**БУ САНДА**


## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Йосыпов Ф.Й.* Татар халкының югалып баручы этнографик төркемнәре: нагайбәкләр һәм нагайбәк сөйләше . . . . . . . . . . . 5

*Бәширова И.Б.* Татар телендә сүзнең лексик мәгънә типлары . . . 17

*Максимов Н.В.* Сөйләм теленә һәм язуга бер караш . .. . . . . . . . . 27

*Алишина Х.Ч.* Профессор Д.М. Насилов – борынгы уйгур теле һәм язуы буенча Россиядә бердәнбер белгеч . . . . . . . . . . . . . . 34

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Әхмәтьянов Р.Г.* Йосыф Баласагуни һәм аның «Кутадгу билик» әсәре турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39

*Әхмәтҗанов М.И.* Алтын Урда дәүләтенең башлангыч дәверендәге публицистик әдәбият традицияләре хакында (XIII–XVI йөзләр) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51

*Миңнегулов Х.Й.* Киң колачлы казакъ галиме (Күлбәк Ергобәк) . . 56

*Ганиева-Гыйниятуллина А.Ф.* Гариф Ахуновның соңгы чор иҗатында яңа эзләнүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61

## КОНКУРСКА

*Булатова М.Р.* Башкортстанда туган татар язучылары иҗатындагы телбизәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68

*Мансуров А.И.* Р. Гаташның «Ирләр булыйк» шигыренә салынган фәлсәфи фикер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Ямалтдинов И.И.* Тукай турында бәетләр . . . . . . . . . . . . . . . 81

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Исхаков Р.Р.* XVI–XVII гасырда Идел–Урал халыкларын христианлаштыру һәм татар-керәшен конфессиональ берлеген формалаштыру мәсьәләсенә карата . . . . . . . . . . . . . . . . . 85

*Мөстәкыймов И.А.* XVII гасырның икенче яртысы – XVIII гасыр башы Урта Идел тарихына караган ике мәгълүмат . . . . . . . . . 105

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Яхин Ф.З.* Татар әдәбият белемендә Гали Халит . . . . . . . . . 109

*Хәсәнгата Габәши.* Тәрҗемәи халемнән, гыйльми һәм иҗтимагый хезмәтләремнән беркадәресе . . . . . . . . . . . . 118

## ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР

*Нигъмәт Хәким.* Имля хакындагы корылтай карарлары турында . 150

## ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Юлы уңның эше уң, яки Самарага сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154

## СӘНГАТЬ

*Газизова М.Р.* Сатирик рәссам Илдар Нәфиев иҗаты . . . . . . . 162

*Галимова Э.М.* Мордовиядә яшәүче татарларның җыр үзенчәлекләре (Абдулла Кротов башкаруындагы җырлар мисалында) . . . . . . 165

## ЯҢА КИТАПЛАР

Әхмәтъянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге . . . . . . . . 171

Документларда – тарих сабаклары . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

УДК 811.512.145

*Ф.Й. Йосыпов*

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЮГАЛЫП БАРУЧЫ ЭТНОГРАФИК ТӨРКЕМНӘРЕ: нагайбәйкләр һәм нагайбәк сөйләше[1]

Статья посвящена истории формирования и языковым особенностям одной из этнографических групп татарского народа, которая на сегодняшний день находится на грани исчезновения, а именно нагайбакских татаров. Как показали исследования, нагайбакский говор с точки зрения фонетических, грамматических и лексических особенностей входит в единую систему диалектов и говоров татарского языка.

**Ключевые слова:** этнографические группы татарского народа, нагайбаки, диалекты и говоры татарского языка, нагайбакский говор.

Урал тауларының көньякка таба түбәнәеп барган бер өлешендә, Чиләбе өлкәсенең Башкортстан республикасы белән чиктәш Нагайбәк районында, татар халкының нагайбәкләр, нагайбәк татарлары яки нагайбәк керәшеннәре дип аталып йөртелә торган мөстәкыйль этник төркеме яши. Алар яши торган Кассель, Фершампенуаз, Остроленко, Париж, Астафьевка авыллары Нагайбәк районына карый. Нагайбәкләрнең бер төркеме Златоуст шәһәреннән ерак булмаган Чибәркүл районының Варлам, Попово, Болотове Краснокаменка, Ключевская авылларында да яши. 1924 елга кадәрге административ бүленеш буенча бу авыллар Оренбург губернасының Верхнеуральск өязенә караганнар.

Тарихи әдәбиятта нагайбәкләрне мөстәкыйль халык итеп санау тенденциясе яшәп килде. Әмма соңгы вакытларда галимнәр, керәшен татарларының тормыш-көнкүреш, гореф-гадәтләрен, тел үзенчәлекләрен өйрәнеп, нагайбәкләрне дә аларның бер төркеме дип карый башладылар (Токарев, 1958; Баскаков, 1969; Юсупов, 1979). Тарихи әдәбияттан һәм архив материалларыннан күренгәнчә, нагайбәкләр, татар халкының аерылгысыз бер этник төркеме буларак, башка керәшен татарлары кебек үк, уртак иҗтимагый-сәяси язмыш кичерделәр.

Нагайбәкләр, 1842 елга кадәр, ягъни хәзерге Чиләбе өлкәсе территориясенә күчерелгәнче, Уфа губернасының Бәләбәй өязендә яшәгәннәр. Әдәбиятта аларның шушы территориядә кайчан һәм ни сәбәпле христианлаштырылулары турында ачык мәгълүматлар китерелмәсә дә, кайбер

[1] Татар халкының юкка чыгу куркынычы астында торган этнографик төркеме – нагайбәк татарларына багышланган бу хезмәт журналның киләсе саннарында дәвам итәчәк мәкаләләр циклын башлап җибәрә.

тарихи материалларга таянып, алар элек яшәгән урыннарында ук керәшен татарларының аерым төркеме буларак формалашкан дип уйларга нигез бар. Нагайбәкләрнең килеп чыгуы белән бик күпләр кызыксынса да, бу мәсьәләдә бердәм фикергә килә алмаганнар. Нагайбәкләр турындагы беренче белешмәләрне Оренбург губернасы тарихына караган хезмәтләре белән танылган П.И. Рычков бирә [Рычков, 1762, с. 183–190]. Ул аларны, халык арасында сакланып калган риваятьләр һәм кайбер документларга таянып, «иске» керәшеннәр дип саный. П.И. Рычков күрсәтүе буенча, бу керәшеннәр Нагайбәк крепосте тирәсендәге 10 авылда яшәгәннәр (ләкин ул авылларны санап күрсәтми). Автор әйтүенчә, бу җирләрдә кайчандыр Нагайбәк исемле башкортның җәйләве була, шушы урынга 1736 елда салынган крепостька да Нагайбәк исеме бирелә. Казах әсирлегеннән качып, руслар ягына чыккан һәм Оренбургта чукындырылган фарсылар, төрекләр, төрекмәннәр, әрмәннәр, каракалпаклар, үзбәкләр һәм башка халыклар, шулай ук соңрак чукындырылган Оренбург калмыклары да нагайбәкләр арасына таратылып утыртылганнар [Рычков, 1762, с. 191–208].

Оренбург губернасы тарихы буенча күп кенә хезмәтләр калдырган В.Н. Витевский нагайбәкләр белән махсус кызыксына, аларның тарихы, гореф-гадәтләре, авыз иҗаты турында мәгълүматлар бирә. Ул, халык арасында яшәп килгән риваятьләргә һәм Фершампенуаз авылы уряднигы С.И. Никитинда сакланган документларга таянып, нагайбәкләрне Иван Грозный вакытында ук үзләре теләп чукынган һәм Нагайбәк авылы тирәсенә күчереп утыртылган Арча татарлары дип исәпли [Витевский, 1891, с. 285]. Аның әйтүенчә, чукынучылар арасында татар морзалары да булган.

Татар халкының үзенчәлекле бу төркеме турында рус казакларының тарихын өйрәнүче Ф.М. Стариков фикерләре дә кызыклы.Ул да аларның килеп чыгышын, нагайбәкләр арасында сакланган риваятьләргә таянып булса кирәк, чукындырылган Арча татарларына бәйләп аңлата [Стариков, 1884, с. 176]. Шул ук вакытта галим, Казан ханлыгы җимерелгәч тә, бер төркем нугай, чукындырылып, Бәләбәй, Минзәлә өязләрендәге буш җирләргә күчерелгән дип раслый торган документ барлыгы турында әйтә. Ләкин ул аларны, ни өчендер, «яңа» керәшеннәр дип атый. 1760 елда алар әле Нагайбәк крепосте һәм аның тирәсендәге ун авылда яшәгәннәр ди һәм авылларының төгәл исемлеген китерә: Большие и Малые Усы, Дияшево, Новая, Балыклы, Ахманово, Сарашлы, Килыво, Илегово, Кастеево, Маты [Стариков, 1884, с. 176]. 1795 елда үткәрелгән халык санын алуның V ревизиясендә дә бу авылларда керәшен татарлары яшәве турында әйтелә.

Бакалы керәшеннәренең Бәләбәй өязенә Казан губернасыннан күчеп утырулары турында Е. Малов та әйтә [Малов, 1878, с. 3].

Сәяхәтче һәм тарихчы П. Небольсин нагайбәкләрне чукындырылган мишәрләр дип исәпли. Ләкин шул ук вакытта ул аларны

нугайлар белән дә бәйли. Безнең өчен кызыклы гына риваять китерә: Әстерхан далаларында яшәүче кундрау татарларының сөйләвенә караганда, ак тәнле берничә нугайбәк, туганнары белән ачуланышып, Идел буйларына күчеп китә. Аннан алар Иделнең сулъяк яры буйлап Кинельгә барып чыгалар һәм Ык елгасы буена килеп урнашалар [Небольсин, 1852, с. 21].

Е.А. Бектеева да нагайбәкләрнең килеп чыгышын нугайларга бәйләп аңлата. Үзе дә нагайбәк керәшеннәреннән чыккан әлеге автор халык арасында сакланган бер документтан мондый өзек китерә: «Казан Иван Васильевич тарафыннан 1552 елның 1 октябрендә алына. Шул ук вакытта нугайлар, чукындырылып, җан башы окладына язылып, башкорт җирләренә күчерелә».

Югарыда китерелгән авторларның нагайбәкләр этногенезына нугай компонентының катнашуы турындагы фикерләре күпмедер дәрәҗәдә безнең тарафтан тупланган тел материаллары белән дә ныгытылырга мөмкин. Билгеле булганча, казан арты-дөбьяз, казан арты-питрәч (бигрәк тә Шәле, Күн авыллары) сөйләшләрендә нугай теле белән уртак үзенчәлекләр сакланган. Бу сөйләш вәкилләре үзләренең чыгышларын Сөембикә белән бер вакытта һәм аннан да алдарак килгән нугайлар белән бәйләп аңлаталар. Тарихта хәзерге Питрәч районындагы Күн, Зеленодольск районының Чүрчиле авылларында чукындырылган татарларның яшәүләре турында кайбер мәгълүматлар бар. Бу турыда күренекле археограф Марсель Әхмәтҗановның фикерләре дә бик кызыклы. Ул Казан артындагы Балтач, Карадуган авылларының тарихын нугай-кыпчаклар белән бәйли (1985). Д. Исхаков та нагайбәк төркеменең казан арты, мишә буе керәшеннәре белән зур уртаклыгын күрсәтә. Ул да бу төркем керәшен татарларының формалашуында нугай-кыпчаклар катнашкан дип уйларга билгеле бер нигез бар дип исәпли (1993).

Нагайбәкләрнең килеп чыгышын Арча татарлары белән бәйләү нугай-кыпчак гипотезасына каршы килми. Тирәнрәк уйлаганда, бу ике фикер бер-берсен тирәнәйтә генә. Д. Исхаков моны Казан арты топонимнарының Бәләбәй (Минзәлә) һәм Верхнеуральск өязләрендәге авыл исемнәренә тәңгәл килүе белән раслый. Автор шундыйлардан Ахманово, Килеево, Балыклы, Заишево (бу төбәктә яшәүчеләр сөйләшендә [з] авазы [д] белән алмаштырыла: Дияшево) һ.б. авыл исемнәрен күрсәтә. Бу топонимнар нагайбәкләрнең төрле чорларда әкренләп көнчыгышка таба хәрәкәтен күрсәтә торган дәлилләрнең берсе булып санала.

Зур совет энциклопедиясенең 23 нче томында да нагайбәкләр чукындырылган нугайлар дип аңлатыла. Биредә әйтелгәнчә, аларның бер өлеше соңыннан башкортлар, татарлар белән катнашып бетә, ә XVIII гасырда хәзерге Чиләбе өлкәсенә күчерелгән икенче төркеме сакланып кала.

Күренекле совет этнографы С.А. Токарев, беренчеләрдән булып, нагайбәкләрне татар

халкының аерылгысыз бер төркеме итеп карый, аларны Нагайбәк крепосте тирәсендә яшәгән, XVIII гасыр азакларында аннан Чиләбе өлкәсенең Верхнеуральск өязенә күчерелгән керәшен татарлары дип исәпли [Токарев, 1958, с. 180–181]. Бу билгеләмә безнең нагайбәкләр сөйләшен өйрәнү нәтиҗәләре белән дә раслана.

Югарыда китерелгән фикерләрдән нагайбәкләрнең аерым бер этник төркем булып формалашуында Казан ягыннан күчерелгән керәшен татарлары, нугайлар һәм башка халыклар катнашканлыгы аңлашыла.

Нагайбәкләрнең Уфа губернасы Бәләбәй өязендә күпме яшәүләре турында төгәл мәгълүматлар булмаса да, бу төбәктә бик борынгы заманнарда ук керәшен татарларының яшәгәнлеге билгеле. Алар тарихи әдәбиятта 1730 еллардагы башкорт чуалышларына бәйле рәвештә генә искә алына башлый. 1736 елга кадәр нагайбәкләр казнага ясак, ә җирдән файдаланган өчен оброк түләп киләләр. Ләкин башкорт восстанияләрендә катнашмаган һәм Рус дәүләтенә тугрылык күрсәткәннәре өчен, алар ясактан азат ителә, башкортлардан арендага алып торган җирләре үзләренә беркетелә һәм барысы да казак сословиесенә күчерелә. Алар Минзәлә, Уфа шәһәрләре арасындагы чик сызыклары буйлап казак хезмәтен үти башлыйлар [Материалы по истории России..., 1800, с. 193].

Архив документларында да алар башта «иске», «яңа» керәшеннәр исеме астында гына йөртелә. Яңа салынган Нагайбәк крепосте 1736 елдан башлап казак сословиесенә күчерелгән керәшеннәр белән идарә итә башлый, ә аңа буйсынган керәшен татарларын тирә-яктагы халыклар тарафыннан нагайбәклеләр (нагайбакцы) яки нагайбәкләр (нагайбаки) дип йөртү гадәткә керә. Уфа провинция конторасы указыннан күренгәнчә, бу җирләр яңадан үлчәнеп, нагайбәкләргә 1745 елда план һәм межа кенәгәләре бирелә [Стариков, 1884, с. 176].

1780 елдан башлап, Нагайбәк крепосте янындагы җирләр Бәләбәй өязе карамагына күчә. Бу крепостька караган керәшен авылларында, нагайбәк казакларыннан тыш, яңа чукындырылган типтәрләр, «иске» керәшеннәр һәм ясаклы татарлар яшәгән [Стариков, 1884, с. 176]. Бу турыда архив материалларында да әйтелә.

Оренбург губернасына татарларның күчеп утыру тарихына караган тагын бер мәсьәләгә игътибар итәргә кирәк. Татар халкының Оренбург губернасында хәрби хезмәт башкарган икенче төркемен йомышлы (служилые) татарлар һәм мишәрләр (рус язмаларында, архив материалларында: мещеряк, мещеряки) дип атап йөртү XVIII гасырдан башлап кына кулланышка керә. Бу термин Уфа һәм Оренбург губерналарының эчке төзелешенә, халык санын алуга (ревизские сказки) караган архив материалларында бик еш очрый. Рус хөкүмәтенең ышанычын казанган йомышлы мишәрләр (*рус:* служилые мещеряки) Русиянең чик буе өлкәләрен саклаучы йомышлы татарларның бер төркемен тәшкил итә. Әмма алар бер үк бурычны башкарсалар да, бу татарлар нагайбәкләрдән,

әлеге катламны белдерүче атама ягыннан гына түгел, бәлки административ төзелеш ягыннан да нык аерылып торганнар. Уфа, Бәләбәй, соңрак Верхнеуральск өязләрендәге керәшеннәрне бар яктан да рус казакларына тиңләү Оренбург губернасы төзелү белән башланып китә. Билгеле булганча, Русиянең бу административ өлешен төзү һәм үзләштерү эшендә рус казакларына зур өметләр баглана. Үзенең көнчыгыш чикләрен киңәйтүдә казаклар катламыннан файдалану Русиянең хәрби-сәяси тормышында аерым урын алып тора. Йомышлы мишәрләрдән үзгә буларак, нагайбәкләр хәрби униформа, хәрби тәртип, оештыру, үзәкнең төзелеше ягыннан рус казакларыннан һич кенә дә аерылмаганнар. Нагайбәкләр белән Оренбург казак гаскәре дигән хәрби оешма идарә иткән. Нагайбәкләрнең үз сотниклары, үз атаманнары булган. Йомышлы мишәрләр белән Башкорт-мишәр гаскәре идарә итә. 1840 елда бу идарә бетерелә. 1847 елдан башлап идарә итү эшләре 1 нче башкорт кантонына күчә. 1855 елдан соң бу оешма Башкорт гаскәре дип атала башлый. Димәк, нагайбәкләр татар халкыннан административ хезмәт буенча да изоляцияләнгән була. 1736 елдан 1917 елга кадәр нагайбәкләр Оренбург казак гаскәренең бер өлешен тәшкил итеп яшиләр.

1800 елдан башлап биргә үзәк губерналардан күп кенә полклар күчерелә, яңа крепость, поселоклар үсеп чыга. 1840 елда Оренбург казачествосына яңа җирләр бүлеп бирелә. 1842 елның 26 февраль указы буенча 3 нче кантонның Бакалы, Нагайбәк станицаларына караган авыллардан 1250 нагайбәк казагы гаиләләре белән Верхнеуральск өязенә күчереп утыртыла [Материалы по истории России..., 1800, с. 193].

Яңа җирләргә күчерелгән вакытта, бу авылларда бер генә казак (нагайбәк) гаиләсе дә калдырылмый; аларның җирләре Казан ягыннан күчерелгән керәшен татарлары һәм русларга бүлеп бирелә [Витевский, 1891, с. 257]. Нагайбәкләр яшәгән җирләргә килеп утырган керәшен татарлары ясак түләүче татарларның бер төркемен тәшкил итә. Шулай итеп, Нагайбәк крепостеның административ, хәрби әһәмияте бетү һәм казак сословиесендә булган нагайбәк керәшеннәрен Оренбург далаларына күчерү белән, бу якларда нагайбәк дигән этноним да онытыла. Әгәр дә Башкортстанның Бакалы районында яшәүче керәшен татарлары нагайбәкләрнең бер төркеме булса, халык хәтерендә, һичшиксез, бу атама сакланып калыр иде. Шуның өчен дә, күп кенә уртак яклары булуга карамастан, нагайбәкләр белән Башкортстанда яшәүче керәшен татарларын бутарга ярамый.

Яңа җирләргә күчерелгән нагайбәк авылларының башта исемнәре дә булмый, алар саннар белән генә аталып йөртеләләр. Мәсәлән, 1 нче (Кассель), 2 нче (Остроленко), 3 нче (Фершампенуаз), 4 нче (Париж) һ.б. Соңрак, рус армиясенең Германия, Франция белән сугышта ирешелгән уңышларын мәңгеләштерү

максатыннан чыгып, нагайбәк авылларына Кассель, Фершампенуаз, Остроленко, Требий, Париж исемнәре бирелә [Витевский, 1891, с. 257]. Шуның белән бергәттән, халык телендә хәзерге көндә дә бу авылларны Бәләбәй өязендәге исемнәре белән атау яшәп килә. Мәсәлән, Кили (Кассель), Сарашлы (Остроленко), Балыклы (Париж), Кәчти (Варлам, Попово) һ.б.

Соңрак нагайбәк авылларына руслар һәм хәрби калмыклар да утыртыла. Варлам, Краснокаменка, Ключевская авылларының бер өлешендә әле дә руслар яши. Калмыклар, картлар әйтүенә караганда, 1917 елга кадәр үк моннан хәзерге Калмык республикасы территориясенә күчеп киткәннәр.

Нагайбәк сөйләше үзенең фонетик, грамматик төзелеше ягыннан татар әдәби теленә бик якын тора. Татар халкының төп массасыннан берничә гасыр буена изоляцияләнгән килеш яшәү нәтиҗәсендә, аларның телләрендә, рухи культураларында күп кенә борынгы күренешләр сакланып калган. Нагайбәкләрнең тел үзенчәлекләре татар диалектлары системасында урта диалектның бер сөйләшен тәшкил итә. Әдәби телгә каршы куела торган билгеләре ягыннан ул башка керәшен татарлары сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Бу бигрәк тә фонетика өлкәсендә [а] авазын сүз башында, рус телендәге кебек, ачык итеп, [о], [у] сузыкларыннан соң нык иренләштереп, [ә] авазын тар итеп әйтүдә чагыла: *боза$^{o}$у, бора$^{o}$, чәчкә, тәрәзә* һ.б. Урта диалектның казан арты сөйләшләрендәге кебек, нагайбәк сөйләшенә дә җ-еләштерү хас: *җегет – йегет, җақын – йақын, җыл – йыл* һ.б. Бу уртаклык *ф-п, х-к* авазларының тәңгәллегендә дә күренә: *пайда – файда, йапрақ – яфрак, қат – хат* һ.б.

Иренләшкән [о], [ө] авазларының үзләреннән соң килгән [ы], [е] авазларын иренләштерүе ягыннан да сөйләш әдәби телгә бик якынтора. Грамматик төзелеше ягыннан да нагайбәк сөйләше татар әдәби теленнән аерылмый. Сөйләшнең лексик составын татар һәм башка төрки телләр белән уртак сүзләр тәшкил итә.

Нагайбәкләр сөйләше, аерым сөйләш буларак, Уфа губернасының Бәләбәй өязендә үк формалаша башлаган дип әйтергә ныклы нигез бар. Моны беренче чиратта күрше минзәлә һәм бөре сөйләшләре белән уртак үзенчәлекләр күрсәтеп тора. Шундый үзенчәлекләрдән кайберләренә генә тукталып китик.

Фонетика өлкәсендә – *чыбыркы, йомырка, кәбәркә* сүзләренә [т] тартыгы өстәп, ягъни архаик үзенчәлекне саклап сөйләү – *чыбыртқы, җомортқа, кәбәрткә;* морфология өлкәсендә: а) *-мақ, -мәк* + *кирәк* формасының минзәлә сөйләшендәге кебек актив булуы: *Анда ничек итеп бармақ кирәк;* ә) *-лар, -ләр* күплек кушымчасының, фигыльләргә ялганып, теләк-киңәш мәгънәсен белдерүе: *Син анда утырмаслар, монда утырырлар; Аш салганыйым, ашарлар;* б) *-ынқыра, -енкерә* формалы фигыльләрнең әдәби телдәгегә караганда активрак булуы. Лексика өлкәсендәге уртаклык күбрәк туганлык терминнары,

йорт-җир, каралты төзелешләрен атый торган сүзләргә карый.

Нагайбәк сөйләшенең формалашуында аларның татар халкының төп массасыннан дини яктан изоляцияләнүләре дә әһәмиятле роль уйнаган. Христиан динен кабул иткән бу төркемнең тирәяктагы башка татарлар белән аралашуы чикләнә; сөйләшнең үз эчендә йомылуы барлыкка килә, тормыш-көнкүрештә нагайбәкләргә генә хас үзенчәлекләр туа. Мондый изоляцияләнү аларның телләрендә дә аерымлык китереп чыгара. Рус теле аша кергән христиан исемнәре борынгы төрки тел структурасына һәм яңгырашына яраштырып әйтелә. Бу очракларда христиан исемнәренә борынгы төрки телдә эндәшү формасы дип аталган *-ау, -әү, -ай, -әй, -ук, -үк* кушымчаларын ялгап әйтү киң кулланыла. Мәсәлән: *Ибый – Иван, Гәрей – Григорий, Татый – Татьяна, Учый – Осип, Макрый – Макар, Карлый – Карп, Сабый – Савелий* һ.б.

Нагайбәкләрнең килеп чыгышын, аларның татар халкының мөстәкыйль этник төркеме буларак формалашу тарихын өйрәнүдә туганлык мөнәсәбәтләрен белдерүче терминнар да ышанычлы чыганакларның берсе булып хезмәт итә ала. Һәр телнең лексик составында бу сүзләр үзләренең даими тотрыклылыгы һәм бик борынгы чорларга барып тоташулары белән аерылып тора. Нагайбәк сөйләшендә дә алар иң борынгы катламны тәшкил итә.

Нагайбәкләрдә гомуми туганлык, нәсел-нәсәбә мәгънәсен белдерү өчен *туганай* сүзе кулланыла. Бу сүзне борынгы *-ай, -әй* кушымчалары белән әйтү башка татар сөйләшләрендә очрамый. Ул татар теленең тарихи үсеш дәверендә *-ый* формасы белән алмаштырылган (*туганый*) һәм аның мәгънә эчтәлеге дә киңәя төшкән: 1) килен белән каенсеңел яшьтәш булганда (кама тамагы сөйләше); 2) килендәшләр арасында эндәшү сүзе (казан арты-дөбьяз) буларак кулланыла.

Һәр халык һәм этник төркем өчен кан ягыннан булган туганлык терминнары иң якын һәм нык саклана торган туганлык мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Шундый терминнарның кайберләренә күз салып узыйк.

*Нәнә, нәнәй, нәнәү, мамау, инәй* – әни. *Нәнә, нәнәй* сүзләре казан арты, чистай, зәй керәшеннәрендә, казан арты-балтач, ләмберә, сергач сөйләшләрендә шул ук мәгънәдә, кама тамагы, эчкен сөйләшләрендә дәү әни мәгънәсендә кулланыла. *Инәй* формасы Чиләбе өлкәсенең Чибәркүл районында яшәүче нагайбәкләр өчен хас. Әлеге терминнарның таралыш изоглоссасы нагайбәкләрнең әкренләп казан артыннан көнчыгышка таба миграция юнәлешен күрсәтеп тора.

*Тәтә, тәтәй, тәтәү, папау* – әти. *Нәнә, тәтә* сүзләрен эмоциональ-экспрессив стильдә яки эндәшү формасы буларак, *-ау, -әү* кушымчалары ялгап куллану да, *нәнәү, тәтәү,* шул ук стильдә *мамау, папау* сүзләре дә киң таралган. Төрки телләрнең ерак тарихына хас булган бу кушымча туганлык мөнәсәбәтләрен белдерә торган башка сүзләргә дә ялганырга мөмкин: *әбәү* (дәү әни), *бабау* (дәү әти). *Нәнә, тәтә*

сүзләре башка терминнар ясауда нигез булып хезмәт итә: *олы, нәнә* эндәшү сүзләре буларак кулланылалар. *Нәнә, тәтә* терминнары бик борынгы, ихтимал, болгар чорыннан ук килгән туганлык атамаларыннан булуы мөмкин. *Тәтә* сүзенең татар сөйләшләреннән башка, шушы яки шуңа якын мәгънәдә күрше чуваш һәм фин-угор телләрендә кулланулы шул турыда сөйли.

*Тута, түти, тутай, ак̡ түти* – апа. Эндәшү сүзе буларак, күбрәк *тутай* варианты кулланыла. *Ак̡ түти* термины исә эмоциональ-экспрессив стильдә, сөйләүченең адресатка булган якынлыгын, җылы хисләрен ассызымлау кирәк булганда әйтелә: *җырак̡ түти* – әнисенең апасы; *җырак̡ агай* – әнисенең абыйсы, энесе; *җырак̡ әби, җырак̡ай* (эмоциональ-экспрессив стильдә) – әнисенең әнисе (дәү әни); *җырак̡ бабай* – әнисенең этисе (дәү эти). Әни ягыннан булган туганлык атамаларын *җырак̡* сүзе белән белдерү керәшен татарларының уртак үзенчәлекләреннән санала.

*Агай, агачай* – үзе белән бертуган абый. *Агачай* термины беренче варианттан үзенең эмоциональ-экспрессив төсмере белән аерылып тора. Ясалышы белән бу сүз *җиңәчәй* вариантына туры килә.

Никахка бәйле булган туганлык терминнарының күбесе, башка керәшен татарларындагы кебек, *бий* нигезен тәшкил иткән атамалар белән белдерелә. Бу терминнар иренең ата-анасын һәм иреннән өлкән булган туганнарын атау өчен кулланыла: *бийана, бийем* – кайнана, *бийата* – кайната, *бийагай* – иренең абыйсы, *ак̡бийем* – иренең апасы. Иренең энесе – *җанагай,* сеңлесе – *печкәчәй, печкәчәм. Печкәчәй, печкәчәм* сүзләреннән дә *бий* тамырын аерып чыгарырга мөмкин: *бикәчәй, бикәчем* (нократ сөйләшендә), *пикәчәй, пикәчем, печкәчәй, печкәчем.*

*Бай* тамыры ярдәмендә никахка бәйле туганлык мөнәсәбәтләрен белдерү күрше чуваш телендә дә киң таралган: *паятам* – кайнатам, *паянам* – кайнанам һ.б. *Бий* тамыры күп кенә төрки телләрдә хуҗа, кенәз, түрә төшенчәләрен белдерә торган терминнар ясауда катнаша. Төрки халыкларда бу атамалар өлкән яшьтәге туганнарга, гомумән, хөрмәткә лаек булган өлкән кешеләргә эндәшү формасы буларак кулланыла. Татар һәм чуваш сөйләшләрендә бу сүзнең туганлык терминнары составында актив булуы, аның Урта Идел һәм Түбән Кама лингвистик җирлегендә дә бик борынгы заманнардан ук кулланылып килүе турында сөйли.

Кан ягыннан булган туганлык мөнәсәбәтләрен белдерүдә *кайын* тамыры да киң кулланыла: *кайнага* – апасының ире яки хатынның абыйсы, *к̡айната* – хатынның апасы. *К̡айын* сүзе белән туганлык терминнары ясау төрки телләрнең күпчелеге өчен хас.

Нагайбәкләр сөйләшендә табигать күренешләре, җир-су атамалары өлкәсендә дә бик борынгы чорларга барып тоташа торган сүзләр сакланып калган. Мәсәлән: *к̡ырлач* – кышкы иң каты суыклар. Мондый көннәр, кайвакытта һәм ни дәрәҗәдә салкын булуына карап, *агам к̡ырлач // оло к̡ырлач,*

*әнем қырлач // бәләкәй қырлач* төрләренә бүленә. *Ағам қырлач // оло қырлач* дип декабрь азагы, январь башларында була торган каты суыклар атала. *(Ағам қырлачәйтә икән, мин китәм, менә әнем күрсәтер сезгә кирәкне, дип). Энем қырлач // бәләкәй қырлач* – январь ахырында, февраль башында була торган салкын көннәр *(Мин үсеп кенә җиттем, кыш та бетте).* Салкын айларны шушы рәвешчә атау керәшен татарларының күбесе өчен хас булган. Бу борынгы сүзләр нагайбәк татарларының ерак тарихта башка халыклар белән булган элемтәләре турында сөйли. Чулым татарларында *хурлач ай* – буранлы ай. Чагыштыр: чуваш телендә *ман қырлач*– январь, *кесен қарлач* – февраль айларында була торган каты салкыннар, хакас телендә *кичит хырлас* – каты салкыннар (декабрь) ае, караим телендә *кырлаш* – каты салкын, *кичи кырлаш* соңгы салкын көннәрне аңлата.

*Ақман-туқман* – көчле буран. Бу сүз шулай ук Башкортстандагы татар сөйләшләрендә билгеле. Димәк, бу яктан да нагайбәкләрнең әлеге сөйләшләр белән булган тарихи элемтәләре күренеп тора.

Нагайбәкләрнең рухи культурасын өйрәнү Казан ханлыгы җимерелгәч тә чукындырылган бу төркем татарларның аңында ислам дине төшенчәләре һәм бу дингә караган йолаларның җитәрлек дәрәҗәдә ныгып бетмәгәнлеген күрсәтә. Нагайбәкләрнең XVI гасыр башында да борынгыдан килгән кайбер мәҗүсилек йолаларын үтәп килүләре шул турыда сөйли. Мондый гореф-гадәтләрнең күбесе бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән һәм нагайбәкләрнең рухи тормышында әһәмиятле урын алып тора. Берничә гасыр буе христиан динендә булуларына карамастан, нагайбәкләр бу диннең барлык таләпләрен үзләштереп бетергәннәр дип әйтеп булмый. Өлкән буын вәкилләренең истәлекләренә караганда, нагайбәкләрне чиркәүгә староста һәм старшиналарның боерыгы белән китерергә мөмкин булган. Өйдәге иконалар авылга зур түрәләр һәм руханилар килгәндә генә эленгән. Алар киткәч, иконаларны идән астына төшереп куйганнар. Нагайбәкләрнең сөйләүләренә караганда, ислам һәм христиан дине йолаларын үтәп килүче гаиләләр егерменче гасыр башында да шактый булган. Әйтергә кирәк, нагайбәкләр ислам диненә бүген дә зур ихтирам белән карый. Корылык һәм шуңа охшаган табигать фаҗигаләре вакытында нагайбәкләр, күрше авыллардан мөселман-татарларны кырларына чакырып, дога кылдыра, бик әһәмиятле вакыйгаларда корбан чалдыра торган булганнар. Ләкин бу йоланы авыл халкы гадәттә ерактан гына күзәтеп торган. Гореф-гадәт, йола исемнәренә караган сүзләр дә нагайбәкләрнең борынгы тарихын ачуга ярдәм итә торган чыганакларның берсе булып тора. Шундыйлардан берничәсенә генә тукталып китик.

*Аш бирелү* – үлгән кешенең рухына атап, корбан чалу. Ислам диненнән аермалы буларак, бу йола билгеле бер вакыт белән чикләнмәгән. Ул, кеше үлеп, бер

ел үткәч тә, берничә елдан соң да башкарылырга мөмкин. Бу – бик борынгыдан килгән һәм ислам дине үзенчәлекләре белән баетылган йолаларның берсе. Шуның белән бергә биредә ислам һәм христиан динендә булмаган күп кенә детальләрне дә күзәтергә мөмкин. Аш бирү йоласы, гадәттә, октябрь азагы, ноябрь башларында башкарыла. Бу көнне һәр гаилә, бу бәйрәмгә катнашып, үзенең вафат булган туганнарын искә ала.

*Табаҡ җасау* – үлгән кешенең рухына атап корбан чалган йортка аш илтү йоласы. Китерелгән ашлардан һәм суйган мал итеннән өч табак ясала: беренче табак җан башы дип атала. Ул билгеле бер әрвахның рухына багышлана. Уша табагы – ятим балалар өчен, картлар табагы карт-коры өчен дип әзерләнә. Суйган малның арткы өлеше аерым пешерелә, беренче көнне ашалмый. Бу ит җанбаш ите дип атала. Ул табынның түренә куела. Әбиләр, олы яшьтәге хатыннар бу итне төн буе «саклап» чыгалар. Аны *җанбаш итен саклау* дип әйтәләр.

*Тийәрберсен итү* – 1) югарыда әйтелгән «табак»ларның һәркайсыннан бераз ризык алып, үлгән кешене искә төшереп, дога кылып ашау; 2) ризыктан авыз итү.

*Пештемә куу* – яз көне, чәчүләр беткәч, таякка беркетелгән себеркегә ут төртеп йөгерү йоласы. Бу җәй башында була торган соңгы кырауларны «куу» максатында башкарыла.

*Сөрән* (синонимы – бәйге) *үткәрү* – вакыты һәм эчтәлеге белән, сабан туена туры килә торган спорт бәйрәме. Чагыштыр: тау ягы, чистай сөйләшләрендә *газиз сөрән* – сабан туе, казан артымамадыш сөйләшләрендә *сөрән көне, сөрәнгә чыгу* – сабан туе өчен бүләкләр җыю көне. *Сөрән* сүзе дә бик борынгыдан килә. Бу сүзнең төрки телләрдә якын мәгънәләрдә кулланылуы шул турыда сөйли. Борынгы төрки телдә *сүрән* – сугышка өндәп кычкыру. Чагыштыр: казан арты-дөбьяз сөйләшендә *сөрән салу* – берәр хәл турында кисәтеп, бик каты итеп кычкыру; кыргыз теле сөйләшләрендә *суран* – сугышка өндәп кычкыру; казах телендә *сурен* – тавыш, кычкырыш; үзбәк телендә *суран* – хәрби өндәү, кычкыру; алтай телендә *сурен* коточкыч хәл дигән мәгънәне аңлата. Бу сүз уйгыр, шор, тува, хакас, төрекмән, азәрбайҗан телләрендә дә шуңа охшаш мәгънәләрне белдерә.

Билгеле булганча, миссионерлар тарафыннан керәшен татарлары өчен татар телендә дини эчтәлекле китаплар языла. Китап теле тәэсирендә керәшен татарларының күбесе өчен уртак булган дини лексика барлыкка килә, борынгы татар телендә һәм татар сөйләшләрендә сирәк кулланылган яки онытылып бара торган кайбер сүзләр, киресенчә, активлашып китә яки башка семантик үсеш ала. Мәсәлән: *кач* – тәре, *ҡач ману* – дини бәйрәм – рус. святое крещение, *бәрмәнчек* – дини бәйрәм – *рус.* вербное воскресенье (башка сөйләшләрдә *бәрмәнчек* тал бөресен анлата). Кайбер фигыль формаларында [л] тартыгын төшереп калдыру күренешен дә (мәсәлән, *бумый* –

*булмый, кимей – килми, тыумый – тулмый* һ.б.) шушы китап теле тәэсирендә туган дип әйтергә мөмкин.

Нагайбәк сөйләшенең татар теленнән изоляцияләнүе, яңа урынга – Оренбург губернасына күчкәч, тагын да арта. Татар халкының төп массасыннан территориаль яктан аерымлану, берничә гасыр дәвамында башка төрки телләр (башкорт, казах) чолганышында яшәү аларның сөйләшендә түбәндәге күренешләрне барлыкка китергән: [ыу], [еү], [ей] дифтонгларын (*сыу* – су, *тыуган – туган, кейтми – китми*), аналитик формалы хикәя фигыльләрне (*барып утыра, барып йата*), төп юнәлештәге фигыльләрне кайтым юнәлеше күрсәткече белән куллануны (*ашаныу, языныу*), лексикада: *дайарлау* – хәзерләү, *әйтәшер* кереш сүз ролендә, *иреү* – сагыну, *ирнеү* – ялыгу, *мәшкә* – гөмбә һ.б. күрсәтергә мөмкин.

Чибәркүл районында яшәүче нагайбәкләр сөйләшенә башкорт теленең йогынтысы аеруча сизелерлек булган. Биредә фигыль формаларын һәм ярдәмлек сүз төркемнәрен куллануда башкорт теленең көнчыгыш диалекты белән шактый гына уртаклыгы сизелә.

Нагайбәк татарларының халык авыз иҗаты да искиткеч бай. Халыкның тормышы, үткән тарихы аның иҗатында чагыла. Башка керәшен татарларындагы кебек үк, боларда да борынгы җырлар, бәет-мөнәҗәтләр күп сакланган. Рус һәм украин халыкларындагы кебек үк, җырларны хор белән күп тавышлы итеп башкару ягыннан да нагайбәкләр татар халык авыз иҗатына үзенчәлекле өлеш кертәләр. Бу, бер яктан, христиан дине аша керсә (чиркәүдә догаларны җырлап уку, дини җырлар башкару һ.б.), икенчедән, рус һәм украин казаклары белән күп еллар уртак иҗтимагый тормыш кичерү нәтиҗәсендә дә барлыкка килергә мөмкин. Нагайбәкләрнең халык авыз иҗаты казак тормышының физик, психологик һәм мораль яктан авырлыгын чагылдырган җырларга бай. Алар туган җирне ташлап китү, аның гүзәл табигатен, дус-иш, газиз туганнарын өзелеп сагыну, туыпүскән җиргә мәхәббәт һәм тугрылылык белән сугарылган. Кайбер сирәк очрый торган әсәрләрнең нагайбәкләр иҗатында табылуы аларның татар халкының башка төркемнәре белән тирән генетик бәйләнешләре турында сөйли (мәсәлән, «Сак-Сок», «Хан кызы» бәетләре, «Сарашлы урамнары», «Матур кызның итәге өч рәт», «Яка чылбыры» дигән җырлар һ.б.).

Йомгаклап әйткәндә, югарыда сөйләп үтелгән тарихи, икътисади, сәяси, берничә гасырга сузылган катлаулы этник процесслар нәтиҗәсендә нагайбәкләр татар халкының аерылгысыз бер өлеше булган керәшен татарларының үзенчәлекле этник төркеме, сөйләшләре исә татар теле диалектлар системасына караган мөстәкыйль сөйләш буларак формалашып җиткән.

**Әдәбият**

*Ахметзянов М.И.* К этнолингвистическим процессам в бассейне р. Ик (по материалам шеджере) // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. Казань: ИЯЛИ КФАН. СССР, 1985. С. 58–71.

*Баскаков Н.А.* Введение в изучение тюркских языков. М., 1969.

*Витевский В.Н.* И.И. Неплюев и Оренбургский край в прошлом в составе до 1758 года. Вып. II. Казань, 1891.

*Исхаков Д.М.* Этнографические группы татар Волго-Уральского региона (принципы выделения, формирование, расселение и демография). Казань, 1993.

Материалы по истории России. Сборник указов и других документов, касающихся управления и устройства Оренбургского края 1733–1736 гг. Оренбург, 1800.

*Небольсин П.* Отчет о путешествии в Оренбургский и Астраханский край // Вестник императорского русского географического общества. Ч. II, кн. 1–2. СПб., 1852.

*Рычков П.И.* Топография Оренбургской губернии. Ч. I. СПб.,1762.

*Стариков Ф.М.* Откуда взялись казаки? Оренбург, 1884.

*Токарев С.А.* Этнография народов СССР. М., 1958.

*Юсупов Ф.Ю.* Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.

***Йосыпов Феритс Йосыф улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 811.512.145´373

***И.Б. Бәширова***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СҮЗНЕҢ ЛЕКСИК МӘГЪНӘ ТИПЛАРЫ

Статья посвящена вопросам теории и методологии изучения лексико-семантической структуры слова. Автор исследует взаимосвязи между различными типами лексических значений слов в татарском языке и факторы, оказывающие влияние на их формирование.

**Ключевые слова:** семасиология, слово, лексико-семантическая структура слова, лексическое значение слова, типы лексических значений.

XX гасырның урталарында рус телендә дә, татар телендә дә зур күләмле аңлатмалы һәм ике телле сүзлекләр төзү эше киң колач ала. Әлеге уңай белән сүзнең лексик-семантик төзелешен, ягъни лексик мәгънәне хасил итә торган компонентларны, аның грамматик үзенчәлекләрен, эмоциональ-экспрессив бәяләү һәм стилистик төсмерләрен анык итеп күзалларга, аларның үзара нинди бәйләнеш-мөнәсәбәтләрдә яши алуын, үсеш-үзгәрешләрен махсус рәвештә төгәл итеп билгели белергә кирәк була.

Бу юнәлештә рус филологиясендә күп хезмәтләр языла башлый. Шулардан академик В.В. Виноградовның хезмәтләре бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмаган. Ул үзенең «Основные типы лексических значений слов» мәкаләсендә сүзнең реаль лексик мәгънәсен күзаллау өчен, сүзне телнең тулаем системасына (лексика, сүзьясалышы, грамматика), шул телдә сөйләшә торган халыкның тарихы, гореф-гадәте, фикер һәм тәгъбирләү үзенчәлегенә бәйле рәвештә генә карарга кирәк булу мәсьәләсен күтәрә. Әлеге бәйләнешләргә нигезләнеп кенә сүз мәгънәләренең төп лексик типларын аерымларга мөмкин дип белдерә. Автор өч төрле лексик типның булуын күрсәтә:

1. Сүзнең турыдан-туры чынбарлыктагы предмет-күренешләрне атый һәм сүзлекләрдә теркәлә торган номинатив лексик тибы. Болар сүзлек фондының ныклы катламын тәшкил итә, ләкин, кызганычка каршы, күп сүзләр теркәлмичә кала. Әлеге сүзләр кулланышта якынча иректе, ягъни теләсә нинди башка сүз белән бәйләнә ала, фразеологик тезмәләрнең кысасы белән чикләнмәгән [Виноградов, 1953, с. 12].

2. Сүзләрнең фразеологик тезмәләрдәге мәгънә тибы. Болар үз контекстында йомыла, аларда төшенчәлек үзәге дә, логик-предметлык мөнәсәбәте дә, ирекле сүзләрдәге кебек, калку булып күренә алмый, димәк, туры атау мәгънәсе дә бик чикле була. Сүзләрнең ирекле һәм фразеологик бөтеннәрдәге мәгънәләрен барлау, аларның мәгънә чиген, мәгънә эчтәлеген тулырак билгеләргә мөмкинлек бирә [Виноградов, 1953, с. 20]. (Сүз

уңаеннан әйткәндә, татар теле белемендә бу мәсьәләнең җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелмәгәнлеге мәгълүм. Бездә, гадәттә, номинатив мәгънәләр һәм фразеологик мәгънәләр һәрберсе аерып алып кына тикшерелә. Г. Ахунҗанов хезмәтләрендә генә әлеге мәгънәләрнең берсе икенчесенә керешүе хакында фикер әйтелә.)

3. В.В. Виноградов сүзнең өченче мәгънә тибын сүзләрнең синтаксик тезмәләрдә ничек итеп кулланылуына карап билгеле. Сүзтезмәләр һәм җөмләләрдә функциональ-синтаксик яктан чикләнеп барлыкка килә торган тип сүзләрнең башка мәгънә типларыннан аерыла. Бу вакытта сүз ия, хәбәр, эндәш сүз, аерымланган кисәк һ.б. булып кулланыла һәм күчмә-метафорик мәгънәдә дә була ала [Виноградов, 1953, с. 28].

Шулай итеп, В.В. Виноградов хезмәтендә сүзнең ирекле, фразеологик һәм функциональ-синтаксик дип билгеләнә торган мәгънә типлары күрсәтелә. Әлеге типларны белү күпмәгънәлелек, синонимия, омонимия һ.б. лексик категорияләрне дөрес итеп аңларга мөмкинлек бирә [Виноградов, 1953, с. 3–29].

Рус филологиясендә сүзнең лексик мәгънәсен, лексик-семантик төзелешен тикшерә торган хезмәтләрнең күбесе асылда инглиз, немец, француз телләренең лексикасын өйрәнеп языла, димәк, шул телләрдә чагылыш тапкан теоретик күзаллауларга игътибар ителә [Смирницкий, 1955; Арнольд, 1966; Никитин, 1970, 1974; Степанов, 1976; Уфимцева, 1980 һ.б.].

Теоретик күзаллаулар дигәндә, сүзне семасиологик аспектта тикшерергә кирәклек мәсьәләсенең истә тотылуы аңлашыла. Шулай итеп, рус филологиясендә семасиология тармагы үсеш ала. Әлеге фәннең үз проблемалары (сүзнең лексик мәгънәсе, мәгънә эчтәлеген хасил итә торган компонентлар, аларның табигате һәм вазифасын белү һ.б.) билгеләнә. Сүзләрнең мәгънәләрен, мәгънәләрнең үзара бәйләнешен, аларның үсеш-үзгәрешен тикшерү кирәклеге аңлашыла. Сүзне аерым лексема буларак өйрәнергә, ягъни сүзнең реаль мәгънәсен билгеләргә, аннан соң гына аның кулланылышына, ягъни аерым контекст белән бәйле хәлдә барлыкка килгән лексик-семантик вариантларына да игътибар итәргә мөмкин булуы күренә.

Бу тикшеренүләрдә семасиология тармагына караган фәнни терминология кулланылышка кертелә, метод-методология нигезләнә [Звегинцев, 1957; Шмелев, 1964; Мартынов, 1982; Уфимцева, 1986 һ.б.].

Татар тел белемендә семасиологиягә багышланган махсус монографияләр булмаса да, лексикология дәреслекләрендә ул искә алына [Сабиров, 1965, с. 17], яисә аерым бер бүлекчә итеп карала [Сафиуллина, 1999, с. 14–56]. Әлеге бүлекчәдә сүзнең лексик мәгънәсе, аның типлары, сүздәге күчмә мәгънәләр (метофора, метонимия, синекдоха, вазифа буенча күчеш), омонимнар, синонимнар, антонимнар мәсьәләсе тикшерелә.

Соңгы елларда русистикада, семасиология фәненең яңа

ачышларына нигезләнеп, сүзнең лексик мәгънәсе, мәгънә эчтәлеге (лексик-семантик төзелеше, әлеге төзелешне барлыкка китерә торган компонентлар), лексик мәгънәнең типлары дигән төшенчәләр дә, билгеле бер дәрәҗәдә яңача яктыртыла. Бу мәсьәләгә татар теленә мөнәсәбәтле рәвештә дә игътибар итәргә кирәк булу аңлашыла. Алда әйтелеп үтелгәнчә, сүзнең мәгънә эчтәлеген аның лексик һәм грамматик мәгънә бәйләнешләренең берлеге итеп карарга кирәклек семасиология фәненең методологик нигезе дип кабул ителә. Әлеге нигездә сүзне аның төрле формалары системасының (лексик, лексик-грамматик, лексик-фразеологик, экспрессив-стилистик) берәмлеге итеп өйрәнергә мөмкин була һәм бу вакытта: 1) сүзнең мәгънәсен чынбарлыкта булган предметның атамасы итеп кенә күзаллау киңәя; 2) сүз мәгънәсенең эчтәлеген хасил итә торган компонентларны төгәлрәк билгеләргә һәм аларның үзара мөнәсәбәтен, табигатен системалы итеп өйрәнергә мөмкин була; 3) сүзнең контекстуаль мәгънәсен телнең үз системасында һәм сөйләм системасы берәмлеге буларак тасвирларга җирлек туа; 4) сүзнең лексик-семантик төзелеше һәм телнең лексик-семантик системасы дигән төшенчәләргә нигезләнеп, сүзне өч аспекттан тикшерү мөмкинлеге ачыла: сүз – лексема, сүз – лексик-семантик вариант һәм сөйләмдә сүз кулланылган вакытта, сүзмәгънә эчтәлегенең төрлечә реальләшә алуын күзәтү [Уфимцева, 1986, с. 7 һ.б.].

Әлеге мәсьәләләрне аерып алып карау зарурлыгы күренә.

1. Мәгълүм ки, сүз – чынбарлыктагы предмет, процесс, билге, үзенчәлек һәм төрле мөнәсәбәтләрнең кеше аңындагы чагылышының атамасы ул. Аның тышкы яңгырашы (әйтелеш, язылышы) һәм эчке мәгънәсе (эчтәлеге) бар. Әлеге мәгънәне, семасиология фәненең методологик таләбе нигезендә, статик-субстантциональ һәм хәрәкәттәге, ягъни сөйләмдә эш башкару, функциональ халәтенә карап тикшерә алабыз. Бу аспектлар берсе икенчесе белән үзара ныклы бәйләнеш-мөнәсәбәттә булып, лексик мәгънәнең типларын билгеләргә дә, сүзнең мәгънә эчтәлеге төзелешенең компонентларын аерырга да мөмкинлек бирә.

Алда әйтеп үтелгәнчә, сүз мәгънәсенең төп функциясе – ул билгеле бер информация алып килү. Лексик мәгънәнең типлары менә шушы информациянең чыганагына бәйле була. Әгәр дә сүз чынбарлыкта булган (тотып карыйбыз, тәмлибез, күрәбез, ишетәбез, тоябыз) предмет, күренеш, билгенең һ.б. атамасы булса, сүз (авазлар комплексы) – чынбарлыктагы предмет һ.б. белән ике планлы чагылышы нәтиҗәсендә конкрет-объектлы мәгънә тибы барлыкка килә. Бу вакытта сүзнең мәгънә эчтәлегендә аның логик-предметлык компоненты зур урын ала. Сүзнең лексик мәгънәсе өйрәнелә торган хезмәтләрдән аңлашылганча, XX гасырның урталарына да әле лексик мәгънә дигәндә, сүзнең чынбарлык-предметлык белән бәйле

булуы гына истә тотылганлыгы күренә. Мәсәлән, В.В. Виноградов мәкаләсендә бу турыда болай диелә: «Термин «лексическое» или как в последнее время стали говорить, «смысловые значения слова» не может считаться вполне определенным. Под лексическим значением обычно разумеют его предметно-вещественное содержание, оформленное по законам грамматики данного языка и являющееся элементом общей семантической системы словаря этого языка» [Виноградов, 1953, с. 10]. XX гасырның ахырларына таба инде сүзнең мәгънәсен чынбарлыкта булган предметының атамасы итеп күзаллау киңәя. Сүз белән предметның мөнәсәбәтен, мәгънә эчтәлегенең бер компоненты итеп кенә карарга кирәк булу аңлашыла. Семасиология тармагында тикшерүләр алып барган галимнәр әлеге компонентны денотат дип терминлаштыра. Хәзерге тел гыйлемендә бу термин объектив, номинатив, когнитив, фактик, предметлы төшенчәләрне дә белдерә һәм сүзнең лексик мәгънәсенең төп бер компоненты атамасы буларак күзаллана [ЛЭС, 1990, с. 128–129, 262], сүзне чынбарлыкта булган предметның атамасы икәнлеген аңларга мөмкинлек бирә [Уфимцева, 1986, с. 93].

2. Әгәр дә сүз чынбарлыкта булмаган, адәм баласының уй-фикерләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән төшенчәнең, мөнәсәбәтнең атамасы булса, сүз (авазлар комплексы), төшенчә (фикер эшчәнлеге) белән ике планлы чагылышның нәтиҗәсендә абстракт-субъектив мәгънә тибы барлыкка килә. Бу вакытта сүзнең мәгънә эчтәлегендә аның уй-фикер-төшенчәлек компоненты зур урын ала. Галимнәр әлеге компонентны сигнификат дип махсус терминлаштыра. Сигнификат (лат. обозначение) – тел знагының төшенчәле эчтәлеген күрсәтү. Хәзерге тел гыйлемендә бу термин төшенчәнең эчтәлеге, мәгънәсе, концепт, денотат билгеләрен терки торган төшенчәләрне дә аңлата һәм сүзнең лексик мәгънәсенең төшен-ядросын-сигнификатын белдерә торган компонент атамасы буларак кулланыла [ЛЭС, 1990, с. 262, 444]. Шулай итеп, сүзне чынбарлыкта булмаган предметның атамасы икәнлеген аңларга мөмкинлек бирә. Иң мөһиме, һәр очракта да сүзнең мәгънә эчтәлегендә денотатлы һәм сигнификатлы ике аспектның бергә берләшеп яши алуы күренә.

Сүзнең лексик-семантик төзелешен барлыкка китерә торган әлеге ике компонент берсе икенчесе белән тыгыз берлек хасил итә: сүз мәгънәсенең эчтәлеген икесе берьюлы барлыкка китерә [Уфимцева, 1986, с. 95].

Сүзнең лексик мәгънәсенә гомумиләштерү хас: һәр сүз гомумиләштерә. Моны ничек аңларга? Без билгеле бер предметның исемен атаган вакытта (сәгать, китап һ.б.) чынбарлыктагы бер генә данә предметны түгел, бәлки әлеге төрдәге күп (барлык) предметларны да истә тотабыз. Бер үк исемнең бер төрдәге күп предметларга атама булуын аңлау процессы фикер эшчәнлеге нәтиҗәсендә төшенчәләп-гомумиләштереп күз алдына

китерү була. Димәк, чынбарлыкта булган конкрет бер предметның атамасында, логик-предметлык аспекты белән бергә, фикерләү-төшенчәлек аспекты да урын ала. Бу төрдәге сүзләр конкрет-гомумиләштерүле, ягъни денотатлы-сигнификатив эчтәлекле дип атала. (Монда ялгызлык исемнәренә атама булган сүзләрнең барлыгын, аларның төшенчә белдерә алмавын, ономастика дигән махсус фән тармагында өйрәнелүен истә тотарга кирәк.)

Мәгънә эчтәлегендә уй-фикер-төшенчә компоненты зур урын алган сүзләрнең атамасын без ишетәбез-әйтәбез, күрәбез-язабыз, димәк, чынбарлыкта булган билгеләргә төрәбез, тәгаенлибез. Бу төрдәге сүзләрне абстракт-гомумиләштерүле, ягъни сигнификатлы-денотат эчтәлекле дип атарга мөмкин була.

Конкрет мәгънәле һәм абстракт мәгънәле сүзләр чынбарлыктагы предмет, күренеш, билге, үзенчәлек мөнәсәбәтенең аңдагы чагылышын, авазлар комплексына төреп, тулы, төп, автосемантик, бәйсез, иркле лексик мәгънәсе булган мөстәкыйль мәгънәле сүзләр төркеменә берләшә. Болар әйбер яки күренешне атый: *мәктәп, дәфтәр, китап;* эш яки хәрәкәтне белдерә: *укый, яза, ашый, уйлый;* әйберләрнең сыйфатын, үзенчәлекләген белдерә: *ак, кара, түгәрәк, салкын;* хәрәкәтнең, эшнең билгеләрен аңлата: *тиз оча, әкрен йөри, матур яза* һ.б. Бу сүзләр сүзлекләрдә сүз-лексема буларак теркәлә. Ике телле сүзлекләрдә мәгънәләре тәрҗемә ителә, аңлатмалы сүзлекләрдә – тәфсилләнә, сүзне тел знагы итеп яшәтә торган сүз-мәгънә барлана һәм аңлатыла.

Шуның белән бергә мөстәкыйль мәгънәле сүзләрнең семантик төзелешендә, денотат һәм сигнификат компонентлардан башка, телнең хуҗасы булган һәр халыкның үткәне, гыйбрәтле тарихына, уй-фикер йөртү үзенчәлегенә, тормыш тәҗрибәсенә, дини ышануларына бәйле булган әхлак-этик, эмоциональ-экспрессив бәяләү төсмере һәм сүзнең теге яки бу төрләрдәге сөйләм тибында кулланыла алу-алмау чиген күрсәтә торган стилистик төсмере дә салынган була. Мәгънә эчтәлегендәге бу компонентлар турында да аңлатмалы сүзлектә мәгълүмат бирелә. Сүзлектә теркәлгән әлеге мәгълүмат төрле сөйләм төрләреннән алынган мисал-җөмләләрдә чагылыш таба. Димәк, сүзнең лексик мәгънәсен билгеләгәндә, аның сөйләмдә кулланыла торган грамматик үзенчәлекләре дә истә тотыла.

Билгеле булганча, сөйләм эчендә мөстәкыйль мәгънәле сүзләр белән бергә, ярдәмлекләр дип атала торган сүзләр дә урын ала (модаль сүзләр, ымлык, кисәкчә, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр һ.б.) [Татар грамматикасы, 2002, б. 12]. Шуның белән бергә мөстәкыйль мәгънәле сүзләрне алыштырып, күрсәтеп килә, аерым сүз төркеме булып берләшә торган алмашлык сүзләре булуы мәгълүм. Димәк, сүзләрнең лексик мәгънәсе дигәндә, аларның мәгънә эчтәлегенең компонентларын белү белән бергә, кайсы сүз

төркеменә каравын да, нинди лексик-семантик категориянең берәмлеге була алуын да истә тотарга тиешбез [Виноградов, 1953, с. 6, 1977, с. 65].

Шулай итеп, махсус әдәбиятта семиологик (релевантлы) класслар дип атала торган [Ахманова, 1969, с. 383] мөстәкыйль һәм ярдәмче мәгънәле сүзләр аерыла. Мөстәкыйль мәгънәле сүзләр чынбарлыкта булган предметлар һәм фикер эшчәнлеге белән барлыкка килгән төшенчәләргә атама буларак, аларга бәйле хәлдә, сөйләм барышында үзара да ныклы бәйләнеш-мөнәсәбәттә яшиләр. Әлеге бәйләнеш лексик берәмлекләрнең категориаль яисә сүз ↔ сүз мөнәсәбәте дип атала. Бу очракта сүз мәгънә алып килә торган тел-сөйләм системасына бәйле була һәм ул структур тип дип атала торган өченче мәгънә тибын хасил итә. Нәтиҗәдә, чынбарлыктагы предметларга атама булып, денотат-сигнификатлы, ягъни объектлы-конкрет; фикер эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән төшенчәләргә атама булып, сигнификат-денотатлы, ягъни субъектлы-абстрактлы мәгънә тибы; бер сүзнең икенче сүз белән бәйләнешенә нигезләнеп, структур мәгънә тибы барлыкка килә.

Әлеге типларда лексик мәгънә сүз-лексема, сүз-форма, парлы сүз, сүзтезмә рәвешендә реальләшә ала.

3. Югарыда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, сүзлектә теркәлгән, ягъни статик халәттәге сүзнең лексик мәгънәсен барлаганда, аның турында фикер әйтергә омтылганда, сүзнең хәрәкәттәге хәленә, ягъни сөйләм берәмлеге буларак кулланылуына да игътибар итәбез. Әмма бу вакытта сүз һәм яңгырашы (язылышы), һәм формасы, һәм мәгънәсе ягыннан сөйләм таләп итә торган төрле үзгәрешләргә дучар ителгән була. Әлеге мәсьәләләр тел гыйлемендә морфонология, морфология, синтаксис тармакларында махсус өйрәнелә.

Сөйләм эченә килеп керү белән, сүзне сүз итеп формалаштыра торган морфемаларда фонетик үзгәрешләр барлыкка килә. «....Сөйләм процессында морфемалар төрле фонетик һәм морфологик чолганышта калалар, нәтиҗәдә, янәшә торучы морфемаларның фонетик составына бәйле рәвештә фонетик үзгәрешләр, чиратлашулар барлыкка килә» [Татар грамматикасы, 1998, б. 175]. «...Тел берәмлеге булган сүз, сөйләмгә килеп кергәч, күп төрле формаларны алып, сүзформа дип атала башлый. Сүзформа сөйләмдә сүзләрне үзара бәйләүче һәм модаль мәгънә белдерүче формаларны ала (анда нуль форма да булырга мөмкин). Мәсәлән, *шәһәр* – сүз, *шәһәргә, шәһәрнең, шәһәрне, шәһәрнеке, шәһәрдәге* һ.б. – сүзформа булалар. *Шәһәр бакчасы* дигәндәге *шәһәр* сүзе дә – сүзформа, төгәлрәк әйткәндә, нуль формалы сүзформа... Шулай итеп, сүз сөйләм агымында сүзформа буларак катнаша, сөйләмдә мәгънәле кисәк буларак аерылып тора. ...татар телендә бәйлекләр, кушымчалар кебек үк, сөйләмдә, алдагы сүзнең формасын тәшкил итеп, аннан сүзформа ясыйлар» [Татар грамматикасы, 1998, б. 162–163].

«…Синтаксисның өйрәнү объекты – сөйләм. Сөйләм ул колач җитмәслек чиксез бер күренеш, шуңа күрә аны гомумән алып өйрәнеп булмый», – дип, академик М.З. Зәкиев сөйләмне текст һәм җөмлә итеп аерып тикшерергә кирәклеген ассызыклый. Җөмләнең үзен эзлекле итеп өйрәнү барышында – сүзләр белән, җөмлә кисәкләре белән, җөмләдә сүзләр бәйләнешен тикшергәндә, сүзтезмәләр белән эш итәргә туры килә. Шуңа күрә синтаксиста, сөйләм берәмлекләре буларак, сүзләр, җөмлә кисәкләре һәм сүзтезмәләр дә сөйләмдә алган үзенчәлекләре белән бергә аерып чыгарыла [Татар грамматикасы, 1999, б. 12–13].

Шулай итеп, тел берәмлеге булган сүз-лексема, эш башкару процессында, сүзформа һәм сүзтезмә шәкелен дә алып, сөйләм берәмлеге буларак хәрәкәт итә башлый. Әлеге берәмлек морфология һәм синтаксис тармагында, һәр фәннең үз максат-бурычына туры китерелеп, махсус рәвештә тикшерелә, сүзләрнең төркемләнүе дә, аларның үзара бәйләнеше дә һәр телнең үз грамматик төзелешенә буйсынган хәлдә алып барыла.

Шуның белән бергә, бу хезмәтләрдә һәр сүзнең фәкать үз лексик мәгънәсен саклаган хәлдә генә әлеге грамматик төзелешкә буйсына алуы ассызыклана.

Сүзьясалыш кануннарын аңлатканда, лексик мәгънәнең саклануы хакында болай дип белдерелә: «...сүзьясалыш законнары һәм чаралары нигезнең лексик каршылыгы белән чикләнә, шунлыктан, кушымчалар һәр тамырга һәм нигезгә кушыла алмый, мәсәлән, *тара-, күрә-* дигән фигыль нигезләренә *-к* кушымчасы ялганып, *тарак, күрәк* дигән исемнәр ясала. Әмма шундый ук төзелештәге башка фигыльләрдән *-к* кушымчасыннан яңа сүзләр ясап булмый: *кайна-, калтыра-, кама-, күзә-*. Шулай ук теләсә нинди фигыль ярдәмче фигыль ярдәмендә кушма (тезмә) фигыль ясый алмый. Мәсәлән, бар фигыльленнән *җибәр* ярдәмче фигыль белән яңа тезмә фигыль ясап булмый (барып җибәрү?), гәрчә тезмә фигыльләрнең мондый моделе татар телендә киң таралган» [Татар грамматикасы, 1998, б. 203]. Яисә: «...Сүзләрнең лексик һәм грамматик каршылыгы нәтиҗәсендә һәр сүз теге яки бу кушма сүзнең компоненты була алмый» [Татар грамматикасы, 1998, б. 220].

Морфология дәреслекләрендә, мәсәлән, һәр сүз төркеменә хас булган грамматик-морфологик категорияләрне тикшерә башлаудан алда, әлеге сүз төркеменә берләшә торган сүзләрнең семантик төркемнәре турында мәгълүмат бирелә: «...Исемдә предметлык мәгънәсе үз эченә күп төрле төшенчәләрне туплый: конкрет һәм абстракт исемнәр, җыйма исемнәр, матдә исемнәре, ялгызлык һәм уртаклык исемнәр була», – дип, әлеге исемнәрдә чагыла торган морфологик үзенчәлекләрнең сүзнең лексик мәгънәсенә бәйле булуы әйтелә: «Конкрет исемнәрне берлектә дә, күплектә дә кулланып булса, абстракт исемнәр гадәттә берлек формасында кулланыла. Берлектә дә, күплектә дә куллану

исемнәрнең семантик (мәгънәви) төркемчәләренә бәйле», – дип әлеге бәйләнешнең нинди булуы аңлатыла [Татар грамматикасы, 2002, б. 38].

Фигыль сүз төркеменә мөнәсәбәтле рәвештә дә бу мәсьәләгә махсус басым ясала. Лексик мәгънәгә бәйле рәвештә кайбер сүзләр грамматик мәгънәгә яңа төсмерләр өсти, аны үзгәртә алалар, кайбер грамматик категорияләрне алар бөтенләй кабул итми, яки аларның төрләнеше чикләнгән була [Татарская грамматика, 1993, с. 73; Татар грамматикасы, 2002, б. 92–101].

Аңлашылганча, сүзләр, грамматик мәгънә нигезендә, морфологик берәмлек, ягъни аерым сүз төркемнәре булып берләшкәндә, үзләренең индивидуаль мәгънәсен дә югалтып бетермичә, киресенчә, аны саклаган хәлдә, гомумиләшә һәм морфологик яктан формалашкан уртак мәгънәнең (предметлык, процесслык, билге, сан һ.б.) семантик разряды – парадигмалары булып яшәешен дәвам итә икән. Бу хәл, бигрәк тә, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык кебек сүз төркемнәрендә, аларның һәрберсенең үзенә хас лексик-семантик парадигмаларында ачык чагыла.

Шулай итеп, индивидуаль лексик мәгънәсен саклаган хәлдә, гомум-уртак грамматик мәгънә нигезендә берләшү процессында, шул мәгънәне чагылдыра торган формалары белән берлектә, һәр төркемнең үз табигатенә туры килгән һәм аны хасил итә торган үз категорияләре яшәеш ала. Бу категорияләр, шул гомум-уртак мәгънәнең грамматик парадигмаларын тәшкил итә. Билгеле булганча, предметлык дигән гомумиләшкән грамматик мәгънәгә сан, тартым, килеш; процесслык дигән грамматик мәгънәгә наклонение, заман, барлык-юклык, зат-сан дигән морфологик һәм тагын лексик-грамматик дигән юнәлеш һәм дәрәҗә категорияләре хас була.

Грамматика дәреслекләрендә ассызыклап белдерелгәнчә, бер төркем сүзләргә хас булган уртак грамматик мәгънә лексик-семантик яктан төрле парадигма тәшкил итә торган сүзләрнең бергә туплана алуына нигезләнә. Мәсәлән, предметлык мәгънәсе конкрет һәм абстракт мәгънәле, әйбер-матдә һәм җыймалык мәгънәсен белдерә торган сүзләрдә чагыла.

Процесслык дигән грамматик мәгънәне өйрәнгәндә, иң башта аның грамматик булмаган, фигыль-сүзләрнең табигый семантикасын белдерә торган төркемнәре-парадигмалары булуына басым ясала. Болар: а) лексик мәгънәнең гомумиләшүенә нигезләнгән эшне, хәрәкәтне, хәлне, фикерләүне, сөйләүне һ.б. аңлата торган тематик төркем, ә) мәгънәнең нинди булуына карап, мөстәкыйль мәгънәле һәм ярдәмче мәгънәле фигыльләр, б) эш-хәрәкәтнең, процессның объектка юнәлдерелгән яки юнәлдерелмәгән булуы ягыннан – күчемле һәм күчемсез, в) мәгънә чигенең белдерелүе яки белдерелмәвенә карап, чикле һәм чиксезлекне белдерә ала торган фигыльләр [Татарская грамматика, 1993, с. 73].

Димәк, предметлык һәм процесслык дигән грамматик мәгъ-

нәләр, бер яктан, сүзләрнең лексик-семантикасына нигезләнгән парадигмаларында, икенче яктан, аларның гомумиләшкән грамматик мәгънәләренә нигезләнгән парадигмалары белән яшәештә була. Аерым бер сүзнең мәгънә эчтәлеге сүзформа һәм сүзтезмә халәтендә реальләшкәндә, менә шушы ике төрле парадигманың һәркайсына хас булган үз табигате, үз үзенчәлеге дә саклана, ягъни грамматик мәгънәнең реальләшүе аның үз формасына да, шул ук вакытта, әлеге форманы кабул итә торган сүзнең кайсы семантик төркемгә каравына да бәйле була. Бер үк грамматик форманың төрле мәгънә белдерә алуы да, асылда, лексик һәм грамматик өлкәләрнең үзара мөнәсәбәтенә нигезләнә.

Шулай итеп, алда әйтеп үтелгәнчә, сүзнең лексик мәгънәсенең эчтәлеген үзара ныклы бәйләнеш-мөнәсәбәттә булган өч фактор хасил итә: а) чынбарлыктагы предметларның гомумиләштерелеп чагылуына һәм аларның үзара бәйләнешенә нигезләнеп барлыкка килгән логик-предметлык һәм фикерләүтөшенчәле эчтәлек (сүзмәгънә), б) әлеге логик-предметлык-төшенчәле эчтәлекнең аны реальләштерә һәм яңарта торган грамматик чараларның үзенчәлеге һәм закончалыгы белән формалашуы (сүзформа), в) аерым бер сүзнең сүзлектәге башка сүзләр белән мөнәсәбәтен хасил итә торган бәйләнешләр (сүзтезмә). Аңлашылганча, әлеге өч факторның һәрберсе икенчесе белән дә, үз эчләрендәге элементлар белән дә катлаулы бәйләнеш-мөнәсәбәттә тора. Сүзмәгънә дигәндә, сүзнең объектлы-денотатив, субъектлы-сигнификатив бәйләнеш-мөнәсәбәтләренә нигезләнгән, тик торган халәттәге-субстанциональ мәгънәсе; сүзформа дигәндә, бер индивидуаль мәгънәгә ия сүзнең, аерым төркем сүзләргә хас булган предметлык, процесслык, билгелек һ.б. гомумиләштерелгән грамматик мәгънәләрне кабул итәргә сәләтле булуы; сүзтезмә дигәндә, әлеге индивидуальлеге сакланган һәм гомуми грамматик мәгънәгә төренгән сүзнең синтагма эчендәге урынын һәм мәгънәсен билгели торган бәйләнешләре күз алдында тотыла.

Сүзнең сүзформа һәм сүзтезмә халәтендәге бәйләнеш-мөнәсәбәтләре телнең морфология һәм синтаксис тармакларында, сүзнең индивидуаль үз мәгънәсе һәм башка сүзләр мәгънәсе белән бәйләнеш-мөнәсәбәте лексикологиянең бер тармагы булган семасиологиядә тикшерелә.

Бәйләнеш дигәндә, бәйле элементларның бер-берсенә булган тәэсире, мөнәсәбәт дип әйткәндә, бәйле элементларның үзара охшаш һәм ермалы яклары истә тотыла.

**Әдәбият**

*Арнольд И.В.* Семантическая структура слова в современном английском языке и методика ее исследования. М.: Просвещение, 1966. 192 с.

*Ахманова О.С.* Словарь лингвистических терминов. М.: Сов. Энциклопедия, 1969. 608 с.

*Виноградов В.В.* Избранные труды. Лексикология и лексикография. М.: Наука, 1977. 310 с.

*Виноградов В.В.* Основные типы лексических значений слов // Вопросы языкознания. 1953. № 5. С. 3–30.

*Звегинцев А.А.* Семасиология. М.: МГУ, 1957. 321 с.

Лингвистический энциклопедический словарь. М.: Советская энциклопедия., 1990. 216 с.

*Лопатникова Н.И., Мовшович Н.А.* Лексикология французкого языка. М.: Высшая школа, 1982. 132 с.

*Мартынов В.В.* Категории языка. Семиологических аспект. М.: Наука, 1982. 192 с.

*Никитин М.В.* К типологии значений в естественном языке // Ученые записки Владимирского гос. пед. университета, серия «Иностранные языки», вып. 4, т. 24., 1970. С.158–226.

*Никитин М.В.* Лексические значение в слове и словосочетания. Владимир, 1974. 222 с.

*Сабиров К.С.* Лексикология // Современный татарский литературный язык. М. : Наука, 1969. С. 52–80.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология: югары уку йорты студентлары өчен. Казан: Хәтер, 1999. 288 б.

*Смирницкий А.И.* Значение слова // Вопросы языкознания, 1955. № 2. С. 79–89.

*Смирницкий А.И.* Лексикология английского языка. М.: Изд-во литературы на иностранных языках, 1956. 260 с.

*Степанов Ю.С., Эдельман Д.И.* Семиологический принцип описания языка // Принципы описания языков мира. М., 1976. С. 7–28.

Татарская грамматика: в 3-х томах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. Т. 2. Морфология. 397с.

Татар грамматикасы: өч томда. Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998. Т. 1. 512 б.

Татар грамматикасы: өч томда. Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1999. Т. 3. 512 б.

Татар грамматикасы: өч томда. Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 2002. Т. 2. 448 б.

*Уфимцева А.А.* Семантика слова // Аспекты семантических исследований. М.: Наука, 1980. С. 5–81.

*Уфимцева А.А.* Лексическое значение. Принцип семиологического описания лексики. М.: Наука, 1986. 199 с.

*Шмелев Д.Н.* Очерки по семасиологии русского языка. М.: Просвещение, 1964. 244 с.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомум лингвистика бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145´35

***Н.В. Максимов***

# СӨЙЛӘМ ТЕЛЕНӘ ҺӘМ ЯЗУГА БЕР КАРАШ

Статья рассказывает о первом опыте создания алфавита на основе кириллицы для кряшенского говора татарского языка во второй половине XIX века. Раскрывается вклад основных деятелей этого процесса из крещенотатарской среды.

**Ключевые слова:** кряшенский говор татарского языка, татарская письменность на основе кириллицы, диалекты и говоры татарского языка.

Рус прогрессив педагогикасы үз вакытында Россиядә яшәгән рус булмаган халыкларның, шул исәптән, татар халкының бер үзенчәлекле төркеме булган керәшеннәрнең педагогик фикере үсешенә уңай йогынты ясаган. XIX гасырның 60 нчы елларындагы революцион-демократик хәрәкәтнең, рус педагогикасының күренекле вәкилләре К.Д. Ушинский, Л.Н. Толстой, Н.И. Ильминский, Н.Ф. Катанов, Е.А. Малов, Н.П. Остроумов, В.В. Григорьев кебек галимнәрнең ярдәме белән керәшеннәр арасыннан *Тимофеев Василий Тимофеевич* (1836–1896), *Горохов Василий Михайлович* (Казанда Укытучылар семинариясен тәмамлаган. 1918–1922 елларда – Керәшен укытучылары мәктәбе директоры, 1922 елдан Керәшен педтехникумы директоры, 1930 елдан КДПИның педагогика кафедрасында мөдир), *Григорьев Александр Николаевич* (Казанда Укытучылар семинариясен тәмамлаган. 1920 елларда Керәшен педтехникумында укыта, 30 нчы еллардан КДПИда доцент. СССР ФА ТӘһТИын оештыручыларның берсе), *И. Кондратов* (русларга – русча-татарча, татарларга татарча-русча сүзлектән файдаланып, татар телен өйрәтү өчен кулланма буларак төзелгән «Новый практический самоучитель татарского языка» (Казань, тип. Имп. Ун-та, 1893. 90 с.) авторы. 1901, 1904, 1911, 1914 елларда аның 2–6 басмалары дөнья күрә), *Абрамов Павел Васильевич* (КФЭИ ректоры, кафедра мөдире, профессор. «Экономическая география Татарстана» дигән фәнни хезмәт авторы), *Агачев Павел Васильевич* (Казан авиация техникумында «Высшая математика» фәне укытучысы. Техникумнар өчен «Высшая математика» дәреслеген төзегән), *Алексеев Игнатий Алексеевич* (1917–1918 елларда Казанда Төп Керәшен мәктәбе укытучысы. Соңрак югары техник уку йортлары һәм техникумнар өчен 900 биттән торган «Высшая математика» дәреслеген татар телендә язган беренче автор) кебек мәгърифәтчеләр һәм галимнәр үсеп чыга.

1862–1963 елда Казан шәһәрендә керәшеннәр өчен беренче

мәктәп ачыла. Мәктәпнең фәнни һәм методик яктан эшчәнлеге тиешле дәрәҗәдә алып барылсын өчен, куратор итеп, танылган рус галимнәре Н.И. Ильминский, Н.П. Остроумов, А. Воскресенский һ.б. билгеләнә.

Шуны онытмаска кирәк: Н.И. Ильминский, нигездә, урыннарда керәшен мәктәпләрен ачу һәм аларда эшне оештыру, эшнең матди яктан тәэмин ителеше белән шөгыльләнгән. Мәктәп укучылары өчен укыту әсбапларын һәм укытучылар өчен методик ярдәмлекләрнең барысын да Тимофеев җитәкчелегендә керәшен укытучылары русчадан тәрҗемә иткән яки үзләре язган.

Көн тәртибенә кирилл графикасы нигезендә алфавит төзү, керәшен сөйләшендә уку һәм язу үрнәкләре булдыру мәсьәләсе килеп баса. Н.И. Ильминский, Н.П. Остроумов, В.Т. Тимофеевлар һәм алар әзерләгән керәшен укытучылары тарафыннан, бу вакытта үз язулары булмаган керәшеннәр өчен, кирилл хәрефләренә нигезләнеп, керәшен алфавиты төзелә. Әкренләп, керәшеннәрдә язу үрнәкләре барлыкка килә, керәшеннәрнең язма теле, керәшен сөйләшенә нигезләнеп, кирилл язуында формалаша һәм үсә башлый. В.Т. Тимофеевның укучысы Емельянов Яков Емельянович (1848–1893) 1877 елда Казанда керәшен сөйләшендә «Дарҗа әби кенәгәсе» дигән шигырьләр җыентыгын бастырып чыгара.

Керәшен язуында 9 сузык, 17 тартык авазның билгесе теркәлгән.

<table>
<tr><td>Остроумов алфавитында</td><td>Бүгенге татар алфавитында</td><td>Остроумов алфавитында</td><td>Бүгенге татар алфавитында</td></tr>
<tr><td colspan="2">сузык аваз билгеләре</td><td colspan="2">тартык аваз билгеләре</td></tr>
<tr><td>А а</td><td>А а</td><td>Б б</td><td>Б б</td></tr>
<tr><td>Ӓ ӓ</td><td>Ә ә</td><td>В в</td><td></td></tr>
<tr><td>У у</td><td>У у</td><td>Г г</td><td>Г г</td></tr>
<tr><td>Ӱ ӱ</td><td>Ү ү</td><td>Д д</td><td>Д д</td></tr>
<tr><td>О о</td><td>О о</td><td rowspan="5">Җ җ</td><td>Җ җ</td></tr>
<tr><td>Ӧ ӧ</td><td>Ө ө</td><td>Й й</td></tr>
<tr><td>Ы ы</td><td>Ы ы</td><td>Е е</td></tr>
<tr><td>Э э</td><td>Э э</td><td>Я я</td></tr>
<tr><td>И и</td><td>И и</td><td>Ю ю</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>З з</td><td>З з</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>К к</td><td>К к</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td>Х х</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Л л</td><td>Л л</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>М м</td><td>М м</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Н н</td><td>Н н</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>П п</td><td>П п</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td>Ф ф</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Р р</td><td>Р р</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>С с</td><td>С с</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Т т</td><td>Т т</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Ч ч</td><td>Ч ч</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Ш ш</td><td>Ш ш</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>ң</td><td>ң</td></tr>
</table>

Шушы алфавитка нигезләнеп, 1876 елда Казанда В.Т. Тимофеев, Н.И. Ильминский, А.А. Воскресенский, Н.П. Остроумов тарафыннан төзелгән «Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещённых татар Казанской губернии» дигән, 1892 елда исә керәшеннәр өчен икенче сүзлек – «Татарско-русский словарь» басылып чыга.

Шунысы игътибарга лаек: шул вакытта Мамадыш һәм Лаеш өязендә (*Лаеш өязенә ул вакытта хәзерге Питрәч, Балык*

*бистәсе, Теләче, Саба районнары – керәшеннәр иң күп яшәгән районнар да кертелгән*) яшәгән керәшеннәр сүзләрне ничек әйтеп сөйләшкән булса, сүзлек, нигездә, шулай, фән телендә әйтсәк, фонетик принципка нигезләнеп, керәшеннәр катнашында төзелгән. Фонетик принципка нигезләнеп язу ул – сүздәге авазларны ишетелгәнчә язу, дигән сүз.

Татар әдәби теленең төп фонетик һәм орфоэпик нормалары формалашуда керәшен сөйләше, керәшен мәктәпләрендә эшләгән укытучылар тарафыннан төзелгән укыту әсбапларында һәм методик ярдәмлекләрдә сүзләрнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлеге ни дәрәҗәдә исәпкә алынган? Гомумән, алар исәпкә алынганмы?

Бу сүзлек үз чорында, фәнни яктан кыйммәтен бүгенге көннән карап бәяләсәк, керәшен укучылары һәм укучылары өчен орфографик, орфоэпик, аңлатмалы сүзлек вазыйфаларын үтәгән. Бу сүзлек XVIII йөзнең беренче яртысында И. Гиганов (1801) һәм А. Троянскийның (1833, 1835) 2 томлы сүзлекләренә нигезләнеп, XX гасырның 20–40 нчы елларында Н. Катанов (1912), С. Рахманколый (1913), М. Корбангалиев, Р. Газизов, И. Кулиев (1931) кебек яңа буын һәм яңа заман татар тел галимнәре тарафыннан татарча-русча сүзлекләр төзелгән.

Сүзлекнең үзенчәлеге тагын нәрсәдә, дисәк, беренче чиратта, ул борынгыдан килгән керәшен сөйләшенең үзенчәлеген исәпкә алып төзелгән, керәшен сөйләшенең яңгырашы сакланып калган кадерле тарихи язма истәлек, һәм керәшеннең 1865 еллардан ук формалашкан язма теле булганлыкка бер дәлил.

Фонетик принципка нигезләнеп, сүз башында килгән **е, й, я, ю** хәрефләре иҗек ясаучы буларак язылган иҗекләрдә **җ** хәрефе язылган: ***җабык*** *– ябык,* ***җаз*** *– яз,* ***җак*** *– як,* ***җака*** *– яка,* ***җакын*** *– якын,* ***җалган*** *– ялган,* ***җапрак*** *– яфрак,* ***җарканат*** *– ярканат,* ***җаулык*** *– яулык, җегерме – егерме,* ***җук*** *– юк,* ***җумарт*** *– юмарт,* ***җурган*** *– юрган,* ***җукә*** *– юкә* һ.б.

Керәшен сөйләшендә [h] авазы булмаганлыктан, сүзлектә бу авазның билгесе теркәлмәгән. Бүгенге татар телендә кулланылышта булган *һәм, һәммә, һәр, һәрбер, һаман, һич* кебек язылыштагы сүзләр керәшеннәрдә ***әм, әммә, әр, әрбер, аман, ич*** формасында әйтелгән, соңрак шул ук формада керәшенчә язылышка да кертелгән.

Сүзлектә гарәп һәм фарсы теленнән кергән сүзләр дә теркәлгән, шунысы игътибарга лаек: алынмалар, әйтелешкә тәңгәлләштерелеп, калын формада сингармонизм законына яраклаштырып теркәлгән: ***җамагат*** *– җәмәгать,* ***кагаз*** *– кәгазь,* ***кадар*** *– кадәр,* ***куат*** *– куәт,* ***сагат*** *– сәгать,* ***гаеб*** *– гәеп,* ***гонаг*** *– гөнах,* ***карындаш*** *– карендәш,* ***җугыйса*** *– югыйсә* һ. б.

Керәшен сөйләме, беренчедән, тулысынча сузыклар гармониясенә нигезләнеп төзелгән сүзләрдән торганга, икенчедән, сүз башында һәм сүз уртасында **е, я, ю** хәрефләре килгән сүзләрдә сузыкларның калын яки нечкә укылышын күрсәтү кирәк

булмаганга, алфавитта **ь** һәм **ъ** билгеләре бөтенләй теркәлмәгән.

Сүзлектә ирен-ирен тартыгы [ф] рус теленнән алынган сүзләрдә дә, гарәп һәм фарсы алынмаларында да керәшен сөйләшендәге [п] тартыгы белән, [х] тартыгы исә [**к**] яки [**къ**] тартыгы белән бирелә. Мәсәлән:

[**п**] = [**ф**]: ***җапрак*** *– яфрак,* ***пайда*** *– файда,* ***панар*** *– фонарь* һ.б.;

[**къ**] һәм [**к**] = [**х**]: ***җакшы*** *– яхшы,* ***каста*** *– хаста,* ***кезмят*** *– хезмәт,* ***кайран*** *– хайран,* ***калык*** *– халык,* ***камыт*** *– хомут,* ***кан*** *– хан,* ***канҗар*** *– хәнҗәр,* ***катын*** *– хатын,* ***кодай*** *– кодай,* ***көрмят*** *– хөрмәт,* ***кәтер*** *– хәтер* һ.б.

Сүзлектә тел белгечләре игътибарга алырлык тагын бер күренеш бар. Ул – контактлы ассимиляциянең үзенчәлекле чишелеше, ягъни хезмәттә янәшә килгән [н] һәм [г], [гъ], [к], [къ] авазларының үзара тәэсир итешү очрагы сүзләрне үзенчәлекле язу нигезендә хәл ителгән. Мондый очракларда, кайбер сүзләрнең уртасында, [н] авазына [г] авазы тәэсир итүдән, [ң] авазы ишетелсә дә, язуда ул махсус хәреф белән күрсәтелми: ***бәрәнге*** *– бәрәңге,* ***дингез*** *– диңгез,* ***дунгыз*** *– дуңгыз,* ***конгорт*** *– коңгырт,* ***кынгырау*** *– кыңгырау,* ***җалангач*** *– ялангач,* ***мангай*** *– маңгай* һ. б.

Керәшен алфавитында **ң** хәрефе өчен махсус билге бирелгән. Сүзлектә ул хәреф бер иҗекле сүзләрнең ахырында (*мең, миң, җиң, таң*), ике иҗекле сүзләрдә – беренче иҗек ахырында (*җаң + гыз, җаң + гыр*) яки икенче иҗек башында гына (*җа + ңа, җа + ңак, и + ңеш*) язылган.

Татар тел белемендә бүгенгә кадәр *ирен гармониясе* дигән төшенчә ачыкланып җитмәгән. XX йөзнең беренче яртысында эшләгән тел галимнәре тарафыннан әйтелгән: «*Татар сүзенең беренче иҗегендәге иренләшкән авазга ярашып, калган иҗекләрдәге сузыклар да иренләшә*» дигән фикер кагыйдәләштерелгән.

Татар телендә иренләшү гармониясе, нигездә, сүзнең беренче иҗегендәге [о] һәм [ө]авазлары белән бәйләп аңлатыла. Кагыйдә буенча «*калын сүзләрнең беренче иҗегендәге* [*о*] *авазы – икенче иҗектәге* [*ы*] *авазын, нечкә сүзләрнең беренче иҗегендәге* [*ө*] *авазы икенче иҗектәге* [*э*] *авазын яраштыра*». Һәм, мисал итеп, барлык фәнни һәм методик хезмәтләрдә, «Татар теле» дәреслекләрендә, укытучылар өчен төрле елларда язылган методик хезмәтләрдә традицион рәвештә ике иҗектән генә торган ***болыт***, ***колын***, ***төлке***, ***сөлге*** кебек сүзләр, транскрипциядә шул сүзләрнең әйтелеш һәм укылыш формасы китерелә: [***болот***], [***къолон***], [***төлкө***], [***сөлгө***] һәм мондый сүзләрдә басымның икенче иҗеккә төшүе турында әйтелә.

Кагыйдәдә тәкъдим ителгән *болыт*, *төтен* формасында язылган сүзләр, нигездә, тамыр сүзләр. Аларга, исем буларак, тартым кушымчасы ялгана ала: ***болыт + ы***, ***төтен + е;*** *-лы* яки *-ле* кушымчасы ялганып, сыйфат та ясалырга мөмкин: ***болыт + лы***, ***төтен + ле***. Кагыйдә буенча ирен гармониясенең «икенче иҗектә тулы булып, өченче иҗектән кими баруы, дүртенче иҗектә исә бөтенләй бетүе» ту-

рында әйтелә. Ягъни, кагыйдәгә нигезләнсәк, ***болыты*** һәм ***төтене***, ***болытлы*** һәм ***төтенле*** кебек өч иҗекле сүзләрне [***болоты***], [***болотлы***] һәм [***төтөнә***], [***төтөннә***] формасында әйтергә һәм укырга тиеш булабыз.

Тагын бер мисал. Кагыйдә буенча өч иҗекле ***өтерге*** сүзенә, *-се* – тартым яки *-не* төшем килеше кушымчасы ялганганда, сүз [***өтөргэсэ***], [***өтөргэнэ***] формасында әйтелергә һәм укылырга тиеш була. Ягъни телебездәге мондый сүзләрне бер төрле язабыз, ясалма законга яраклаштырып әйтәбез һәм сөйләшәбез.

Бу сүзләргә, беренчедән, кушымча ялганган саен, басым ялганган кушымчага күчә бара. Икенчедән, басым төшкән иҗектәге [о] яки [ө] авазының өченче һәм дүртенче иҗекләрдә [ы] яки [э] авазына үзгәрүе мөмкин түгел, чөнки иренләшү гармониясе дигән төшенчә үзе [о] һәм [ө] авазларын артикуляция аппаратының эшләү рәвешенә яраклаштырудан барлыкка килгән күренеш. Шуңа күрә ул *о*-лаштыру һәм *ө*-ләштерү дип атала, беренче һәм икенче иҗеккә генә түгел, сүздәге барлык иҗекләргә дә карый.

Тимофеев катнашында төзелгән сүзлекләрдә исә ирен гармониясе, керәшен сөйләшенең борынгыдан килгән сөйләм үзенчәлеге буларак, тулысы белән үзен аклап, калын һәм нечкә әйтелешле ике һәм өч, хәтта дүрт иҗекле сүзләрдә дә артикуляция аппаратының – эшләү, басымлы иҗектәге **[о]** һәм **[ө]** авазларының әйтелү үзенчәлегенә нигезләнеп хәл ителгән. Мисал өчен:

| Ике | Өч | Дүрт |
|---|---|---|
| иҗекле сүзләр | | |
| короч<br>орлок<br>бөйөр,<br>җөзөк,<br>көмөш<br>көчөк<br>бөртөк<br>бөтнөк<br>дөрөс<br>мөгөз<br>өрлөк<br>бөрлөгән<br>өчөн<br>җондоз<br>җоморка | бойорок<br>койорок<br>мөгөзлө<br>җодорок<br>җоморо | чөйөлдөрөк |

Татар теле укытучысы укучыларга мондый сүзләрнең язылышы белән укылышы туры килмәгәнне еллар дәвамында (унбер ел) аңлата. Укытучы, диктант яздырганда, тексттагы *борыны* дигән сүзне тиешенчә, ягъни орфоэпик нормалар таләп иткәнчә әйтсә, укучы *бороно* дип ялгыш язып куя; укытучы орфоэпик нормаларны бозып, сүзне язылганча әйтсә генә, укучы сүзне дөрес яза ала. Фәнни һәм методик чыганакларда моңа охшаш «ясалма» кагыйдәләр яшәп килгәндә, укучы язган текстның сыйфат ягы укытучылар көткән нәтиҗәне бервакытта да бирә алмый, билгеле. Укытучылар да, укучылар да – барысы да кагыйдәне яхшы белә, сөйләшкәндә генә «үзенчә» – татарча, мишәрчә, керәшенчә буталалар: [***борын***], [***брын***], [***бырын***], [***борон***]; [***төлке***], [***тлкэ***], [***тэлкэ***], [***төлкө***] дип сөйләшәләр. Ничек сөйләшсәләр, еш кына, шулай язалар да.

Укучыларның бер өлешен («5»ле һәм «4»ле билгесенә укучыларны) язу нормаларына

күндерергә мөмкин (дөрес язмасаң, эшеңә «2»ле билгесе куела!), ләкин төрле диалектларга һәм этник төркемнәргә караган халыкны ясалма кабул ителгән әдәби сөйләм нормаларына ияләндерү һәм күнектерү мөмкин эш түгел. Бала, теле ачылганчы, бабасы һәм әбисе, әтисе һәм әбисе, абыйсы һәм апасы сөйләшкәнне ишетә; сөйләшә башлагач – өйдә; мәктәпне тәмамлагач, туганнары һәм авылдашлары, кардәшләре арасында сүзләрне «бабалары сөйләшкәнчә» әйтеп сөйләшә башлый, ясалма кагыйдәләргә буйсынмый.

Татар тел белгечләренең (Л. Җәләй, Ф. Юсупов, Ф. Баязитова, Д. Бәйрәмова, Ф. Сафиуллина һ.б.) язуына караганда, татарлар үз эчендә тел үзенчәлекләре буенча – өч: урта, көнбатыш, көнчыгыш диалектка һәм кырыкка якын сөйләшкә; динне тоту ягыннан – ислам һәм христиан динен тотучыларга бүленә. Христиан динен тотучылар ул – керәшеннәр.

Татар теленең бүгенгә килеп җиткән фонетик, орфографик һәм орфоэпик нормаларына карата ике сорау туа. Беренчесе, татар әдәби теленең сөйләм һәм язу нормалары формалашуда кайсы диалектлар төп рольне уйнаган? Икенчесе, татар әдәби теленең төп сөйләм һәм язу нормалары XX йөзнең 40–50 нче елларына, чынлап та, формалашып җиткән булганмы, әллә шул чордагы кайсыдыр билгеле тел галимнәре кулы белән тиз генә һәм ясалма рәвештә «формалаштырылган»мы?

Л. Җәләй «Татар теленең орфоэпик нигезләре» дигән хезмәтендә (1953) «Татар орфоэпиясенең төп нормалары **урта диалектның Казан арты сөйләшенә нигезләнгән**», – дип язган. Урта диалект һәм Казан арты сөйләше, димәк.

Г. Әхәтовның «Татар диалектологиясе» (1984) дигән хезмәтендә исә: «Хәзерге татар әдәби теле **урта диалектка һәм шулай ук мишәр диалектына нигезләнеп барлыкка килә.** Икенче төрле әйткәндә, татар әдәби теленең төп фонетик, грамматик һәм лексик нормалары шушы ике диалектка нигезләнеп алына», – дип язылган.

**Диалект** ул – аерым бер төбәк, урын халкына, кешеләренә хас сөйләш; **диалекталь** – берәр диалектта кулланыла торган, берәр диалектка хас булган сүзләр, авазлар һ.б. (ТТАС, 2005. 143 б.)

Татар тел галимнәренең хезмәтләрендә укучы бер сорауга әле дә булса җавап таба алмый: татар теленең, татар милләтенең теле формалашуга керәшен сөйләшенең тәэсире булганмы?

Казан арты һәм Көнбатыш диалектларның төп үзенчәлекләренә, ягъни татар һәм мишәр сөйләше үзенчәлекләренә игътибар итсәк, аларда аерма шактый зур икәнлеге күзгә ташлана.

| Диалектларның төп үзенчәлеге | |
|---|---|
| Урта диалект | Көнбатыш диалект |
| җ-ләштерүнең актив булуы [й]-лаштыруның пассив булуы | җ-ләштерүнең булмавы, [й]-лаштыруның актив булуы |
| [а] авазының басымсыз иҗекләрдә [о]-лаштырып әйтелүе | [а] авазының басымсыз иҗекләрдә [о]-лашмавы |

Заманында урта һәм көнбатыш диалектта яшәгән халыкларның (ягъни Казан арты татарларының һәм мишәрләрнең) сөйләшен татарча дөрес язу һәм дөрес уку кагыйдәләре өчен нигез итеп алганда, тел галимнәре тарафыннан охшаш яки бик үк якын тормаган тел күренешләрен яраклаштыру кебек эш башкарылган. Татарның язуы да, сөйләме дә бүгенгә кадәр, бәлки, шуңа күрә камил түгелдер.

Хәзерге татар әдәби телендә татарча дөрес язу һәм дөрес уку, нигездә, фонетик принципка корылган. Фонетик принцип ул – сүздәге авазларны ишетелгәнчә язу, язылганны хәрефен авазга туры китереп уку, дигән сүз.

Сүзлектә **е** хәрефе иҗек уртасында һәм азагында [э] авазы әйтелгән урыннарда язылган:

*эчемчек, эремчек, терекле, телем, тере* һ.б.;

*печян, тегермян, тигяняк, өстял, өйрят.*

*кюкерт, кюл, кюлмяк, кюпер, кюмер*

*кюлягя, кюмяч.*

Сүзебезне шундый сорау белән төгәллисе килә: керәшен сөйләшенең этник тамырлары хәзерге чордагы кайсы телләр белән тоташа, кайсы телләргә якын?

***Максимов Николай Валентин улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының татар теле һәм татар телен укыту методикасы кафедрасы доценты*

УДК 811.512.1

***Х.Ч. Алишина***

# ПРОФЕССОР Д.М. НАСИЛОВ – БОРЫНГЫ УЙГУР ТЕЛЕ ҺӘМ ЯЗУЫ БУЕНЧА РОССИЯДӘ БЕРДӘНБЕР БЕЛГЕЧ

Статья посвящена юбилею доктора филологических наук, профессора, заведующего кафедрой тюркской филологии Института стран Азии и Африки МГУ им. М.В. Ломоносова, заместителя председателя Российского комитета тюркологов при отделении историко-филологических наук РАН, главного редактора журнала «Российская тюркология» Дмитрия Михайловича Насилова. В конце статьи приводится список основных научных трудов ученого.

**Ключевые слова:** кафедра тюркской филологии МГУ, институт стран Азии и Африки, факультет татарской филологии, восточных языков и истории КГУ, Д.М. Насилов, Г.Ф. Благова, Д.Г. Тумашева, татарская грамматика, глагольные категории.

Россиянең күренекле тюркологларының берсе, М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының (МДУ) Азия һәм Африка илләре институтындагы төрки филология кафедрасы мөдире, Россия тюркологлары комитеты рәисенең урынбасары, «Российская тюркология» журналының баш мөхәррире, филология фәннәре докторы, профессор Дмитрий Михайлович Насилов быел үзенең 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

Д. Насилов 1935 елның 18 мартында Мәскәү өлкәсенең Зарайск шәһәрендә интеллигентлар гаиләсендә туа. Һөнәр сайлауда аңа якын туганы, күренекле галим-тюрколог, педагог, профессор, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе Владимир Михайлович Насиловның йогынтысы зур була. Д. Насилов үзенең бөтен гомерен төрки телләрне өйрәнүгә багышлый. МДУның филология факультеты көнчыгыш телләр бүлегенә укырга кереп, ул бүгенге (төрек, үзбәк) һәм борынгы төрки телләр буенча белгеч һөнәрен үзләштерә. Монда илебез тюркологларының күренекле вәкилләре белем алган. Шуларның берсе – себер татарларының телен фәнни өйрәнүгә нигез салган, Казан дәүләт университеты профессоры, Татарстан фәннәр Академиясенең хокукый әгъзасы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Татарстанның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты, СССР (хәзер Россиянең) тюркологлар комитеты оешканнан бирле аның әгъзасы булган, Төрек лингвистик җәмгыятенең (Türk Dil Kurumu) мактаулы әгъзасы Диләрә Гариф кызы Тумашева. Ул биредә 1944–1949 елларда укый.

Насиловның студент еллары Көнчыгышта милли-азатлык хәрәкәтенең күтәрелеш чорларына туры килә. Илебез өчен төрки

телләр буенча югары квалификацияле белгечләр кирәк була. Дмитрий 1958 елда университетны кызыл дипломга тәмамлый һәм «көнчыгыш телләре белгече – филолог, филология фәннәре өлкәсендә фәнни хезмәткәр, югары уку йортында укытучы» белгечлегенә ия була.

СССР Мәгариф министрлыгы юлламасы буенча Д. Насилов Үзбәкстанга китә һәм 1958–1960 елларда Сәмәрканд университетының үзбәк теле кафедрасында укытучы булып эшли. 1964 елда Мәскәүдә Тел белеме институтында аспирантура тәмамлый һәм «Структура времени индикатива в древнеуйгурском языке (по памятникам уйгурского письма)» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Бүгенге көнгә кадәр ул Россиядә борынгы уйгур теле һәм язуы буенча бердәнбер белгеч.

1963 елдан Д. Насиловның 30 еллык максатчан фәнни эшчәнлеге Тел белеме институтының Ленинград бүлеге (Хәзер Россия Фәннәр Академиясенең Лингвистик эзләнүләр институты) белән бәйләнгән. Бирегә аны алтай телләре секторы белән җитәкчелек итү өчен эшкә чакыралар. Галим бик сирәк фәнни эш – «Борынгы төрки сүзлек» редакторларының берсе, мәкаләләрнең авторы була. В.В. Радлов, С.Е. Малов кебек күренекле галимнәр төзи башлаган әлеге сүзлеккә төрки халыкларның 6000 сүзе кергән. Бу елларда Д. Насилов төрки филология өлкәсендә күренекле галимнәрнең берсе булып таныла, төрки телләрнең теоретик грамматикасын өйрәнүгә зур өлеш кертә, алтай телләрендәге фигыльнең грамматик категориясен җентекләп тикшерә.

Д.М. Насилов фәнни эшчәнлегенең төп юнәлеше – фигыль категорияләре темасы. Минем фәнни эшемнең җитәкчесе академик Диләрә Тумашева да озак еллар дәвамында бу теманы тәфсилләп өйрәнде. Яшь аермалары зур булуга карамастан, Россиянең танылган ике тюркологын – Тумашева белән Насиловны – күпьеллык иҗади дуслык берләштерә, укыган факультетлары, фән өлкәсендәге уртак кызыксынулары, үзләренә белем биргән танылган укытучыларын ярату, хөрмәт итү берләштерә.

1990 елда Д. Насилов «Төрки аспектологиянең проблемалары: акциональность» темасына докторлык диссертациясе яклый.

Танылган галимнең хезмәт биографиясенә кагылышлы янә бер мөһим фактны билгеләп үтәргә кирәк. Санкт-Петербургта яшәсә дә, ул беркайчан да Мәскәүдәге коллегалары белән элемтәләрне өзми; «Этимологический словарь тюркских языков» сүзлеген, «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков» кебек күптомлы хезмәтләр төзүдә катнаша.

Галим Д.М. Насилов инде ярты гасырдан артык укытучылык эшчәнлеген алып бара. Киң танылган тюрколог, төрки тел белеме буенча күренекле белгеч буларак, ул үзе эшләгән университетта гына түгел, илебезнең әйдәп баручы башка югары уку йортларында да лекцияләр укый. Минем үземә дә 1989 елда аның

«Язык древнетюркских письменных памятников» темасына лекцияләр курсын тыңлау бәхете насыйп булды. Бу лекцияләр белән ул Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты һәм уку йортының башка аспиранталары алдында чыгыш ясады. Галим хуннар, сяньби, төрки каганатлар, борынгы уйгыр, манихей, орхон-енисей әлифбаларының тарихын тәфсилләп аңлатты, Д.М. Васильевның «Корпус древнетюркских памятников Енисея», С.Е. Маловның «Памятники древнетюркской письменности», «Енисейская письменность тюрков» хезмәтләрен җентекләп анализлады һәм әлеге китапларны табып, ничек укырга кирәклегенә басым ясады. Олуг галимнән алган тирән белем, Дмитрий Михайловичның йөз-кыяфәте, югары культурасы, зыялылыгы бездә – Себер, Казахстан, Үзбәкстан, Якутия, Хакасия, Таганрогтан килгән аспирантларда – аңа карата тирән хөрмәт һәм соклану хисе тудырды.

1993 елда профессор Д. Насиловны РФ Милләтләр министрлыгы каршындагы Россия халыклары телләре институтына директор урынбасары итеп чакыралар. Ил тормышында яңа этап – милли мәдәниятләрнең күтәрелеш этабы башланган еллар иде ул. Нәкъ менә шушы елларда Төмән дәүләт универститетында, В.И. Ленин исемендәге Мәскәү педагогия институтында, Ырынбург, Тубыл һәм башка югары уку йортларында татар бүлекләре ачылды. РФ Милләтләр министрлыгы бу елларда халыкара төрки академиянең нигезен салу һәм гамәлгә кую өчен зур оештыру эшләре алып барды.

1996 елда Д. Насилов М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының төрки филология кафедрасы професоры итеп сайлана. Ул студентлар һәм аспирантлар өчен «История алтаистики», «Язык древнетюркских письменных памятников», «Древнеуйгурский язык», «Узбекский язык», «Основы сравнительной грамматики тюркских языков», «Введение в тюркологию», «Сопоставительная грамматика русского и узбекского языков» һ.б. лекцияләр курсын әзерли һәм аларны үзе үк алып та бара.

Профессор Д. Насиловның фәнни хезмәтләрен дөньяның барлык тюркологлары да яхшы белә. Алар галимнең «Проблемы тюркской аспектологии: акциональность», «Концепция языкого типа в трудах Н.А. Баскакова», «Значение и «функция» в функциональной грамматике А.В. Бондарко», «Языки малочисленных этносов в образовательном пространстве России» һ.б. монографияләрен югары бәяләделәр. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы белән хезмәттәшлек итеп, Д. Насилов мәктәп укытучылары өчен дә зур фәнни-методик ярдәм күрсәтә. Шундый иҗади хезмәттәшлек нигезендә «Концепция модели этнической (национальной) школы для коренных малочисленных народов Севера Российской Федерации», «Типовая общеобразовательная программа по языкам тунгусо-маньчжурской группы для школ народов Севера», «Кон-

цепция учебника родного и русского языка для национальной школы» хезмәтләре әзерләнгән.

Галим Д. Насиловның фәнни һәм иҗади эшчәнлеге киң кырлы. Ул 100 дән артык халыкара, Россия һәм регионнардагы конференция, симпозиумнарда актив катнаша. Алар арасында иң мөһимнәре түбәндәгеләр: Көнчыгыш телен өйрәнүчеләрнең 38 нче Халыкара конгрессы (ИКАНАС – 38) – Төркия, Әнкара (2007); күренекле галим Мәхмүт Кашгарый һәм аның «Диване лөгатет-төрк» хезмәтенә багышланган Халыкара симпозиум (Левкоша, 2008); Тюркологларның 3 нче Халыкара съезды (Левкоша, 2008). Күренекле фәнни хезмәтләре өчен профессор Д. Насилов Төрек лингвистик җәмгыяте (Türk Dil Kurumu) академигы итеп сайлана.

Россия (элек СССР) тюркологлар комитеты әгъзасы һәм җитәкчеләренең берсе буларак та Д.М. Насилов зур оештыру эшләре алып бара. Россия тюркологлары белән тыгыз элемтәләр урнаштырылган. 2009 елда Россия фәннәр академиясе, аның каршындагы Тел белеме институты, Россия тюркологлары комитеты хуплавы белән кабат «Российская тюркология» журналы чыга башлый һәм аның баш мөхәррире итеп Д. Насилов сайлана. Галим РФ Дәүләт думасының Милләтара мөнәсәбәтләр буенча комитетының эксперты да.

Тюркология өлкәсенә керткән мәртәбәле хезмәтләре өчен Д. Насилов 2014 елда Төркиянең «Лиякат» (Заслуга) ордены белән бүләкләнә. Бу орден чит ил кешеләренә Төркиянең Тышкы эшләр министрлыгы һәм мәдәният, тел, тарих буенча Ататөрек исемендәге Югары шура тәкъдиме белән ил Президенты тарафыннан бирелә.

Дмитрий Михайлович төрки телләрнең теориясе һәм тарихы буенча мәртәбәле белгеч, 250 дән артык фәнни һәм фәнни-методик хезмәтләр, сүзлекләр һәм монографияләр авторы. Хәзерге вакытта ул М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының Азия һәм Африка илләре институтында төрки филология кафедрасын җитәкли. Аның җитәкчелегендә бик әзерлекле укытучылар һәм галимнәр плеядасы әзерләнгән. Хезмәтләре дәүләтебез тарафыннан да лаеклы бәясен алган.

### Әдәбият

*Шеймович А.В.* К 85-летию Галины Федоровны Благовой: научные итоги десятилетия (автор по нашей просьбе предоставил нам электронную версию своей статьи).

Диляра Гарифовна Тумашева / гл. ред. серии М.Х. Хасанов, сост. Ф.М. Хисамова. Серия «Биобиблиографические указатели ученых Академии наук Татарстана». Казань: Фэн, 2003. 56 с.

Языкознание. М.: Наука, 2014. № 4.

*Тумашева Д.Г.* Татарский глагол. Опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий: учебное пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1986.

Тумашевские чтения: актуальные проблемы развития языка, фольклора, литературы, искусства сибирских татар: материалы II Всерос. науч.-практ. конф. (Тюмень, 17 окт. 2008). Тюмень, 2008. 258 с.

*Насилов Д.М.* Программный труд академика Д.Г. Тумашевой // Диалектология, история и грамматическая структура тюркских языков. Сборник материалов международной тюркологической конференции. 21–24 октября 2011 г. Казань, 2011. С. 9–12.

*Шюкрю Халык Акалын.* Дмитрий Михайлович Насилов награжден орденом турецкой Республики «Лиякат» // Российская тюркология. Москва – Казань, 2014. № 1 (10). 116 с.

## Д.М. НАСИЛОВНЫҢ ТӨП ХЕЗМӘТЛӘРЕ

1. Структура времён индикатива в древнеуйгурском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1963.

2. Древнетюркский словарь: словарные статьи, редактор / коллектив авт. и ред. Л., 1969.

3. Проблемы тюркской аспектологии: акциональность. Л.: Наука; ЛО, 1989. 208 с.

4. Проблемы тюркской аспектологии: Акциональность: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. М., 1989. 32 с.

5. Expression of situational plurality in Turkic languages // Typology of Iterative Constructions / соавт.: Х.Ф. Исхакова, В.И. Рассадин. München, 1997.

6. Imperative sentences in Turkic languages // Typology of imperative sentences. / соавт.: И.А. Невская, Х.Ф. Исхакова, Ш. Сафаров. München: Lincom Press, 2001. P. 181–220.

7. Концепция модели этнической школы для коренных малочисленных народов Севера РФ / коллектив авт. М., 2001.

8. Карлукско-уйгурская группа: фонетика. Глагол // Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Региональные реконструкции. М., 2002. С. 339–418.

9. Репрессированная тюркология / соавт.: Ф.Д. Ашнин, В. М. Алпатов. М., 2002.

10. Национальная школа: направления совершенствования структуры и содержания образования // Федеральная программа развития образования / коллектив авт.-сост. М., 2003.

11. Словарные статьи: Л, М, Н, П // Этимологический словарь тюркских языков / коллектив авт. М., 2003.

12. Уступительные конструкции в тюркских языках // Типология уступительных конструкций / соавт.: И.А. Невская, Х.Ф. Исхакова. СПб.: Наука, 2004. С. 425–452.

13. Древнетюркские языки: программа лингвистического курса // Программы курса турецкого языка и теоретических курсов / сост. Ю.В. Щека. М.: ИСАА МГУ, 2005. С. 51−54.

14. Основы тюркской семантики // Программа спецкурса Программы курса турецкого языка и теоретических курсов / сост. Ю.В. Щека. М.: ИСАА МГУ, 2005. С. 55−63.

***Алишина Хәнисә Чавдат кызы,***
*филология фәннәре докторы, Төмән дәүләт университеты профессоры*

УДК 821.51-3"653"

*Р.Г. Әхмәтьянов*

# ЙОСЫФ БАЛАСАГУНИ ҺӘМ АНЫҢ «КУТАДГУ БИЛИК» ӘСӘРЕ ТУРЫНДА

Статья посвящена лиро-эпическому произведению Йусуфа Баласагуни «Кутадгу билиг» – памятнику XI века, где отразились представления средневековых тюрков о мире, их философия, образ жизни, принципы организации жизни и управления. Определенное внимание уделено также истории изучения этого памятника такими учеными, как В. Радлов, В. Бартольд и др.

**Ключевые слова:** Йусуф Баласагуни, «Кутадгу билиг», средневековая тюркская литература

XI гасыр төрки әдәби комартkылары арасында гына түгел, иң борынгы заманнардан алып XV гасырга кадәрле аралыкта да Й. Баласагунинең **«Кутадгу билик»** дигән поэмасы күләме ягыннан да, эчтәлеге җәһәтеннән дә, тарихи ядкәрлек буларак та төрки дөньядагы иң күренекле сәнгатьчә әдәби әсәр булып тора. Дөрес, аннан бераз элегрәк – X гасырда язылган **«Алтун Ярук»** («Алтын яктылык») дигән дини прозаик әсәр «Кутадгу билик»тән күләмлерәк, ләкин анда реаль тарихи мәгълүмат та, поэтик-сәнгатьчә эчтәлек тә ярлырак.

Әйтергә кирәк ки, «Кутадгу билик» – татарча «Котайткыч белек» – бүгенгә кадәр тиешенчә бәяләнмәгән әсәр. Рус һәм Европа филологлары бу әсәргә «традицион» рәвештә кимсетебрәк карыйлар. Атаклы тюрколог В.В. Радлов, үзе үк «Кутадгу билик» турында махсус тикшеренү һәм рус вә алман телләренә тәрҗемә авторы (дөресрәк автордаш) булса да һәм, шулай ук, атаклы төрки тел тарихы белгече В.В. Бартольд та аны «буш әсәр», «оригиналь түгел» диебрәк бәяләгәннәр. Бәлки алар шуны күз алдында тотканнардыр: әсәрдә бик күп сәтырлар дидактик һәм дини өйрәтмәләргә, үгет-нәсыйхәтләргә багышланган. Ләкин аларда да җанлы тормыш күренешләре, үз заманы кешеләренең гадәт-холыклары чагылдырыла. Шундый чагылышлар үз заманы турында махсус тарихи әсәрләрдән күбрәк мәгълүмат биргәлиләр. Мәсәлән, әсәрдә ике урында сәрай (иерархиясе), сәрайдагы мөнәсәбәтләр турында озын-озак белешмә-инструкция бирелә һ.б. Әсәрдә озын дидактик сүз арасында бирелгән җанлы картиналар, геройлар арасындагы мөнәсәбәтләрдә килеп чыккан мәзәк әхвәлләрне чагылдыру да юк түгел һ.б.

«Кутадгу билик» ни өчендер озак заманнар укымышлылар һәм укучылар игътибарыннан читтә торган, тора-бара онытылган. Яңа заманга ул өч нөсхәдә генә килеп җиткән, алар да очраклы гына диярлек әсәрнең

кыйммәтен белүчеләр кулына эләккәннәр.

Сакланган кулъязмаларның беренчесе уйгур хәрефләре белән язылган һәм 1439 елның 17 июнендә тәмамланган булган. Элекке нөсхәдән күчерелеп язылган урыны, кулъязмада әйтелгәнчә, Һират (Герат) шәһәре. Күрәсең, ул заманда әле уйгур язуын кулланучылар булган. Шуннан ул кулдан-кулга күчеп (сатылып, бүләк ителеп һ.б.), Төркиягә килеп эләккән. Төркиядә дә, күрәсең, китап кадерен белүчеләр булган. Ни дисәң дә аны югалтмаганнар. Ниһаять, Истанбулда дипломатик хезмәттә булган Австрия галиме Иосыф фон Хаммер-Пургшталь (1774–1856) бер букинисттан 1796 елда күреп сатып ала һәм Венадагы король китапханәсенә тапшыра. Һәм әсәр тик XIX гасырның икенче яртысында гына атаклы венгр шәрекъшунасы Г. Вамбери тарафыннан нәшер ителә.

Бу Һират кулъязмасы бөтенлексез – анда төп текстының йөзләрчә бәйтләре (ике юллыклары) төшерелеп калдырылган һәм югалган.

Икенче кулъязманы алман галиме фон-Мориц 1896 елда Каһирәдә губернатор китапханәсе директоры булып эшләгәндә табып ала. Бу кулъязма шулай ук бик таркау, тузган, күп сәхифәләре югалган яки текст кыскартылган була.

Шуңа да карамастан, бу текстлар зур кызыксыну уяталар. Бөек тюрколог В.В. Радлов ул текстларны нәшер иттерә, алман һәм рус телләренә тәрҗемә итеп тә бастырта.

«Котайткыч белек»нең иң тулы кулъязмасын табу һәм гыйльми әйләнешкә кертеп җибәрү шәрәфе атаклы татар-башкорт галиме (атасы башкорт, анасы татар) Әхмәтзәки Вәлидигә (үзен Валидов дип тә, Вәлизадә дип тә атап йөрткән, Төркиягә баргач Вәлиди-Тоган тәхәллүсен алган) насыйп була. Ул мулла гаиләсендә туып, бик яшьли төрле телләр белән кызыксына һәм аларны үзләштерә, гыйльми әсәрләрен татарча, русча, төрекчә, алманча һәм французча яза. Гарәп һәм фарсы телләрен, шәрык мәдәниятен вә әдәбиятын яхшы белә. Өстәвенә, ул гадәттән тыш эшчәнлеге һәм эшмәкәрлеге белән аерылып тора. Төрки тарих вә әдәбият белән яшьли шөгыльләнә башлый һәм аның тәүге әсәрләре Казанда нәшер ителә торган татарча журналларда дөнья күрә. Ул заманындагы гомуми тюркология белән бик яхшы таныш була һәм халыкара хәлләрне дә яхшы аңлый. 1913 елда Зәки Вәлиди иске кулъязмалар эзләргә Урта Азия якларына махсус барып, Нәманган шәһәрендә Мөхәммәт хуҗа Лаләриш исемле һәвәскәрнең китапханәсендә «Кутадгу билик»нең тулы диярлек кулъязмасына тап була. Тик китапханә иясе кулъязманы теләсә кемгә бирергә ашыкмый. Әхмәтзәки Вәлиди Казанга кайтып, Фирганә өлкәсендәге кыйммәтле кулъязмалар турында мәкалә язып бастыра[1]. Шул мәкалә буенча булса кирәк, мәзкүр кулъязманы үзбәк язучы-филологы Фитрат 1924 елда Мөхәммәт хуҗадан сорапмы, түләпме кулына кертүгә ирешә һәм шул хакта

«Мәгариф вә укытучы» дигән үзбәкчә журналда мәкаләсе чыга. Шуннан соң әсәрнең аерым өлешләре төрле басмаларда дөнья күрә. «Кутадгу биликнең» фотокүчермәләре СССР һәм Төркия гыйльми үзәкләренә ирештерелә. Хәзерге көндә асыл нөсхә Ташкентта, гыйльми үзәктә саклана.

«Котайткыч белек»не өйрәнүгә татар галимнәре аеруча өлеш керткәнен әйтеп үтү лязем. 1920 нче елларда «Кутадгу билик» турында Урта Азиядә яшәгән тәнкыйтьче Г. Сәгъди мәкаләләр яза. Бу әсәрне 1930 еллардан башлап 1964 елга, вафатына кадәр, гомер буе диярлек Төркиядә эшләгән татар галиме Р. Рәхмәти-Арат өйрәнә. Ул әсәрнең төрле кулъязмаларының фотокүчермәләрен бастырып чыгара, җыелма һәм тәнкыйди текстын төзи, аны төрек теленә тәрҗемәләп нәшер иттерә. Аның бу язганнары Төркиядә соңрак, 1990 нчы елларда күптомлыкларда да дөнья күрә. Рәхмәти-Араттан бераз соңрак башлап, «Кутадгу билик»не озак еллар буенча татар галимәсе А.А. Вәлитова тикшерә, әсәрнең тәнкыйди текстын әзерли.

1970 елда «Советская тюркология» журналының «Кутадгу билик»не өйрәнүгә багышланган махсус 4 нче саны нәшер ителде. Анда күренекле татар тюркологы Әдһәм ага Тенишевның да мәкаләсе бар иде.

Шуннан соң бүгенге көннәргә кадәр төрки халыкларның (бигрәк тә мөстәкыйль төрки дәүләтләрнең) гыйльми үзәкләрендә уртак сәмәрәбез булган «Кутадгу билик»не өйрәнү дәвам итә.

Йосыф Баласагуни кереш өлешендә үз әсәрен мактый һәм аның төрле илләргә таралганлыгын әйтә. Янәсе, ул Чин галимнәренең акылдар сүзләре, Мачин голәмәләренең матур тәгъбирләре белән бизәлгән. Китап гадәттән тыш югары рухи эчтәлеккә ия булганга күрә, Чин галимнәре аны «патшаларның әдәп китабы», Мачин хакимнәре «Мәләкәтләренең иминлеге», Шәрык голәмәләре «Әмирләрнең бизәнече», Иран белгечләре «Төрки Шаһнамә», ә кайберләре «Мәмликләрнең киңәшнамәсе» дип, ә туранилар (төркиләр) исә «Кутадгу билик» ягъни «Котайткыч белек» дип атадылар, ди. Белгечләрнең фикеренчә, алдан ук болай әйтү сәеррәк. Ихтимал, бу китапның бүтән (мәсәлән, прозаик) вариантлары, элгәрләре булгандыр, тик алар безгә килеп җитмәгән, диләр.

**«Котайкыч белек»** – иҗтимагый социологик белемнәр таратуны максат итеп язылган әсәр. Белем бирү, тарату дәрте роман-поэманың күпчелек өлешләрендә сизелеп тора. Өстәвенә ул патриот – төрки телдә дә фарсы вә гарәп телләрендәге шикелле, гүзәл әсәрләр язылуын тели һәм шәхсән шул максатка өлеш кертә. «Чинъ вә Мачин галимнәре вә хакимнәре бердәм рәвештә килешеп әйттеләр ки, мәшрикъ тарафларында барча Төркестан илләрендә Бугра хан телендә түрк лөгатенчә бу китаптан яхшырак кем дә булса берәү язмады-төземәде», диелә. Шул рәвештә арытабан, бик тә һаваланып, автор «минем әсәрне укыгач төркиләр генә түгел, күрше

фарсы, гарәп һәм Чинъ вә Мачин (Кытай) белгечләре һәм хөкемдарлары шаккаттылар, иң бөек әсәрләр рәтенә куйдылар», – ди.

Болай әйтеп, артык шапырыну, арттырып мактану гына түгелдер бу. Автор әсәренең кайбер өлешләрендә һәртөрле мактануга үзе каршы чыга ич. Күрәсең, чынлап та аның бу әсәре (яисә бу поэмага нигез булган һәм шул ук исемдәге икенче бер әсәр) киң таралыш тапкан. Зәки Вәлиди иске чыганаклардан күреп хәбәр иткәнчә, Чыңгыз ханның «Кутадгу билик» дигән китабы булган, имеш. Ул китапны соңрак Алгы Азиядә хакимлек иткән Җәлаер бийләр кулында күргәннәр[2]. Кайбер чыганакларда «Кутадгу билик» әсәренең татарлар арасында күптән билгеле булуы әйтелә. Беренче карашка сәеррәк тоелган бу расламаның, бәлки, берәй кирчегәсе бардыр. Шуны да искә төшерик – җәлаерлар Чыңгыз хан нигезләгән империядә гомумән тәртип саклаучы көч буларак хөкем йөрткәннәр. Көньяк Уралда – Башкортстанда Җәлаер (йылаер) дигән ике зур торак пункт (аларның берсе – элекке крепость – кальга), Җәлаер елгасы һәм Җәлаер яссы таулыгы бар. Себер татарлары составындагы җәлаерлардан атаклы Касыйм тарихчысы Җәлаири чыккан. З. Вәлиди, җәлаерлар Чыңгыз хан чорында ук төрки телдә сөйләшкән булса кирәк, чөнки исемнәре төркичә, ди. Һәрхәлдә җәлаерлар төрки китапларны укыганнар.

Кызганычка каршы, бик тә төрки мәдәниятле булган, ләкин үзәкләштерелеп бетмәгән караханилар дәүләтен XI гасыр азагында (бәлки Баласагуни үлеп тә өлгермәгәндер) монгол телле мәҗүси каракытайлар тар-мар итә һәм XIII гасырның башларына кадәр (йөз елдан артык) дәүләтнең көнчыгыш өлешендә хакимлек итәләр. Каракытайлар мөселманлыкка, мөселман мәдәниятенә каршы буларак, мәҗүси төркиләрне яклаганнар (аларның дәүләтендә дә төп халык төркиләр булып калган).

Китапның кыскача кереш өлеше шигырь белән дә кабатланып бәян ителә.

Анда тагы «Ханлар ханы Табгач Бугра ханның» авторны олылаганы, бүләкләр һәм югары чиннар биргәне бәйан ителә. Шунда ук әсәрдәге төп геройларның исемнәренә-ләкабьләренә аңлатмалар бирелә. Хан Көнтугды – «гаделлек», вәзир Айтулды – «дәүләт, байлык», Үгделмеш – вәзирнең улы – «акыллылык», Уйгырмыш исә барына канәгатьлекне, тыйнак акыллылыкны белдерә, ди.

Мондый аерылып торган китаби керештән соң 67 бүлек-бабтан гыйбарәт төп текст бирелә. Бабларның төзелеше төрлечә: авторның үз сүзләре белән беррәттән, сорау һәм җавап формасындагылары да бар.

Беренче баб «Җиде күк вә унике бөреж» дип атала һәм биш бүлекчәдән тора: 1) Алланың исеме белән (Аллага мактау); 2) пәйгамбәр галәйһи әс-сәламнең фазыйләтләре; 3) аның сәхабә вә ризваннарының (токымнарының) фазыйләтләре; 4) мөхтәрәм, мөзаффар, мәдәткяр, хакыйкать вә дин таянычы табгач олуг Бугра Карахан әбу Гали Хәсән

бине Арысланхан рәхмәтуллаһу галәйһем шанына; 5) җиде сәйяра һәм унике бөреҗ. Бу соңгы баб безнең өчен иң кызыклысыдыр, мөгаен. Анда шул заманда ирешелгән астрологик белемнәр, сәйяралар (планеталар) һәм йолдызларның, йолдызлыкларның исемнәре – атамалары китерелә. Матур табигать күренешләре бәян ителә.

Әйтергә кирәк ки, китапка алдан бирелгән фиһрист – мөндәриҗә белән безгә килеп җиткән кульъязмалардагы эчтәлек бүленеше туры килми. Мәсәлән, фиһристтә сигезенче баб дип күрсәтелгән бүлек безнең (наманган) кульъязмада юк. Дөрес, бу бабның аталмыш эчтәлегенә («Кылык-кыланыш бозыклыгы» мәсьәләсенә) ярашлы унлап кушык бар, тик алар тугызынчы – «Көнтугды гадел» бабына да кертелгәннәр.

Безгә килеп җиткән кульъязма азагында бүтәнчәрәк фиһрист (эчтәлек) күрсәтелгән. Һәм әлеге күрсәтелгән биш бүлекчә аерым бүлекләр рәтендә торалар.

Икенче (алтынчы) баб «Инсанның кадере белек белән» дип атала һәм ул уку-белемнең кирәклеге, кыйммәте турында. Бу сәтырларны XIX–XX гасыр башларындагы татар шагыйрьләре язган диярсең. Һәм тарихның усал уенына шаккатасың: нишләп соң укуның кыйммәтен-кадерен белгән төрки халыклар яңа заманнарга иң мескеннәр рәтендә калып килделәр икән?

Өченче баб сүз көче, аны әйтә белү турында. Дүртенче баб – авторның үзенә мөрәҗәгате. Бишенче, алтынчы баблар гыйлемне игелеклеккә юнәлтү һәм, гомумән, игелек турында (бу мотив әсәрнең башыннан азагына кадәр исбатлана).

Җиденче бабта һәм соңгы өлешләрендә дә автор кайтып-кайтып үзенең гомере зая үткәнлеге, гамәлгә ашмыйча калган хыяллары турында сөйли.

Әсәрнең төп темасына автор сигезенче бабында гына керешә. Баб «Сүз башы. Көнтугды илек (иллек) турында» дип атала.

*Бәг эрди ажунда бөгу билкә баш,*
*Бу бәглик үзәлә (үзәрә) ажун*
*болды яш.*
*Бу Күнтогды эрди, аты бәлгүлүг,*
*Ажунда чавыкмыш, куты бәлгүлүг.*

Ягъни:

*Бар иде дөньяда батыр бәк белкә,*
*Ул яшьлек китерә белде бар илгә.*
*Бу Көнтугды иде, аты билгеле,*
*Дөньяда дан алган котлы, белекле.*

Идарә хәстәрләре күбәеп киткәч, Көнтугды үзенә бер *басутчы* – ярдәмче урынбасар – эзли башлый. Чөнки:

*Күтәрелгән саен арта ир гаме,*
*Баш үскәнчә арта бүрек үлчәме.*

Көнтугдының эше арткан саен абруе да арта. Аның янына эшмәкәр ир-егетләр агылып килә башлый.

Тугызынчы баб Айтулдының Көнтугдыга килеп хезмәткә керүе турында; әйтергә кирәк, сигезенче һәм тугызынчы баблар бик реалистик тонда сөйләнелә. Монда үз заманындагы тарихи ситуация ачык чагыла, дисәк тә була.

Көнтугдының үз хезмәтенә булдыклы егетләр җәлеп итүен Айтулды дигән бер егет ишетә. Ул кайдадыр ерак провинциядә,

башкаладан читтә яшәгән була. Күп һөнәрләрне үзләштергән, күп нәрсә белгән егет икән. Һәм үзенең булдыклылыгына лаеклы урын табалмыйча йөргән.

*Бу Айтулды әйтте, күр: – Ат, тун, тулым*
*Алып, күндеримче табугка юлым.*

(Сүзмә-сүз тәрҗемәбездәге **тун** «асыл кием», **тулым** «тире капчык, табуг «өлкәннәргә хезмәт»: бу сүзләр татар классик әдәбиятында да шул ук мәгънәләрдә кулланылган). Өстәвенә (тарихи җәһәттән бик характерлы деталь) Айтулды үзе белән күп кенә алтын-көмеш тә ала.

Айтулдының урдага (калага) килүе, **төшен** – аерым фатир – табалмыйча **мүйәнлеккә** – кунакханәгә – барып ятуы, аннары кала буйлап аптырап йөрүләре, сәрайга керү кыенлыкларын кичерүләре һ.б., хәзерге заман тарихи романнардагы шикелле, реалистик буяулар белән тасвирлана. Бу тасвирларда тарихи кыйммәтле детальләр чагылып китә.

Мәсәлән,

*Бөтенләй чит илгә эләксә бер ир*
*Тел яшергән килен шикелле йөрер,*

диелә.

Монда этнографик *тел яшерү* гадәте искә алына. Кызганычка каршы, әсәрдә мондый урыннар күп түгел.

Айтулды күп кенә көннәр каңгырып йөргәч, Күсәмеш дигән бер «изге кеше» белән таныша. Күсәмеш Айтулдыны Эрсиг исемле кеше, югары чиновник – хас хаҗип белән таныштыра, ул хас хаҗип Эрсиг Айтулдыны бәк, эллиг янына алып керергә ирешә. Әсәрдә монарх оригинал титул белән – *элиг, эллиг* дип атала, хан да, патша да түгел. Эрсиг рекомендациясе буенча эллиг Айтулдыны бик җылы каршылый һәм хезмәткә ала. Тик Айтулды тәүдә сынау чорын үтә. Аны капуда (сарай капкасында) каравылчы – көндез *торгак,* төнлә *яткак* итеп билгелиләр. Ул эллиг янына кереп-чыгып йөри алу хокукына ирешә.

Вакыйгаларны бәйан иткәндә автор бик еш риторикага, үгет-нәсыйхәткә бирелеп китә. Ул риторик текстлар еш кына кабатланалар, бер мәгънәне төрле сүзләр белән әйтүгә кайтып калалар.

Айтулды әйбәт эшли, илбикнең ышанычын аклый. Шуннан:

*Илбик (эллиг)беркөн ялгыз утырган мәлдә,*
*Айтулдыны дәште шатлыклы хәлдә.*

Илбик янына чакыру буенча килеп кергән хезмәткәр үзен бик сәер тота. Бәкнең сүзен тыңламый, күрсәткән урынына утырмый, ә иң югары затлар утыра торган зур туп өстенә утыра. Бәк кушканны кылмый, бәк юраганнарга җавап бирми, йөзен бора.

Шуннан илбик каһәрләнә башлый: «Ах, ничек ялгыштым, нинди ахмакны, тилемсәне үземә якынлаштырганмын лабаса», ди. Айтулды: – Гаебем нәрсәдә соң? – ди. Илбик Айтулдыны, әлбәттә, сүгә, яный башлый. Шунда Айтулды аңарга «мин асылда кеше түгел, дәүләт, хөкемдарлык», ди. Хөкемдарлык хөкемдар белән менә шулай уйнап – бер

көлеп карый, бер йөз чөерә, ди. Шулай итеп әсәргә фантастик алым килеп керә.

Уникенче бабта Айтулды дәүләт сыйфаты (үзенең сыйфаты) турында озын фәлсәфә сата.

Унөченче бабта Көнтугды илбик тагын Айтулдыны чакыра. Айтулды керсә, күрә – Көнтугды өч аяклы көмеш көрси (затлы урындык) өстенә утырган, сул ягында ачы агу, уң ягында шикәр, кулында пычак. Айтулды гаҗәпкә кала, куркып китә. Шуннан соң Көнтугды хакимият хикмәтләрен сөйләп бирә. Иң ышанычлы тәхет – өчаяк, ди. Идарә эшендә җәза һәм мөкәфәт (бүләк) кирәк. Һәм ышанычлы кораллы көчләр булсын, ди.

Шуннан соң әсәрдә күп урын Көнтугды белән Айтулдының үзара сорау-җавапларына бирелә. Гомумән, әсәр шундый диалогларга корылган.

Бу әңгәмәләрдә гаделлек, тугрылык, алдашмау, эш сөючәнлек, әдәплелек, тыйнаклык һ.б. фазыйләтләр турында сөйләнелә. Әңгәмәләр барышында темага караган бик күп мәкальләр әйтелә, мәсәлән, тел турында (үзебезнең сүзләрдән тәрҗемәләр бирәбез, саннар икеюллыкларның нумерын-тәртибен күрсәтә):

*950. Кызыл тел кыскартыр яшәр*
*яшеңне;*

*952. Кара башыңа яу кызыл тел*
*торыр;*

*959. Белемле кешенең сүзе*
*төкәнмәс;*
*Шифалы чишмәнең суы*
*төкәнмәс;*

*1000. Күмәртәләп тыңла, берәмләп*
*сөйлә;*

*1006. Сүзне сүгеп булмый –*
*файдасы хәтсез;*
*Тик бер сүз акыллы, ә берсе –*
*мәнсез.*

Бераздан Айтулды авырый һәм үлеп китә. Бу вакыйгага шигъри урын күп бирелә һәм монда да күп кенә афоризмнар табыла:

*1052. Гамьсез булма, и дус, тере*
*чагында,*
*Болай да үлем бар*
*киләчәгеңдә.*

*1087. Чәчләреңә аккош төсе*
*кергәндә*
*Хисләрең дә, ак, саф булсын, и,*
*бәндә!*

*1109. Дәртең бар чагыңда җитми*
*акылың,*
*Акыл бар, карыйсың – гомер*
*ахыры...*

Әсәрдә Айтулдының кешечә үкенүләре һәм углы Үгделмешкә нәсыйхәт бирүләре күп урын алган.

*1151. Каю кемдә, диләр, угыл-кыз*
*була –*
*Йокылары аның тыңгысыз*
*була.*

*1168. Хәйләгә бирешмәс һичбер шәй*
*дә юк,*
*Тик каршы торгысыз һичбер*
*хәйлә юк.*
*Һәр хәйләгә хәйлә коры*
*табыла.*
*Тик үлемгә генә бик тә, бәй*
*дә юк.*

*1311. Телеңнән чыгарма ялган*
*сүзеңне,*
*Ялган бик тиз очыз итәр*
*үзеңне.*

Айтулды илбиккә дә озын нәсыйхәтнамә яза:

*1394. Тозлы су кебектер бу дөнья малы:*
*Никадәр эчсәң дә сусавың калыр.*

*1418. Харамга кагылма һәм дә көнләшмә,*
*Кеше каны түкмә, юкка үчләшмә.*

*1473. Угылны акылга яшь чактан өйрәт:*
*Яшьли очкан шоңкар оча биегрәк.*

Айтулдының углы Үгделмеш («Үгетләнмеш, тәрбияләнмеш») үзеннән дә акыллырак булып чыга. Үгделмеш, яшь булса да, дәүләтне төзекләндерүгә ирешә (күрәсең, эшлекле урынбасар юк чагында Көнтугдының эшләре читенләшкән). Шулай да Көнтугды аны тәрбияләргә, аңарга акыл бирергә керешә.

*1630. Ике галәмдә дә мотлак шул ике:*
*Эшең булсын рәтле, ә холкың ипле.*

Шуннан соң озын гына пассаж тәрбия мәсьәләләренә багышлана.

*1791. Углан сабый чакта белек өйрәнер,*
*Мәгәр сәләт-ушны тәңре бирәдер.*

*1975–1997.*
*Кайбер кеше укый, белеме дә күп,*
*Тик кайбер нәрсәгә булмый өйрәнеп.*
*Кайбер шәйгә Хәкътан сәләт бирелер,*
*Бу сәләт була яшь чактан билгеле.*
*Сәләт ул, шөбһәсез, тәңредән бүләк,*
*Тик аны расларга күп уку кирәк.*

Әсәрдә мәхәббәт турында сөйләнелә – бу мәсьәләдә дә Иллек белән Үгделмеш әңгәмә коралар. Иллек (Илбик) сорый:

*Күңел татлыгы ни һәм күз татлыгы,*
*Бу икедән җанга кайсы якыны?*

Үгделмеш җавапларында татарчага сүзмә-сүз тәрҗемә ителә торган юллар бар:

*1867. Сөекле кешенең йөзе билгеле,*
*Тел ачса, мәгънәле сүзе билгеле* һ.б.

Шуннан соң сүз башлыклар-түрәләр һәм буйсынмышлар арасындагы мөнәсәбәткә күчә. Иллек күп тапкырлар буйсынмышларына күп сөйләнмәскә өнди: (сүзмә-сүз тәрҗемә)

*Белек амбары ул – бу бийләр үзе,*
*Белексез булыр кол, нигә кол сүзе?*
*Сорау җиңел, әмма җавап – җаваплы.*
*Еш кына җаваплы бий генә хаклы.*

*1919. Бик исеме белек белән нурланыр,*
*Һәм лямы кырылса «бек» кенә калыр.*

Шуннан соң бикләрнең, бийләрнең нинди булырга кирәклеге, ил алдында җаваплылыгы, батыр сугышчы да булырга тиешлеге турында күп кенә сөйләнә.

Әсәрдә берничә урында эчкечелеккә каршы тирадалар бар - бийләр, бәкләр дә кайчак эчмәскә тиеш диелә.

Бий, бәкләр турында сөйләгәч, вәзирнең, сүбашының (сәргаскәрнең), олуг хаҗибнең, дәрвазабанның (шәһәр капкасы начальнигының), ялавачның (илченең), кятипнең (секретарьнең),

хәзинәченең, баш ашчының (шеф-поварның), идешченең (шәраб мәҗлесләре оештыручының), сәрай хезмәткәрләренең, ир-атларның (кадрлы сугышчыларының) нинди булырга тиешлеге турында озын-озак бәйаннамәләр китә. Кыскача гына сатучы (сәрай сәүдәгәре) турында да искә алына.

Шуннан ары әсәрнең биштән ике өлеше дини философ һәм монах Уйгырмыш белән баглы бабларга багышлана. Ул Уйгырмыш Үгделмешнең кардәше һәм гыйлеме белән халыкта абруйлы кеше икән. Көнтугды белән Үгделмеш шундый кешене сәрайга тартырга телиләр. Үгделмеш Уйгырмыш белән күп тапкыр сөйләшкәч, иллек исә өч тапкыр озын-озын хатлар язып чакыргач, Уйгырмыш риза була. Тик ул сәрайда яшәү шартлары турында сорый. Шунда иллек сәраендагы тәртипләр, хәл-әхвәлләр, вазыйфалар, җаваплы хезмәткәрләр турында сүз китә һәм әсәрдә шулар турында тәфсилле, тарихчылар өчен кызыклы бүлекчәләр килә. Үгделмеш Уйгырмышны хезмәткәрләр белән нинди мөнәсәбәттә булырга кирәклеген өйрәтә.

Монда сәрайдагы иерархия баскычлары, алар арасындагы мөнәсәбәтләр шактый тәфсилле рәвештә, сатира элементлары белән Үгделмеш авызыннан сыйфатлана. Сәрай әһелләреннән сипаһиләр (гаскәриләр, офицерлар), кара гаммә (хезмәткәрләр), галәвиләр (үзләрен хәзрәт Гали токымнары дип исәпләгән югары катлам динчеләр), белкә-галимнәр, табиблар, әфсүнчеләр, төш юраучылар, йолдызчылар, шагыйрьләр, арытабан гади халыктан *тарычылар* (җирбагарлар, керәстияннәр), сәүдәгәрләр, терлекчеләр, һөнәрмәннәр, ярлылар белән мөнәсәбәт нинди булырга тиешлеге бәйан ителә.

Уйгырмышны хәтта өйләнергә дә өндәп карыйлар. Шунда ничек һәм нинди хатын алырга, угыл-кызны ничек тәрбияләргә, өйләнгәч кул астыгындагы хезмәткәрләр белән нинди мөнәсәбәттә булырга өйрәтмәләр бирелә.

Аннары кунак чакыру, кунакка бару тәртипләре бәйан ителә. Болар белән танышкач, Уйгырмыш, ниһаять, иллек сәраена килә, сөйләшә. Аны зур хөрмәт илә каршылыйлар. Ләкин, әхвәлләр белән тагын бер тапкыр танышып, Уйгырмыш сәрайга килүдән баш тарта, үзенең аулак таулардагы хөҗрәсенә кайтып китә.

Озак та үтми Уйгырмышның караучы егете (хезмәтче?) Үгделмеш янына килеп, изге кешенең авырып ятканын һәм кардәшен үзенә чакырганын хәбәр итә.

Үгделмеш

*5848. Атка менде, барды кардәше таба,*
*Тиеп (җитеп) керде, күреп, кул йөзен үбә.*
*Кардәшен күрә – ул сузылыпятып,*
*Чикмәнен, түшәгән җиңен ястанып...*
*Әйтте (Үгделмеш): – Ни булды үзеңә, әй кардәш...*

Уйгырмыш: «Үлем тоткагы тотты, сине күреп үлим, дип чакырдым», – ди. Үгделмеш аны юата: «Юкка борчыласың, «чирләү әле үлү түгел, гомердә

ничәмә-ничә тапкыр авырып аласың», – ди. Үгделмеш үзенең үләчәген төшендә күргәнен сөйли. Шунда төшләр турында озын әңгәмә бирелә.

*Төшеңдә кайгырсаң – бу сөенечкә,*
*Сөенеч кайгыга – нәкъ киресенчә.*

Аннары, – ди Үгделмеш, – төшеңне ничек юрасаң, шулай булу ихтималы да бар, ди.

Уйгырмыш, ниһаять, төшен сөйли:

*Баскыч күрдем – аратасы илле иде,*
*Текә куелган, киң һәм биек иде.*
*Һәр арата булды миңа бер адым,*
*Азагына кадәр менеп санадым,*
*Бер атлы зат шунда су бирде,*
*алдым.*
*Төбенәчә эчеп бетердем – кандым,*
*Һәм шуннан соң кинәт очтым да*
*киттем.*
*Ә үзем әллә бар, әллә юк идем.*

Үгделмеш: – Бу бик тә яхшы төш, димәк синең дәрәҗәң күтәрелә, – ди. Үзенчә яхшыга юрый. Уйгырмыш исә «төшемдә күргән атлы зат – безнең ата-бабаларны атсыз ияр мендергән зат – үлем, суны төбенә кадәр эчкәнем – гомерем бетте дигән сүз», – ди.

Монда шуны әйтергә кирәк, Алтайдан Днепрга кадәр сузылган киңлекләрдә очрый торган төрки кабер һәйкәлләре – балбалларда үлмеш кеше ике куллап кукшин тоткан кыяфәттә сурәтләнә.

Уйгырмышның илле арата күргәне – илле яше була (тик әсәрдә бу юралыш әйтелмичә кала).

Шуннан соң Уйгырмыш Үгделмештә васыять-нәсыйхәтләрен сөйли.

Әсәрнең төп өлеше шуның белән тәмам. Уйгырмыш үлә. Үгделмешкә бер рәкъвә (комган төре), тәһарәт савыты һәм таяк калдыра.

Көнтугды белән Үгделмеш тиздән кайгыларын оныталар һәм уңышлы рәвештә идарә итә бирәләр. Аларның үлеме тасвирланмый.

Әсәрнең төп өлешеннән соң гыйләвәләр-өстәмә бүлекчәләр китә. Тәүдә төп вәзендә дүрт аерым шигырь бирелә. Шуннан соң касыйдә (мәснәви) вәзенендә «Егетлекне сагынып, абышкалык (гаиләсез картлык) хәлен әйтә» (шулай «әйтә» дип атала да), «Заманы бозыклыгын, дусларның җафасын әйтә», «Китап иясе Йосыф олуг хаҗип үзенә нәсыйхәт бирә» дигән шигырьләр өстәлгән. Тикшеренүчеләр боларны төп әсәрнең текстына кушып, күчереп язучылар өстәгән, яисә Йосыф Баласагунининың аерым шигырьләр китабы булгандыр, диләр.

«Котайткыч белек» төрки әдәбиятлар микъясында (масштабында) гына түгел, бөтендөнья әдәбияты микъясында да иң күренекле әсәрләрнең берсе. Ул бөтенлекле һәм сәнгатьчә язылган зур шигъри әсәр, «шигъри роман» дисәк тә була. Ул бөтен дөньяда шул чорга килеп ирешелгән фикер, мәдәният, фәлсәфә кимәлен бар тулылыгы белән чагылдыра. Бу асылда фәлсәфи романның заманындагы көнкүрешне чагылдыруы да уникаль күренеш. Шуларга баглы рәвештә әсәрнең теле дә искиткеч бай һәм тәгъбирле.

Тагын шуны әйтәсе килә (чөнки әлегәчә әйтелмәгән бу-

гай) «Котайткыч белек» авторы карахинилар дәүләте хөкемдарларын дәүләтне, аның коралы көчләрен ныгытуга чакыра, сипаһсалар – сү-армия башы нинди булырга тиеш дигән күләмле (2233–2327 нче, 164 ике юллык) бүлектә армияне төзү-оештыру вә тактик алымнар хакында акыллы киңәшләр бирә, тик иллек-илбик, күрәсең, бу киңәшләрне тотарак, ил яклавышын җитәрлек дәрәҗәдә оештыра алмаган. Караханилар дәүләте тиз арада икегә бүленгән. Көнчыгыш өлеше каракытайлар корбаны булган.

Автор философик темаларга кергәндә, замандашы булган Ибне Сина фикерләрен кабатлый, дип язалар. Һәрхәлдә Йосыф Баласагуниның заманындагы гыйлем ияләре белән таныш булган.

Түбәндә әсәрнең прозаик кереше (тәрҗемәсе) бирелә.

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Тәбрик һәм данлау, шөкерана вә мактау Тәңре газзә вә җәллага (1), кайсы кем олуглык иясе һәм тамм-төгәл (абсолют) кодрәтле падишаһтыр – ул җирне-күкне яралткан, барча җан ияләренә ризык биргәндер. Ул ни теләсә шуны кылган һәм ни эстәсә шуңа ирешәдер – яфгалүл лаһү ма йәтагъвә яхкүкү ма йүрүд (2). Шулай ук кешеләр арасында иң олугы – тәңре илчесе булмыш рәсүлебезгә сансыз сәламнәр булсын һәм кылмышлары бөек газиз сәхабәләргә ризван Аллаһи галәйһим әҗмәгыйнә (3). Бу китапны бик тә абруйлы дип белегез – ул Чин хәкимнәренең (логик) нәтиҗәләренә нигезләнгән, Мачин хәкимнәренең шигырьләре белән бизәлгән. Һәм бу китапны укып, аны бүтәннәргә мәгълүм итүче китапның үзеннән дә абруйлы булыр. Мачин галимнәре вә хәкимнәре шундый бердәм фикергә килделәр – барча Көнчыгыш өлкәләрендә, Төркестан илләрендә Ббграхан телендә бу китаптан да яхшырак китапны әле беркем дә язмаган. Бу китап каю патшага вә каю икълимгә барып җитсә дә, гаять акылдарлыгыннан, ниһаять дәрәҗәдә сәнагатьчелегеннән, ул илләрнең хәкимнәре-галимнәре барсы да бердәй кабуллап, төрле шәрәфле атамалар бирделәр: чыйнлылар әдәбел-мөлек (4), Мачин хөкемдарының нәдимнәре гаенүл-мәмләкәт (5), мәшрикъ кешеләре зийнәтел-гомәрә (6), дип атадылар. Иранлылар Шаһнамәи төрки (?), диделәр, ә кайберләре патшаларга нәсыйхәт дип бәяләделәр, ә туранлылар Котайткыч белем дип исемләделәр. Бу китапны төзүче Баласагун тумасы, тыйнак, тәүфикълы ирдер. Бу китапны Кашгарда төгәлләп, мәшрикъ мәлиге Табгачхан дәргяһына килеп тәкъдим итте. Мәлик аны хөрмәтләп, Хасс хаҗиб (8) чинын бирде, шунлыктан Йосыф олуг хасс хаҗиб дигән аты-чабы (9) таралды».

Китапның кыйммәте шуңа нигезләнгән: анда беренчедән – гаделлек, икенчедән – дәүләт, өченчедән – акыл, дүртенчедән – канәгатьлек алга сөрелә. Һәм бу сыйфатларның һәрберенә минәзкеше исеме бирелде: гаделлек – Көнтугды илбик (10), патша мисалы, дәүләт – Айтулды, вәзир

мисалы, акылы – Үгделмеш, вәзирнең углы, канәгатьлек – Уйгырмыш – Үгделмешнең карендәше мисалы. Әсәрдә шулар арасында әңгәмәләр кичә, ягъни сораулар-җаваплар әйтелә. Укучымның күңеле ачылып, язучыны изге дога илә искә алсын иде, дип, я, Аллаһу-тәгаләгә бер дога.

1) Газзә вә җәлла – Алланың иң югары эпитеты, «газиз нурлы ялкын» кебегрәк аңлатыла.

2) «Ни теләсә шуны эшли ала һәм һәрнәрсәгә үзгәрә хөкем йөртә» мәгънәсендә.

3) «Аларның җәмгысенә Алланың ризалыгы насыйп булсын».

4) «Илнең әдәбе»

5) «Дәүләтчелек көзгесе».

6) «Яшәүнең зиннәтләнеше».

7) «Төркиләрнең шаһнамәсе». Шаһнамә – бөек шагыйрь Фирдәүсинең ирани-фарсы халыкларның тарихи тәҗрибәсен гомумиләштергән күптомлы поэмасы.

8) Хасс хаҗиб – махсус киңәшче, «тайный советник».

9) Чап «дан» ошбу әсәрдә уңай мәгънәдәрәк кулланыла.

10) Ошбу әсәрдә монарх, кенәз *элиг* дип атала. Бу сүз кайбер бүтән борынгы төрки ядкәрлекләрдә дә очрый (ДТС: 170)[3], тик хәзерге төрки телләрдә кулланылмый. Без тәрҗемәбездә бу сүзне үзенә тамырдаш һәм татар халык телендә дә очрый торган *илбик* сүзе белән алмаштырдык.

## Искәрмәләр

[1] *Валидов Н.З.* Восточные рукописи в Ферганской области. ЗВОРАО. Т. XXII. Вып. III–IV. 1915.

[2] *Veledi-Toqan Z.* Umumi türk tarihine kiriş. İstanbul. S. 84–85.

[3] ДТС – Древнетюркский словарь. Л., 1969.

***Әхмәтьянов Рифкать Газизҗан улы,***

*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145"653"

***М.И. Әхмәтҗанов***

# АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕНЕҢ БАШЛАНГЫЧ ДӘВЕРЕНДӘГЕ ПУБЛИЦИСТИК ӘДӘБИЯТ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ХАКЫНДА (XIII–XVI ЙӨЗЛӘР)

Статья посвящена тюркским письменным источникам периода Золотой Орды, а именно государственной переписке. Делается попытка разбора структуры и стилистики этих документов.

**Ключевые слова:** ярлык, тарханная грамота, государственная переписка, Золотая Орда, письменные источники.

Дәүләтләрнең оешу вакытларында ук, аларның язма документлары гамәлгә керә.

Шул беренче язма чыганаклар соңга таба традицион өслүб алып, дәүләт эчендәге һәм тышындагы үзара мөнәсәбәтләрне көйли торган тотрыклы документлар системасы һәм жанры барлыкка килүгә нигез булалар. Андый документларның стандарт структуралары вакытлар узу дәвамында камилләшә бара.

Чыңгыз хан империясе төзелгәч, аның составында бер зур Олысы булган – Бату Олысы, булачак Алтын Урда барлыкка килә. Бату хан үз кул астындагы җирләрдә Чыңгыз империясендә урнаштырылган дәүләт структурасы аппаратын күчереп алып канунлаштыра. Дәүләт Олысларга бүленә, һәр Олыста җитәкчелеккә хан нәселеннән булган татар ырулары вәкилләре – Олыс бәкләре утыртыла.

Безгә Алтын Урдада Бату, Бәркә ханнар заманында, алар эшчәнлеге белән бәйле булган кайбер документлар турындагы хәбәрләр билгеле.

Бәркә ханның 1263 елның 21 маенда Мисыр мәмлүкләре солтаны Бибарска беренче дипломатик миссиясе килә. Алтын Урда ханы вәкилләре солтанга Хулагулар Иранына каршы берлек төзү турында тәкъдим язылган хат тапшыралар. Бәркә хан, бу тәкъдиме кабул ителгәндә, Бибарска үзенең ярдәм итәчәген вәгъдә итә[1].

Бу илчелек ясаган тәкъдимгә җавап йөзеннән Мисыр солтаны Бибарс Алтын Урдага зур илчелек җибәрә.

Бибарс илчеләре 1264 елның 4 сентябрендә Алтын Урда башкаласына килеп җитеп, Бәркә ханга төрки телдә язылган җавап хатын укыйлар. Җавапка татарлар куанып шат булалар. Бу хаттан соң Бәркә хан да җавап хаты язып җибәрә[2].

Бибарстан килгән хатта ни язылганы хакында хәбәр сакланмаса да, аның эчтәлеген илчелек җибәрелүгә бәйле тарихи хәбәрләрдән, анда Хулагулар Иранына каршы Мәмлүкләр солтанатының берлек төзүгә өндәү булганлыгы бик ачык мәгълүм. Чөнки Бәркә

ханның Хулагулар Иранына каршы алып барган уңышлы сугышлары Мисырда симпатия уяткан.

Бибарсның Хулагулар Иранына каршы алып барган сугышлары тарихына атаклы «Солтан Бибарс» дастанында зур урын бирелә[3].

Чыңгыз империясенең каганы булган Гүюк ханның 1246 ел 3–11 ноябрьдә язылган хаты да Рим папасы Иннокентий IV нең чукынуга чакырган хатына карата Көнчыгышның катгый җавабы буларак мөһим. Гүюк хан папага «Мәңгелек Тәңренең куәтенә ия булган Далай хан, сүзем! Барлык бөек халкыбызга таянып, безнең боерыгыбыз...» дип башланган җавап хаты язып җибәргән. Ул фарсы телендә язылган һәм хәзерге көндә Ватиканда саклана. Гүюк папаның «чукыныгыз!» дип өндәвенә каршы, үз фикерен белдереп, «Күктәге бер Тәңрегә табынуын» христиан дөньясының мәҗүсилек элементлары белән чуарланган диненә каршы куя. Үзенең фәлсәфи карашларын даланың мең еллар буе камилләшеп килгән кануны – ясага таянып бәя кыла. Христианнарның, хәтта илчеләрне үтерү кебек кыргыйлыклары мисалында, түбәнлекләренә ишарә итә. Гүюк хан христиан Европасына үз халыкларының – монголларның, татарларның – аларга караганда, тарихның югарырак баскычында торуын дәгъва итә һәм сез, үзегез килеп, безнең бусагабызга егылыгыз, – дигән фикерләре белән, үзенең бөек дәүләтнең хакиме дәрәҗәсендәге кеше икәнен искәртә.

Бу хаттагы публицистик фикерләр XIII гасыр уртасында, тәре походлары оештыруга дәрте сүнмәгән христиан дөньясына, аларның Чыңгыз империясен үзләренең сәясәт арбасына утырту тәкъдименә горур җавап була.

Хәтта ки, Бәркә хан белән солтан Бибарсның хатларында да шушы публицистик фикер чагылышын тоярга мөмкин. Димәк, татар публицистикасы халкыбызның мөстәкыйльлеген XIII гасырда яклау чарасы буларак дөньяга килә.

XIII гасырдан Алтын Урда идарәчеләреннән калган документларның тагын берсе – Мәнгү Тимер ханның 1270–1276 еллар арасында урыс митрополитлары мәнфәгатьләрен яклап бирелгән ярлыгы.

Әлеге документтан күренгәнчә, Алтын Урда гражданнары тулы дин тоту ирегеннән файдаланганнар.

Ярлык тексты структурасы ягыннан Гүюк ханныкына охшаган. Аның да башы шундый ук трафарет гыйбарәләр белән башлана: «Бөек Тәңренең кодрәте, өчлекнең («Троица») кодрәте белән, Мәнгү Тимер сүзем – баскакларга, уң кул, сул кул бәкләренә, түмән бәкләренә, тамгачыларга, салым җыйнаучыларга, кятибләргә, илче-киләчеләргә, лачын-кошчыларына, барысчыларга, йөзем бакчаларын тамгалаучыларга һәм барлык тамга малы алучыларга...»

Әлбәттә, бу ярлык, беренче чиратта, христиан дине әһелләрен күз уңында тотып язылган. Анда христиан дине эшлекләре, чиркәүләр һәм аларның мөлкәте, абруе хан фәрманы белән саклануга гарантия бирелә.

Чиркәүләрне, иконаларны, китапларны, чиркәү хезмәтендә йөрүчеләрне җәберләү, аларны башка эшләрдә файдалану тыела[4].

Мәнгү Тимер ханның бу ярлыгы – әлеге ханны бу заман хакимнәреннән дә югары куярлык документ һәм прогрессив публицистик фикер.

Уздырылган күзәтүләр XIII гасыр татар публицистик фикернең XIII гасырда ук, дәүләт һәм шәхес иминлеге проблемасын тәэмин итү чарасы буларак, мәйданга чыгуын күрсәтәләр.

XIV гасырга кергәч тә Алтын Урда ханнарыннан Үзбәк ханның 1313 елда митрополит Петрга биргән ярлыгы Мәнгү Тимер хан биргән ярлык эчтәлегенә якын рәвештә язылган.

Ярлыкта христиан дине әһелләренә гел уңай мөгаләмә чагыла.

Янә 1379 елда митрополит Михаилга бирелгән ярлыкта (ихтимал аны, татарча оригиналын югалтып, монахлары үзләре теләгән фикерләрен язып куйган булса кирәк. – *М.Ә.*) татар илчеләрен һәм салым җыючыларны үтергән өчен, чиркәү хезмәткәрләре җавапка тартылмыйлар дигән бер сәер гыйбарә дә бар.

Соңыннан бу ярлык текстының чыннан да фальсификацияләнгән булуы ачыкланды. Ул ярлыкның тулы тексты 1937 елда ук тулысынча басылган икән. Әлеге тулы текстта 1971 елдагы басмадагы кебек тупас фальсификация юк.

Мондый документны логикасыз рәвештә фальсификацияләү урысның тарих чыганакларына үтә дә тәнкыйть күзе белән якын килүне таләп итә.

Алтын Урдада дин иреге булуын әле XV гасыр язма чыганакларында да табарга мөмкин. Мәсәлән, итальян сәяхәтчесе Иосафат Барбаро (1436–1452 елларда Дон елгасы тамагында татарлар арасында яшәгән) күчмә татарларның әле Сәйед Әхмәт хан заманында да (1433 елда исән була) арбаларында агачтан, яки чүпрәктән ясалган табыну курчаклары йөртүләрен хәбәр итә[5].

Себер якларында яшәгән татарларда XV гасырда курчакка табынучылар булу хакында язма чыганаклар бар. Күренекле галим, төрки телләр белгече Н.Ф. Катанов, Тубыл музеенда саклanучы Әбу-Сәгыйд улы Кашшаф кулъязмасына таянып, XV йөздә Иртыш елгасы буйларында курчакка табынып яшәүче татарларны ислам диненә кертү тарихын искә ала[6].

Казан артындагы бер авылда, хан кызыныкы дигән кабердә, аның алтын курчак белән күмелүе хакында риваять әлегәчә сакланган.

Татар ыру-кабиләләренең күчмә тормыш белән яшәгән төркемнәре XV йөздә ислам кабул итеп бетергәннәр дияргә мөмкин, чөнки бу темага кагылышлы язма чыганаклар күрсәтелгән дәвердән соң фәнгә мәгълүм түгел.

XIV гасыр ахырында Алтын Урда ханнары кулыннан чыккан ярлык һәм рәсми хатларда инде бүтән проблемалар искә алына. Аерым алганда, Туктамыш хан белән Аксак Тимер арасындагы сугышлар нәтиҗәсендә туган хәлләр күздә тотыла.

Туктамыш хан гаскәрләре 1391 елда Кондырча елгасы

буендагы Аксак Тимер гаскәрләре белән сугышта җиңеләләр. Җиңелүгә Алтын Урдада ханга каршы 1389 елда фетнә күтәргән Бәкбулат бәк һәм аның тарафдарлары сәбәпче булалар, чөнки алар кул астындагы күп санлы гаскәри төркемнәр Алтын Урданың иминлеге, бөтенлеге өчен сугыштан читләшеп калалар, фронтны ташлап качалар. Әлеге фетнәчеләр, Туктамыш кулыннан властьны тартып алырга теләп, Алтын Урдада гражданнар сугышы чыгаралар һәм илне көчсезләндерүгә үзләреннән саллы өлеш кертәләр. Алар Идегәй белән бәйләнештә булып, аның аркылы үзләренең хыянәтләре хакында Аксак Тимергә хәбәр ирештергәннәр[7].

Туктамыш ханның 1393 елның 25 маенда Польша короле Ягайлога язган ярлыгы, ул вакытта илдәге сәяси хәлнең тотрыклы хәлгә ирешүе хакындагы рәсми хәбәр базасы булып тора. Ягайлога хәбәрне Котлыбога һәм Әсән җитәкчелегендәге илчелек җиткергән. Ярлык мәгълүматына караганда, хан нәселеннән булган угланнардан Бәкбулат һәм Хуҗа Мәдин – йогынтылы бәкләрдән Бигеч, Тордучак, Берди һәм Давытны үзләренең хыянәтен хәбәр итәргә Аксак Тимер лагерена җибәреп, Ватаннарына каза чакырып китерүгә юл ачалар.

Шундый ук хыянәтләр аркасында, Туктамыш армиясе 1395 елгы сугышта да җиңелә. Аксак Тимер бу сугышта, әзер хыянәтчеләрдән тыш, татарлар арасында акчага сатылучылардан да киң файдаланган. Соңгы сугыштагы җиңелү Алтын Урданы аякка баса алмаслык итеп җимерелүгә китерә. Аксак Тимер гаскәрләре татар шәһәрен һәм авылларын талау белән генә чикләнмичә, аларны нигезләренә кадәр мәгънәсезгә җимереп йөриләр һәм тыныч халыкны кыралар, таза кешеләрне, һөнәрчеләрне Сәмәркандка йөзәр меңләп куып алып китәләр. Шул чагында Идегәй һәм башка бәкләр, үз кешеләрен алып, Аксак Тимердән качып китәләр.

Туктамышның Ягайлога 1393 елда җибәргән ярлыгы һәм хаты шул елдагы хәлне бөтен чынбарлыгы белән ачып бирә[8]. Туктамыш ханның хатында сатылган бәкләрнең каты җәзага тартылулары да әйтелә. Ханның ярлык һәм хатларындагы кыска җөмләләрдә татар халкының иң явыз дошманнары үз араларында булган хыянәтчеләр икәне турындагы васыяте шикелле булып калган һәм бу фикер татарның тарихындагы авыр вакытларында дөрескә чыга.

Алтын Урда җирендә 1397 елда хан булып утырган Тимер Котлыг ханның шул елның 30 апрелендә бирелгән тарханлык ярлыгы[9] аңарчы бирелгән һәм тарихта мәгълүм булган ярлыкларга охшамаган.

Анда дәүләтнең идарә аппаратында нинди баскычлар һәм административ идарәчеләр булуы турында, хуҗалыгының әйдәп барган тармагы кайсы булу, административ аппаратларының тармаклары турында ышанычлы хәбәрләр бар. Югыйсә, бер генә язма тарихи чыганакта да бу мәгълүматлар бер урында шулай санап күрсәтелми. Бу типтагы ярлыклар соңыннан XV–XVI йөз-

ләрдәге татар дәүләтләрендә шактый санда мәгълүм.

Тимер Котлыг ханның ярлыгы Кырымда Саин (Бату) хан заманнарыннан бирле тархан булып килгән нәселгә нисбәтле. Аларның биләмәләре хәзерге Кырымда Судак шәһәре янындагы борынгы Ындырчы саласында булган.

Бу документ үзенең структурасы, теле һәм сословие, патронимнары, тарихи лексикасы белән дә соңгырак дәвердә Казан һәм Кырым ханлыкларында бирелгән тарханлык ярлыкларына бик якын тора. Димәк, Казан һәм Кырымда бирелгән тарханлык ярлыклары стиле инде Алтын Урдада XIII йөздә үк гамәлдә булган.

Инде XIII–XIV йөзләрдә Алтын Урда дәүләтендә гамәлдә булган тарханлык ярлыклары, чит ил хакимнәренә җибәрелгән рәсми хан ярлыклары, ханнарның һәм олы бәкләрнең хатларына ясалган күзәтү, аларның тарихлары жанр буларак борынгы Төрки Каганлыкларыннан бирле килгән традицион документлар, публицистик фикер, мирас булуына инандыра.

Алар, безнең публицистик жанр теленең чарланып үткән борынгыдан килгән мирасы.

Татар публицистикасы теле һәм стиле һәр үткән гасырда туган рәсми документлар, язмалар аркылы үсеп килә.

**Искәрмәләр**

[1] Из «Прямого пути» Эль-Муфаддаля // История Татарии в материалах и документах. М.: Государст. социально-экономическое изд-во, 1937. С. 71–72.

[2] Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Том 1. Извлечения из сочинений арабских. СПб., 1884. С. 64.

[3] Путешествие в восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М.: Гоударст. изд-во географической литературы, 1957. С. 32–33, 220–221.

[4] Ярлыки, данные золотоордынскими ханами русским митрополитам... // Сборник документов по истории СССР. Часть X–XI вв. М.: Высшая школа, 1971. – С. 183–184.

[5] Барбаро и Контарини о России. Л.: Наука, 1971. С. 140.

[6] *Катанов Н.Ф.* О религиозных войнах учеников Шейха Багауддина против инородцев Западной Сибири. – Тобольск, 1905. – С. 13.

[7] *Миргалиев И.М.* Войны Токтамыш хана с Аксак Тимуром. Казань, 2003. – С. 14.

[8] Ярлык Токтамыш-хана польскому королю Ягайлу 1392–93 г.; Письмо Токтамыш-хана Ягайлу // История Татарии, в материалах и документах. М.: Госуд. социально-экономичес. изд-во, 1937. С. 72–73.

[9] Ярлык Тимур-Катлауга // История Татарии в документах и материалах... С. 57–58.

***Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 82.09:821.512.122

***Х.Й. Миңнегулов***

# КИҢ КОЛАЧЛЫ КАЗАКЪ ГАЛИМЕ (КҮЛБӘК ЕРГОБӘК)

В статье освещаются жизнь и многогранная деятельность известного казахского ученого-литературоведа, педагога, журналиста, общественного деятеля Кулбека Серсеновича Ергобека (1952 г. рождения), а также взаимосвязи казахской и татарской литератур.

**Ключевые слова:** казахское словесное искусство, Кулбек Ергобек, литературовед-критик, Международный казахско-турецкий университет (г. Туркестан), татарско-казахские литературные взаимосвязи.

Төрле кыенлыкларга, иҗтимагый-сәяси зилзиләләргә дә карамастан, соңгы йөз елдан артык вакыт эчендә, аеруча XX–XXI гасырлар арасында казакъ әдәбияты, сәнгате, фәне гаять зур уңышларга иреште. Бу чорда, мәсәлән, сүз сәнгатендә бөек Абайга (1845–1904) алмашка күпләгән талантлы каләм әһелләре килде: Шәкәрим (1858–1931), Мохтар Ауэзов (1897–1961), Магжан Жомабаев (1895–1938), Беимбет Майлин (1896–1938), Сакен Сәйфуллин (1894–1939), Сабит Моканов (1900–1973), Габиден Мостафин (1902–1984), Габит Мусрепов (1902–1985), Солтанмәхмүт Торайгыров (1893–1920), Сабит Донентаев (1894–1933), Әбдиҗәмил Нурпеисев (1924), Әнвәр Алимжанов (1930–1993), Олжас Сөләйманов (1936), Мохтар Шаханов (1942)... – боларның һәрберсе үзе бер дөнья, кабатланмас күренеш. Шунысы кызыклы: бу затларның шактые, аеруча XX йөзнең беренче чирегендә яшәгәннәре, татарлар белән тыгыз мөнәсәбәттә тора: татар мәктәп-мәдрәсәләрендә («Галия», «Хөсәения»...) укый. Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, М. Гафури... иҗатлары белән таныш була, Уфа, Казан, Оренбургтагы татар нәшриятларында, газета-журналларында үзләренең әсәрләрен бастыра. Мәсәлән, Магжан Жомабаевның «Чулпан» дип исемләнгән тәүге шигырьләр җыентыгы, Г. Ибраһимов ярдәме белән, 1912 елда Казанда дөнья күрә. Сабит Донентаев үзенең шигырьләр мәҗмугасын («Вактөяк») 1915 елда Уфада бастыра.

Казакъ сүз сәнгатенең тәрәккъыятенә әдәбият фәненең, тәнкыйтьнең ныклап үсеше дә зур йогынты ясый. Шунысы мөһим: югарыда телгә алынган әдипләрнең күпчелеге бер үк вакытта әдәбият галиме, тәнкыйтьче буларак та чыгыш ясый. Болардан тыш, сүз сәнгатен гыйльми өйрәнүдә профессиональ әдәбиятчылар нәтиҗәле шөгыльләнәләр: Бейсенбай Кенжебаев (1904–1987), Зәки Әхмәтов (1928–2002), Рымгали Нургалиев (1940–2010), Турсынбек Кәкишев (1927), Сейит Каскабасов (1940), Куныпия Алпысбаев (1949) һ.б.

Болар арасында Күлбәк Ергобәкнең дә үзенә лаеклы урыны бар.

Көньяк Казакъстанның тарихи Отрар төбәгендә туып (26.12. 1952), шул тарафтагы мәктәпләрдә укыган, алты яшендә үк әтисез калган бу зат 1970–1975 елларда Алматыдагы атаклы дәүләт университетының филология факультетында югары белем ала. Алга таба аның күпләрне кызыктырырлык хезмәт биографиясе башлана: Мохтар Ауэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институтында (Алматы) лаборант (1975–1976), өлкән гыйльми хезмәткәр (1990–1992), баш фәнни хезмәткәр, «Хәзерге казакъ әдәбияты» бүлегенең җитәкчесе (1997–1999), Мәдәният министрлыгында методист (1976), С. Муканов музей-йортының (Алматы) өлкән фәнни хезмәткәре (1976–1978), гыйльми җитәкчесе (1980–1987); Республика газеталарында журналист [«Лениншил жас» («Жас алаш») – 1978–1980; «Социалистик Казакъстан» («Егемен Казакъстан») – 1987–1990], Көньяк Казакъстан өлкә җитәкчесенең урынбасары (1999–2003)... Болардан тыш, ул – консерваториядә доцент; Югары аттестация комитетында (ВАК) – гыйльми секретарь; Төркестан шәһәр мэрының ярдәмчесе, «Акикат» («Хакыйкать») журналында бүлек мөдире һәм башка урыннарда да эшләп ала. Күлбәк Сәрсенулы табигате белән сәләтле, җаваплы, тырыш, белемгә, яшәүгә омтылучан, энергияле зат. Төрле урыннарда эшләү, төрле кешеләр белән аралашу аның табигый, шәхси сыйфатларын тагын да ныгыта, үстерә, камилләштерә. Ул кешеләр белән тиз аралаша, уртак тел таба белә, тапшырылган эшне, үз вазыйфаларын җиренә җиткереп, намус белән башкарырга омтыла. Аның бу төр сыйфатларын, эш-гамәлләрен иптәшләре, хезмәттәшләре, студент-аспирантлары ассызыклап, искә төшереп тора. Мин үзем дә аларның фикер-бәяләренә бик теләп кушылам. Чөнки миңа да, гәрчә сирәгрәк булса да, Күлбәк әфәнде белән Астанада, Төркестанда, Алматыда, Казанда берничә мәртәбә очрашырга, сөхбәтләшергә туры килде.

Әйткәнебезчә, бу зыялы зат чыгышы белән Көньяк Казакъстаннан, Сыр-Дәрья тирәсендәге мәшһүр Төркестан (Ясы, Ясса) якларыннан, Әхмәд Ясәвинең (вафаты – 1166 елда) якташы дисәк тә хата булмас. Төркестан – шактый борынгы кала. 2000 елның 20–21 октябрендә киң күләмдә аның 1500 еллыгы билгеләп үтелде. (Казакъстанның президенты Н. Назарбаев чакыруы белән Татарстанның рәсми делегациясе составында миңа Төркестанда бәйрәм тантаналарында катнашырга туры килгән иде). Бу шәһәрдә төркиләрнең бөек шагыйре, шәехе Әхмәд Ясәви җирләнгән. Төркестан каласын, еш кына, «мөселманнарның икенче Мәккәсе» дип тә йөриләр. Ул – хәзерге вакытта төркиләрнең, аеруча казакъларның бик тә мөһим рухани, гыйльми, мәгърифәти мәркәзләренең берсе. Биредә 1991 елдан бирле Хуҗа Әхмәд Ясәви исемендәге Халыкара казакъ-төрек университеты эшли.

Туган як гомер буе адәм баласын үзенә тартып тора. Бу

табигый хакыйкать Күлбәк әфәнде мисалында да ачык күренә. Ул Халыкара казакъ-төрек университеты ачылуның икенче елында ук Төркестан каласына кайта. 1992–1997 елларда казакъ-төрек университетында доцент, профессор, кафедра мөдире, тарих-филология факультетының деканы, ректорның гыйльми эшләр буенча урынбасары булып эшли. Соңгы дистә елда Күлбәк Сәрсенулы Х.Ә. Ясәви университетының вице-президенты, фәнни эшләр буенча проректоры, Тюркология институтының директоры, халыкара «Тюркология» («Түркология») журналының баш редакторы вазыйфаларын башкара. Ул – күпсанлы филолог-галимнәрнең, журналистларның, әдәби тәнкыйтьчеләрнең остазы.

Күлбәк әфәнде студент елларында ук төрле темаларга багышланган язмалары белән матбугатта чыгышлар ясый башлый һәм тиз арада популяр яшь авторларның берсенә әверелә. Күренекле профессор Бейсенбай ага Кенжебаев 1981 елда ук аның «күпкырлы, нәтиҗәле эшчәнлеген, активлыгын» югары бәяли. Бераздан Казакъстанның халык язучысы Әбиш Кекилбаев (1939 елгы) Күлбәк Сәрсенулын «күренекле галим» дип атый.

К. Ергобәкнең гыйльми-тәнкыйди һәм мәдәни эшчәнлеге узган гасырның соңгы дистә елында аеруча активлашып китә. Казакъстанның мөстәкыйльлек алуы, яңа шартлар, милли күтәрелеш, энтузиазм, иҗтимагый ихтыяҗлар – болар бар да яшь галимне дәртләндерә, төрле тармакларда илһамланып эшләргә этәргеч бирә. 1991 елда ул кандидатлык диссертациясен яклый. Озак та үтми (4 елдан соң) ул фән докторы да була. Аның докторлык диссертациясе олуг әдип, җәмәгать эшлеклесе С. Мукановның бай һәм күпкырлы иҗатын тикшерүгә багышланган. Мәгълүм ки, Күлбәк әфәнде бу язучыны аның музей-йортында эшләгән вакытлардан бирле өйрәнеп килә. Сабит Муканов хакында аның берничә китабы, күпләгән мәкалә-хезмәтләре бар. Ул бу әдипнең әсәрләрен туплап бастыру белән дә шөгыльләнә.

Күлбәк әфәнде – киң колачлы, масштаблы, эрудицияле галим. Аның язмаларында казакъ сүз сәнгатенең үткәне һәм бүгенгесе дә, идея-проблематикасы, жанрлар системасы, поэтикасы да, халыкара бәйләнешләре дә яктыртыла. Ул балалар әдәбиятын һәм фольклорны да читләтеп үтми. Аның китапларында, мәкалә-хезмәтләрендә казакъ сүз сәнгатенең Абай, Шәкәрим, М. Ауэзов, Жамбул, Б. Майлин, М. Жомабаев, Г. Мусрепов, Сырбай Мәуленов (1922–1993), Өтебай Турманжанов (1905–1978), Ә. Нурпеисов, Рахманкол Бирдебаев (1927 елгы), Жубан Молдагалиев (1920–1988) һәм башка бик күп билгеле затлары хакында кызыклы күзәтүләр, мөһим фикерләр бар. Күлбәк әфәнденең Чыңгыз Айтматов, урыс һәм кайбер башка халыкларның әдипләре турындагы карашлары да мөһим. Өстәвенә ул – тәҗрибәле текстолог та. Аның тарафыннан әзерләнеп дөнья күргән басмалар да шактый. Урыс, молдаван, төрек һәм кайбер башка

телләрдән казакъчага күчерелгән тәрҗемәләре дә бар.

Күлбәк Ергобәк – казакъ, урыс, төрек, үзбәк, кыргыз, уйгур, якут-саха телләрендә басылган 1000 нән артык мәкалә авторы. 30 дан артык китабы бар. Менә минем кулда аның автограф белән бүләк иткән «Өлеңсөз» («Шигъри сүз») китабы. 576 битлек бу саллы басма 2012 елда Алматыда дөнья күргән. Ул Күлбәк әфәнденең 60 яшьлеге, гыйльми-тәнкыйди, педагогик эшчәнлегенең 40 еллыгы уңае белән чыгарылган. Китапта авторның төрле елларда язылган мәкалә-хезмәтләре тупланган. Бай эчтәлекле бу китап казакъ рухи тормышының бер елъязмасы, энциклопедиясе кебек тә. Тел-стиле үтемле, бәян итүе, сөйләме, әдәби-публицистик әсәр кебек, мавыктыргыч, кызыклы. Аеруча язмаларның исемнәре оригиналь, иҗади. Алар, ничектер, мәкалә-хезмәтләрне кабул итүгә, аңлауга юнәлеш биреп тора (фотосурәтләр, иллюстратив материаллар да урнаштырылган булса, китап тагын да күркәмләнгән булыр иде).

Мәгълүм ки, казакълар һәм татарлар элек-электән аралашып, хезмәттәшлек кылып яшәгән. Моңа аларның этник һәм тел якынлыгы, күп кенә рухи байлыкларның уртаклыгы, бер үк яисә күрше дәүләтләрдә яшәве ярдәм иткән. Бу кавемнәрнең үзара аңлашып, керешеп гомер кичерүләренә аларның зыялылары да зур өлеш кертеп килгән. Күлбәк Сәрсенулы да бу тарихи тәҗрибәне, инсани хакыйкатьне тирәнтен аңлап эш итә. Аның язмаларында татар халкы, аның әдипләре (аеруча Г. Тукай), галимнәре, мәктәп-мәдрәсәләре, басмаханәләре, газета-журналлары, үзара хезмәттәшлеге хакында мөһим факт-мәгълүматлар бар. Ул очрашкан саен татарның аксакал әдәбиятчысы Мөхәммәд ага Гайнуллин, күренекле тәнкыйтьче, язучы Рафаэль Мостафин, шагыйрь һәм әдип Ркаил Зәйдулла һәм башкалар турында еш сорашып тора. Тукай бүләге иясе Рәдиф Гаташ, шагыйрә Флёра Тарханова Магжан Жомабаев шигырьләрен татарчага тәрҗемә иткәч, Күлбәк әфәнде үзенең куаныч хисләрен телдән дә, матбугатта да белдереп чыкты. Аның Казанда берничә мәртәбә булганы бар. «Казан утлары» журналы редакциясендә очрашуын еш искә төшерә. Тукайның тууына 125 еллык бәйрәмгә килеп, матур гына чыгышлар да ясап китте.

Казакъ галимнәре татар зыялыларын төрле чараларга еш чакырып торалар. Бу яктан Шакир Ибраев, Күлбәк Ергобәк кебек гыйлем ияләре эшләгән Халыкара казакъ-төрек университеты татарларга аеруча игътибарлы. Без фәкыйрегезнең генә дә анда берничә мәртәбә булганы, конгресс-конференцияләрдә докладчыгышлар ясаганы бар. 2004 елда бу мәшһүр уку йортының «шәрәфле профессоры» итеп сайлану да минем тормыштагы истәлекле вакыйгаларның берсе булды. Андагы гыйльми басмаларда мәкаләләрем дә басылып тора.

Әхмәд Ясәви исемендәге университет нигезендә 2002 елдан бирле казакъ, төрек, инглиз һәм урыс телләрендә халыкара

«Төркология» журналы чыгып килә. Аның сәхифәләрендә татар галимнәренең (шул исәптән минем үземнең дә) язмалары басылып тора. Казаннан М. Зәкиев белән бу журналның редколлегия составына да кертелдек. Аның 2014 елгы март (67) санында Күлбәк Ергобәкнең казакъ телендә «Татарның күренекле тюркологы» (төректанушысы) исемле күләмле һәм бик тә эчтәлекле мәкаләсе урнаштырылган. Биредә сүз безнең хакта гына түгел, ә татар-казакъ бәйләнешләре, дуслыгы хакында да бара. Бу төр фактларны без үз шәхесебезгә – «Казакъстан кияүенә» – карата гына түгел, ә татар халкына, аның әдәбиятына да ихтирам, хөрмәт билгесе итеп кабул итәбез.

2014 елның 21 ноябрендә Астанадагы Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия Милли университетында Семи (Семипалатинск) кызы Арай Жундибаева «Шәкәрим иҗатын өйрәнү тарихы һәм укыту методикасы» темасына бик тә уңышлы рәвештә докторлык диссертациясен яклады. Күлбәк әфәнде җитәкчелек иткән бу хезмәтнең рәсми гыйльми киңәшчесе (консультанты) мин идем. Шунда мин Сәрсенулы Ергобәкнең яшь галимәгә дөрес юнәлеш бирүенә, аны дәртләндерә, эшләтә белүенә сокланып йөрдем.

* * *

Күлбәк әфәнде Мөхәммәд пәйгамбәр яшенә зур хезмәтләр белән килеп җитте. Аның нәтиҗәле эшчәнлеге күп төрле бүләкләр, дәрәҗәле исемнәр белән бәяләнгән. Бу абруйлы, уңган затка без киләчәктә дә уңышлар, исәнлек телибез. Алдагы көннәрендә дә ул казакъ – татар, Казакъстан – Татарстан мөнәсәбәтләрендә дуслык күпере салучы, рәсми булмаган илче, вәкил булып калсын.

***Миңнегулов Хатыйп Йосыф улы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы*

УДК 821.512.145

***А.Ф. Ганиева-Гыйниятуллина***

# ГАРИФ АХУНОВНЫҢ СОҢГЫ ЧОР ИҖАТЫНДА ЯҢА ЭЗЛӘНҮЛӘР

Творчество Г. Ахунова приходится на тот период, когда в стране процветал социализм. Будучи ведущим писателем того времени, естественно, его произведения написаны в рамках социалистического реализма. Что же касается его поздних произведений – романа «Идел кызы» и повести «Этләр патшасы», они отличаются от других тем, что написаны с совершенно иной позиции.

**Ключевые слова:** Гариф Ахунов, роман, повесть, главный герой, сюжет, литература, общество.

Язучы иҗатын күпләр җирдән бәреп чыккан чишмә белән чагыштырса, мин тирән кое белән чагыштырыр идем. Белем алу – энә белән кое казу, диләр бит. Коеның тирәнлеге язучының аң-белеме, тормышны белү дәрәҗәсе, сәләте белән билгеләнә. Кое никадәр тирәнрәк булса, суы да тәмлерәк, сафрак. Табигый, андый суның файдасы кеше өчен күбрәк була. Г. Ахунов иҗаты да шундый коеларның берсен хәтерләтә. Татар әдәбиятында аның үз йөзе, үз сүзе бар. Ул совет рухында тәрбияләнеп, үзе ышанган коммунистик идеологиягә тугъры калып, ярты гасыр дәвамында туган халкына хезмәт итте. Төрле җитәкче урыннарда эшләү белән беррәттән, татар совет прозасы чәчәк аткан чорда әйдәп баручы язучыларның берсе булды.

Әйе, заманнар үзгәрә тора, аның ачы җилләре Г. Ахунов әсәрләренең төсен уңдырды. Әмма «заказ буенча язылган» дигән тамга сугып, «Хәзинә», «Хуҗалар», «Чикләвек төше», «Ардуан батыр» кебек роман-повестьларны без тарих киштәләреннән алып ташласак, бик зур хата булыр иде. Чөнки, беренчедән, бу безнең тарихыбыз, яхшымы-яманмы ул – без һәм безнең үткәнебез. Алдагы буыннар аларны укып, шул чор сулышын тоярга, аңларга тиеш.

Икенчедән, алар чын сәнгать җимешләре, хәзерге кебек, иҗат ирегеннән файдаланып, чилепешле язылган әсәрләр түгел. Һәр таякның ике башы булган кебек, совет чорында бер уңай күренеш бар иде: әдәби әсәрләрнең сәнгати ягына да зур игътибар бирелә иде. Тиешле дәрәҗәдәге тәнкыйть булмау хәзерге әдәбиятыбызны сыйфат ягыннан бик түбәнәйтте.

Өченчедән, хезмәткә хөрмәт, хезмәт кешесенә ихтирам бар бу роман-повестьларда. Әхлак, намус төшенчәләрен бар нәрсәдән өстен куеп яшәгән геройларны үзләренә үрнәк итеп, аларга охшарга тырышып, ничә буын тәрбияләнде. Хәзерге укучы аларның беркатлылыгына соклана гына ала.

Шулар өстенә язучының, теләгән очракта да, идеологик

кысалардан чыга алмавын, партия күрсәтмәләре нигезендә генә иҗат итәргә мәҗбүр булуын исәпкә алырга кирәк.

Ә менә «Идел кызы» роман-дилогиясе (1978) һәм «Этләр патшасы» повесте (1989) турында, Г. Ахунов иҗатын гына түгел, бөтен татар әдәбиятын нур булып балкытып торучы әсәрләр, дияргә мөмкин. Алар язучының башка әсәрләреннән бөтенләй үзгә позициядән чыгып язылулары белән аерылып торалар.

Бер яктан, иҗади тәҗрибә арту, икенче яктан, 1970–1980 елларда илдә барган гомум тенденцияләр Г. Ахунов иҗатына кискен борылыш алып килә. Моңарчы инанганнар шик астына алына, мәңге булыр кебек тоелган социалистик яшәү рәвешенең нигезе какшый. Язучы йомгакның җеп очын барлый, хатаның кайда киткәнлеге турында уйлана. Шул рәвешле, халкыбызның катлаулы борылышлар чоры турында киң диапазонлы тарихи әсәр – «Идел кызы» иҗат ителә. «Роман совет хакимияте елларында системаның асылын, идеологик кысуларның, хакимлекнең асылын күрсәтеп биргән беренче әсәрләрдән булды. А. Гыйләҗев, Ә. Еникиләр бу темага юл салган булса, Г. Ахунов бу мәузугның яңа катламнарын ачуга җитди өлеш кертте, дисәк тә ялгышмабыз»[ Гайфуллина, б. 79], дип яза Г. Ахуновның иҗатын җентекләп өйрәнүче галимә Ф. Гайфуллина.

«Идел кызы» әсәре Нуриянең дөньяга тууы белән башланып китә. Бу көнне баланың атасы Габбас хәзрәт көндәлегенә язып куя: «1901 сәнә, 17 гыйнуар, җомга көн, иртәнге алты. Кызым Нурия туды. Гасыр башында. Бәхетең белән, төкле аягың белән, балам!» [Ахунов, 1978, б. 13]. Автор гасыр башы булуын махсус искәртә, шуның белән XX йөз кешесенең күргән-кичергәннәрен язарга алынуын белдерә. Нурия әсәрнең төп героинясы булырга тиеш кебек, әмма беренче кисәктә аның турында аз бирелә. Сюжет җебе Габбас хәзрәт белән Солтанга бәйле үстерелә. «Идел кызы» атамасының да Нуриягә кагылышы шартлы гына, чөнки автор әсәр исемен күпкә киңрәк мәгънәдә алган. Идел – ул безнең халкыбыз да (шул тирәдә яшәүче булырак), ул безнең тормышыбыз, язмышыбыз да. Шулай дип уйларга нигез бар, чөнки төп вакыйгалар барган Зартугай авылы Идел буена түгел, Чулман елгасы буена урнашкан.

Роман күп геройларның тормышын, аларның төрле карашларын, заман белән бәйле катлаулы хәл-әхвәлләрен үз эченә ала. Вакыйгалар да бер авыл кысаларында гына калмыйча, Алабуга, Әгерҗе, Мәскәү, Казан калаларына күчерелә. Шул рәвешчә автор аерым кешеләрнең язмышы мисалында татар халкының тормышында гаять мөһим булган дәвернең тулы канлы картинасын күз алдына китереп бастыра. Әсәрдә милли гореф-гадәтләргә, йолаларга да зур урын бирелә.

«Идел кызы»на бәя биргәндә бер чиктән икенче чиккә ташлану күзәтелә. Роман басылып чыккан елларында коммунистик идеология кысаларында каралса, 1990 еллардан соң ул большевизм-

ның ерткычлыгын, гаделсезлеген күрсәтүче әсәр дип бәяләнә. Язучының осталыгы нәрсәдә: ул бернинди иҗтимагый юлдан китмичә, нейтраль позициядән – гомумкешелек югарылыгыннан – торып яза алган. Г. Ахунов акларның да, кызылларның да кансызлыгын реаль гәүдәләндерә. Ата улны, ана кызны белмәгән дәвер. Әдип әсәрен язганда үзләре шул вакыйгаларны кичкән кешеләр белән аралаша, чор катлаулылыгын дөрес бирергә омтыла.

Соңгы еллар әдәбиятында күзәтелгәнчә, күп кенә язучылар революциягә кадәрге чорны язганда байлар тормышын идеаллаштыру юлына кереп китәләр. Имеш, алар хәләл көчләре белән баеп, үз эшчәнлекләре, акыллары белән көн күргәннәр. Җәмгыятьнең дөрес яшәү рәвеше шулай булырга тиеш, әлбәттә. Әмма Рәсәйдә хезмәт кешесенә тиешеннән күпкә аз түләү, крестьянны җирсез тилмертү соң чиккә җитә. Үлекләп шешкән чуан тишелмичә кала алмый, берсүзсез, илдә үзгәрешләр котылгысыз була. Әмма яңа җәмгыять нинди булырга тиеш? Монысы инде икенче мәсьәлә һәм иң мөһиме.

Габбас хәзрәт, күпләр билгеләп үткәнчә, – Г. Ахуновның уңышы, татар әдәбиятында моңарчы күрелмәгән яңа образгерой. Ул – халкыбызның бик күп милли асыл сыйфатларын үзендә туплаган көчле рухлы, белемле, намуслы, хезмәт сөючән, итагатьле, сабыр холыклы милли характер. Әсәрнең буеннан-буена килгән сагыш-моң да аның кичерешләре белән бәйле. Әсәр борчу белән башлана, укучының йөрәген әрнетеп торган хәвеф белән дәвам итә, ахыр чиктә фаҗига белән тәмамлана. «Халыкка аң-белем таратып, дөньяга мәгърифәт нуры сибеп» яшәргә теләгән Габбас мулла үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүче комсыз Сөләйман хәзрәт, кызыл малчы Габделхәлим, эшкуар Тәминдар Тураевлар җәмгыятендә дә үзенә урын таба алмый, янәсында да аңа урын юк. «Бәхетемне күктән көтмәдем, халыкны рәнҗетмәдем, байларга койрык болгамадым. Мин дөньяда үзем аңлаганча, туры яшәдем», – ди ул кызы Нуриягә язган хатында.

Бер караганда, дин кешесенең мордарлыкка баруы – гафу итмәслек нәрсә. Язучы бу юлны сайларга тиеш түгел иде кебек. Тик Г. Ахуновка героеның рухи юкка чыгарылуын күрсәтү кирәк. Рухы булмаган кешенең матди тереклек итүенең мәгънәсе юк. Бөтен куанычы, газизе булган кызы белән арасы өзелү, динен, иманын аяк астына салып таптау, янгыннан соң бөтен егәрен биреп салган йортын, яшәү урынын тартып алу, төрле мыскыллаулар – болар берсе дә эзсез калмый, әлбәттә. Наҗия кебек ни әдәбе, ни иманы, ни акылы булмаган затларга дөнья камчысын тоттырып, аларның башбаштаклыкларына юл куелу үзе үк җәмгыятьнең ялгыш юлдан китүен күрсәтә.

Романны нурландырып, ямь биреп торган, укучының мәхәббәтен яулаган гүзәл героиня Нуриянең, институтка алмауларыннан куркып, әтисеннән баш тартуы – шулай ук коточкыч хәл. Ата белән бала арасындагы изге

мөнәсәбәтнең юкка чыгарылуы, буыннар өзелү дә чор фаҗигасе буларак бирелә. Язучы болар белән яңа җәмгыятьнең нигезе үк черек булуын тагы бер кат ассызыклый.

Дилогиянең икенче кисәге, беренчесенә караганда кайтышрак чыкса да, шул ук максатка җавап бирә. Тоталитар система үзен кабул итмәгәннәрне генә түгел, ә партиягә җанын бирердәй ышанып, аңа хезмәт итүчеләрне дә корбанына әвереләдерә. Без моны Солтан, Чишмәбай мисалларында күрәбез.

Г. Ахунов «Идел кызы» романы белән татар әдәбиятына чын мәгънәсендә яңалык алып килә. «Шулай итеп, 1960–1980 еллар татар прозасын бигрәк тә олы жанрларда иҗат ителгән күпсанлы әсәрләре белән баеткан Г. Ахунов милли әдәбиятыбызны үзгәртүгә дә үзеннән зур өлеш кертә. Ул татар әдәбиятында кеше кадере, шәхеснең «хәзинә» булуы, кыйммәте турындагы сөйләшүгә килеп кушыла. Язучының «Идел кызы» дилогиясе инкыйлабка кадәрге татар авылы, татар дөньясы, муллалар хакындагы советчыл мифны җимерүгә юнәлтелгән зур әсәрләрнең беренчеләреннән була [Заһидуллина, б. 244].

Г. Ахуновның соңгы чор иҗатына караган «Этләр патшасы» повестенә тәнкыйть тарафыннан игътибар азрак булды шикелле. Әллә әсәрне аңлап бетермәделәрме, әллә башка сәбәптәнме, повестьның бүгенгә кадәр тиешле бәяне алганы юк. Ә бит «Этләр патшасы»н язучының иң уңышлы әсәрләреннән диярргә була. Язучы кешеләр арасындагы мөнәсәбәт, җәмгыятьтә һәм гаиләдә кешенең урыны турында уйлана. Кеше бәхетенең (бәхетсезлегенең) объектив һәм субъектив сәбәпләрен күрсәтә.

Әсәр төн уртасында янгын чыгу күренеше белән башланып китә. Бакчалар каравылчысы Акмалның хуҗалыгы янып юкка чыга. Повестьның беренче битләреннән үк төп герой Акмалга бәя бирергә мөмкин: ул тәвәккәл, көчле (йөз алтмышар килограммлы ике кислород баллонын күтәреп чыгара). Күршеләре дә аны сүзендә торуы, эшкә булганы, ярдәмчеллеге өчен хөрмәт итәләр икән, бәлагә тарыган гаиләне үзләренә сыендырырга әзерләр. Шулай да аның җаны тыныч түгел. Бу тынгысызлык янгын белән генә бәйле микән? Дөнья малын табып була, Акмалның җанын башка нәрсә борчый: хатыны Гөлбикә белән улының аңа карата салкынаюы. Борчылырга урын бар, бер тапкыр гаиләсен, улын югалткан кеше, кабат ул хәсрәтләрне күрергә теләми. Акмал яңабаштан үзенә йорт салырга керешә, язучы аның хәтерендә үткәннәрне яңарта.

Тормыш юлы сикәлтәсез генә үтмәгән Акмалетдин Зыятдин улының. Әтисе сугышта үлеп, балачактан ук ятим үсә малай. Шулай да намуслы, хезмәт сөючән, хайваннар ярата, кешеләрне хөрмәт итә белә торган булып үсә. Кулыннан килмәгән һөнәре юк, балта эшен әтисеннән ядкәр буларак өйрәнә. Әтисе Зыятдин оста куллы балта остасы була, сугышка кадәр үз кулы белән авылда берничә йорт

салып калдыра, шуңа да халык күңелендә аңа карата рәхмәт һәм ихтирам хисләре яши.

Рәссам булырга хыяллана егет, укырга керү теләге белән Казанга килә. Теләкләр генә тормышка ашмый. Көзге ясаучы Шаһислам абыйсы Акмалны уеннан кире кайтара, «тормышчанрак» һөнәр сайларга өнди. Бергәләп салырбыз да, унсигез яшең тулгач, үзеңә яздырырмын, дип йорт төзетә, әмма көтмәгәндә «кайгыртучан» абзасы үлеп китә һәм егеткә авылына кире кайтып китүдән башка чара калмый.

Наз-сөюгә сусаган егет Сәүдә исемле чибәр кызга гашыйк була. Бу мәхәббәт Акмалга бик кыйммәткә төшә. Сәүдә аркасында ул сугышып, гаепсезгә өч ел төзәтү колониясендә утырып чыга. Аннан кайткач, кызны гафу итеп, аңа өйләнә. Бу юлы да зур хата ясый: Сәүдә егет хисләрен бәяләрлек дәрәҗәдәге кеше булып чыкмый, матур гына яшәп ятканда башкалар белән хыянәт итә башлый. Гаилә таркала. «Йөрәктән кан тамарлык авыр булды аерылу – малай энисе ягында торып калды... Затлылык дигән сыйфат та чамалы икән Сәүдә Сафинада: улын бер күрергә тилмергән этисен ул Рафаэль янына якын да җибәрмәде» [Ахунов, 2005, б. 362]. Иң аянычлысы – Сәүдәнең тәртипсез яшәү рәвеше, мәгънәсез кыланышлары улларының фаҗигале үлеменә сәбәп була.

Акмал озак йөргәч, кабат өйләнә, балалы хатын Гөлбикәне ала. Уллары Гамил туа. Кызганыч, бала тудыру йортында ук сабый үпкәсенә суык тидереп, шәһәр һавасы ярамый торган булып кала. Акмал бала хакына бакчада яшәргә, каравылчы булып эшкә урнашырга мәҗбүр була.

Әсәрдә сюжет ике юнәлештә алып барыла. Төп сюжет сызыгы – Акмал язмышы: аның үткәне, бүгенгесе; икенчесе ярдәмче юнәлеш – төп геройның этләргә мөнәсәбәте. Язучы Акмалның гомере буе эт-мәчегә битараф булмавын яза. Моны, беренчедән, этисе әйткәнчә, аның Казанда «зверинсә» янында тууы, кечкенәдән төрле хайваннар күрүе белән аңлатса, икенчедән, тормышның гаделсезлеге, кешеләр арасында аңлашу тапмау егетне үз эченә йомдыра. Акмал эт-мәчедән күңел юанычы таба башлый. «Болар гадел, болар берәүне дә сатмыйлар, болар дуслыкның кадерен белүчеләр» [Ахунов, 2005, б. 353], – ди ул. Өе янганнан соң да ул этләрен, исән калган песие белән аның балаларын тәрбияләп, ашатып тора. Алар аңа бик кадерле, ул җан дусларын һәрвакыт яклап, явыз көчләрдән саклап килә. Шуңа автор Акмалны этләр патшасы дип атый. Исеменнән үк күренгәнчә, әлеге гыйбарәгә тирән мәгънә салынган. Этләр патшасы булып яшәү әйбәтме, начармы дигән сорау куйсак, әсәрне укыган кешеләр тиз генә җавап бирә алмаска мөмкин. Кайберәүләр әле беркатлылык белән «әйбәт» дип тә әйтер. Эт-мәчене ярату, табигать баласы булып яшәү яхшы нәрсә, әлбәттә. Әмма язучы – «Идел кызы» кебек роман биргән, гомуммилли проблемаларны тирән аңлап язган ил агасы –

югарырак мәсьәләләр күтәрергә тиеш иде кебек. Һәм ул шулай да.

Акмал – бөтен яктан килгән ир-ат. Язучы аның буй-сынын, кыяфәтен берничә тапкыр сокланырлык итеп сурәтли. Ул белемле, район газетасы редакциясендә корректор, тәрҗемәче, техник редактор булып эшли. Ул сәләтле рәссам да, сәнгать фәне буенча читтән торып Мәскәү халык университетын тәмамлый, рәсемнәреннән күргәзмәләр оештыра. Әмма шушы ир-ат әсәр ахырында беркемгә кирәксез булып, йортсыз-җирсез, малсыз бер сукбай хәленә кала. Ни өчен шулай килеп чыга соң?

Акмалның гомере буе хезмәтеннән, холкыннан файдаланалар. Инде икенче хатыны Гөлбикә дә, рухи кыйммәтләргә караганда, матди байлыкны өстен куйган адәм булып чыга. Юк кына сәбәпне бар итеп, аерылуга барып җитә. Казандагы фатирны, суд аша Акмалның көнне төнгә ялгап эшләгән бакча йортын тартып алып кына калмый, Сәүдә кебек, улы белән этисенең арасын өзә. «Чын хөкемнең – гаделлекнең бездә бит әле булганы юк, моны үз җилкәсендә татыды бит инде ул. Суд бездә йә власть вәкилен, йә хатын-кызны яклый. Әнә бит теге чакта «силсәвит Мәрдән» малаен, тәртипсезлекне үзе башлаган Тәүхитне түгел, үзен яклап көрәшкә ташланган Акмалны утыртып куйдылар. Әнә бит теге чакта Рафаэль берничек тә энисе ягында калырга тиеш түгел иде, энисенең тотнаксызлыгы, себерелеп йөрүе көн кебек ачык иде, аны этисе Акмал Булатов ягында калдырырга тиеш иделәр югыйсә, юк, алай эшләмәделәр, энисе Сәүдә ягында калдырып, фаҗигале үлемгә дучар иттеләр» [Ахунов, 2005, б. 381]. Юкса, ата кеше дә балага ана кебек үк хокуклы бит.

Г. Ахунов җәмгыятьтә ир кешенең дәрәҗәсе төшүгә бик борчыла. Ул, төп герой Акмал язмышы белән чикләнеп калмыйча, фикерен дәлилләү өчен, мисалга Хикмәтулла карт образын да бирә. Һәр язда лалә чәчәкләре үстереп, күрше-тирә хатын-кызларына өләшеп йөрүче сиксән яшьлек мөлаем карт көтмәгәндә үлеп китә. Акмал аның татар халкы тарихын ныклап өйрәнгән атаклы галим булуын соңыннан гына белә. Шәһәрдә затлы фатиры, дәрәҗәле урыннарда эшләүче ике кызы һәм улы була торып, аның җәй буе такталардан гына оештырып куйган алачыкта яшәвенә бик аптырый ул. Нигә исән чакта бу кешегә кадер-хөрмәт булмады икән, дигән сорауга җавап таба алмый. Автор җавапны укучыга Акмал язмышы мисалында бирә. Ана кеше баласын атасына карата хөрмәт хисе белән тәрбияләргә бурычлы. Юкса җәмгыятьтә буыннарның табигый бәйләнеше өзелүе бар.

Язучы әсәрендә шәхес культы чорындагы рухи имгәтүләр, туктаусыз куркытып торуларны ир кешенең дәрәҗәсе төшүгә китергән сәбәпләрнең берсе итеп күрсәтә. Дистә елларга сузылган мыскыллаулар, милләтнең каймагы булган гаярь ир-атларны атып бетереп, исән калганнарына коллык психологиясен сеңдерү шәхеснең горурлык хисен җимерүгә китерә. Отставкадагы пол-

ковник Нәсих Яббаров шул елларның «өрәге» кебек тоела. «Мин утыз җиденче елны халык дошманнарын чебен урынына кырдым, кырып бетерә алмаганнарын сөргенгә сөрдем» [Ахунов, 2005, б. 334], – дип мактана ул. Халыкны өркетеп яшәүгә күнеккән канэчкеч зат яңа корбаннар таләп итә. Инде кешеләргә кагылырга хокукы калмагач, Акмалның гөнаһсыз этләрен атып китә.

Инде этләр патшасы булу әйбәтме, начармы дигән сорауга кире кайтсак, начар, бик начар, дип җавап бирәбез. Акмал кебек уңган, бар яктан килгән ир-ат этләр арасында әвәрә-тәвәрә килеп йөрергә тиеш түгел, гаиләсенә баш булып, бәхетле, тулы канлы тормышта яшәргә, ил тоткасы булырга тиеш, дип әйтәбез.

Г. Ахунов «Идел кызы», «Этләр патшасы» әсәрләрендә милләт язмышы мәсьәләләрен яктырта. Аның бу иҗат җимешләре татар әдәбиятына яңалык алып килә: кешенең әхлакый матурлыгына соклану белән беррәттән, аның рухи какшавына, шәхес буларак юкка чыгарылуына тирән борчыла.

**Әдәбият**

Ахунов Г. Идел кызы: роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Беренче китап. 400 б.

Ахунов Г. Этләр патшасы // Ахунов Г. Сайланма әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 5 том: Повестьлар. Б. 314–382.

Гайфуллина Ф. Гариф Ахунов прозасы. Казан, 2003. 127 б.

Заһидуллина Д. Гариф Ахунов: социалистик реализм чикләрен узу // 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 234–244.

***Ганиева-Гыйниятуллина Айгөл Фирдинант кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145´373

*М.Р. Булатова*

# БАШКОРТСТАНДА ТУГАН ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ИҖАТЫНДАГЫ ТЕЛБИЗӘКЛӘР

В статье анализируются изобразительно-выразительные средства, используемые в художественных произведениях татарских писателей, уроженцев Башкортостана. В произведениях этих писателей, особенно в поэзии, омонимия и смежные с ней явления зачастую используются для экспрессии речи, также как средство языковой игры, для создания комического эффекта (на основе их использования обычно создаются каламбуры).

Изучение диалектизмов в художественном тексте раскрывает языковой потенциал уникальных региональных слов. Диалектные слова, попадая в художественную литературу, приобретают дополнительные оттенки и становятся средством художественной выразительности. Они позволяют точнее представить авторский замысел, глубже проникнуть в характер персонажей. В языке художественной литературы диалектизмы используются для изображения местных географических особенностей, специфики быта, культур.

**Ключевые слова:** татарские писатели, Башкортостан, художественные произведения, художественный стиль, языковые средства, омонимы, паронимы, парономасы, каламбур, диалектные особенности, диалектная лексика.

Башкортстанда туып үскән күпсанлы талантлар, шул исәптән әдипләр дә, гомумтатар рухи мирасын үстерүгә, баетуга гаять зур өлеш кертәләр. Язучылар арасында Шәмседдин Зәки, Мифтахетдин Акмулла, Гали Чокрый кебек элегрәк чор шагыйрьләре дә, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, М. Гафури, Ш. Бабич, Г. Ибраһимов, Ф. Кәрим, Н. Исәнбәт, М. Әмир, Ә. Еники, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, Н. Нәҗми, Ә. Атнабаев, Н. Фәттах, Ә. Баян, И. Юзеев, Х. Сарьян, С. Сөләйманова кебек XX йөз әдипләре дә, Р. Хәмид, Р. Гаташ, Р. Миңнуллин, С. Рәхмәтулла, А. Хәлим, М. Нәзиров, М. Кәбиров, Д. Булгакова кебек бүгенге каләм ияләре дә бар. Аларның һәркайсы бормаланып аккан Агыйдел, Җилем, Ашкадар, Сөн буйларын, урман-тауларга бай туган җирләрен, андагы гүзәллекне данлаган, фәлсәфи фикергә, уйкичерешләргә бай иҗатлары белән шул дөньяны сүз сәнгате аша тоя-күрә белү, хозурлану хисләрен уята. Ул әсәрләрнең халкыбызны, телебезне, динебезне, милли рухыбызны саклауда рольләре бик зур.

Тел белгече буларак, шәхсән миндә туган ягым Башкортстанда туып-үскән татар язучыларының әсәрләрендәге әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләре, бигрәк тә җирле сөйләшкә бәйле яклар зур кызыксыну уята.

Ныклы әдәби нормасы булган телдә диалект сүзләренең кулланылышы сөйләмгә һәрвакыт билгеле бер стилистик «тәм» бирә. Башкортстан татар

язучыларының әсәрләрендә дә җирле сөйләү үзенчәлекләре табигый чагылыш таба, аларның кайсы төбәктә туып-үскәнлеген күрсәтеп тора. Шунысы әһәмиятле: теге яки бу төшенчәне белдерер өчен кулланылган диалекталь сүз, эчтәлеккә ниндидер аһәң өстәп кенә калмыйча, әдәби телгә дә күчеп китәргә мөмкин.

Авазлар (фонетика) өлкәсендә туган төбәк сөйләме XX гасыр һәм аңа кадәр булган чордагы әдипләр әсәрләрендә ачык чагыла. Мәсәлән, М. Гафури һәм Дәрдемәнд шигырьләрендә шундый төп фонетик үзенчәлекләр күзәтелә: *ә~и: кәштә* – әд. киштә; *ү~өй: сүлә* – сөйлә, *әй~и*: *әпәй* – ипи, *г~к: чикә* – чигә, *ңл~лг*: *яңлыш* – ялгыш, *ңл~ңг: маңлай* – маңгай һ.б. Урта диалект сөйләшләренә хас булган *җ*-ләштерү *(җегерме* – егерме, *җуата* – юата, *җегет, җылмаеп)* һәм, киресенчә, *й*-ләштерү очраклары бар: *йир* – җир, *йиденче* – җиденче: *Вакыт үтә, вакыт үтә, төрле хәлләр инде* ***йитә*** (М. Гафури).

Грамматик диалекталь күренешләргә килгәндә, Башкортстанда туган татар язучыларына хас үзенчәлекләрнең берсе – иркәләү-кечерәйтүне белдерә торган *-кай*/*-кәй* кушымчаларының, әдәби тел белән чагыштырганда, актив кулланылуы. Дәрдемәнд шигырьләрендә аларның аеруча еш кулланылуы күзгә ташлана:

*Бак, кырмыска йөк ташый,*
***Бал корткае*** *– җанлы бал,*
***Кошкай*** *ояга мүк ташый,*
*Коштан, корттан гыйбрәт ал!*

Аның әсәрләрендә бу кушымчалар табигать күренешләренә, кешене сыйфатлый торган сүзләргә дә ялгана:

*Көлемсерәп көн башланды,*
*Җәйге күркәм таң белән.*
***Япраккайлар*** *да яшьләнде*
*Һәм тибрәнде күк үлән.*

***Тәнкәен*** *ак,* ***түшкәйләрен*** *киң*
*яраткан,*
***Биткәенең*** *иң очында миң*
*яраткан.*
*Саклар өчен зифа буен яман*
*күздән*
***Чәчкәйләрен*** *аяк белән тиң*
*яраткан!*

Башкортстан татар язучыларының үзенчәлеге тагын шунда: әлеге кушымча абстракт мәгънәле яки җансыз әйберләрне белдерә торган исемнәргә, сыйфатларга, алмашлыкларга, бәйлек сүзләр һәм ымлыкларга да ялганып килә:

*Тау* ***аскайларында*** *бөрлегән,*
*Тау* ***өскәйләрендә*** *карлыган...*

Дәрдемәнд иҗатындагы бу үзенчәлек шигырьләрнең эчтәлеген аеруча җылылык, эчкерсезлек, ярату, соклану, назлау төсмерләре белән баета: *канаткайлары, чишмәкәй, сөмбелкәем, бөдрәкәй, фәрештәкәй, пескәем.*

Хәзерге заман хикәя фигыльнең әдәби телдәге *-ый*/*-и* кушымчасы белән бергә *-ай*/*-әй* варианты да очрый: *Эш булмагач, болар йөри* ***кабаланмай*** (М. Гафури).

*Җәдид(н)е, кадим(н)е һич*
***тикшермәй,***
*Берьюлы голәмәдән дәрес алсак...*
(М. Гафури)

Теләк фигыленең киң варианты кулланылуы, ягъни *-им*/*-ыйм, -ик*/*-ыйк* кушымчалары

урынына *-әем (әйем)/-аем (айым), -әек (әйек)/-аек (айык)* формалары туры килүе дә күзәтелә. Мәсәлән, аларны М. Гафуриның татар халкын мәгърифәткә, фикри һәм әхлакый яктан алга өндәгән, көрәшкә чакырган һ.б. максатлардагы шигырь юлларында күрәбез:

*Кил, милләтем, һөнәр-гыйльмә* ***тырышаек****,*
*Бил баглап, мәйданә* ***чыгышаек****;*
*Җаһилият тәгассыбын артка ташлап,*
*Гыйлем-һөнәр, һәр фәнгә* ***чалышаек****.*

*Татарда «милләт, милләт!» диюче бар,*
*Вәләкин күбебездә юк икътидар.*
*Бака кебек коры телдән «бак-бак» итеп,*
*Хур* ***кыйлмаек*** *үзебезне, кыл, зинһар*!..

*Монда шигырь* ***язмаенча*** *булмый чыдап,*
*Ачылды язар өчен безләргә баб.*

Гомумән, *-ай/-әй, -аем/-әем* вариантларын кулланып сөйләү – Башкортстандагы татар теленең урта диалектка караган бөре, кормантау, тепекәй, турбаслы, учалы сөйләшләре, һәм, өлешчә, златоуст, минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы сөйләше вәкилләренә хас күренеш [Булатова, б. 141]. Әлеге форма татар әдәби телендә XIX гасыр ахырына кадәр кулланылган, башка татар халык сөйләшләрендә дә (касыйм, нократ, эчкен, оренбург татарлары сөйләшләрендә һәм Себер диалектларында) бар.

М. Гафури, Дәрдемәнд шигырьләрендә *исә* теркәгеченең кулланылышы иске татар язма әдәби телендәгечә: ул *-ды/-де* кушымчалы категорик үткән заман формасына ялгана, ә мәгънәсе буенча шарт фигыльгә туры килә, ягъни *-ды исә/-дисә* формасы белән дә белдерелә:

*Телләре* ***югалмадисә****, мәңге югалмас татар;*
*Милләт ашдыкча – ашар, милләт яшьдекчә – яшәр.*
(М. Гафури)

*Син нидер* ***иттең исә*** *атаң өчен, анаң өчен,*
*Син дә углыңнан алырсың аны, әлбәт, и углан.*
(Дәрдемәнд)

*Исә* теркәгеченең кулланылышындагы мондый үзенчәлекләр шулай ук Урал төбәге сөйләшләренә дә хас [Булатова, б. 146].

Мәгълүм булганча, диалекталь сүзләр әдәби телне баетуда саекмас чыганак булып хезмәт итәләр. Алар матур әдәбият әсәрләрендә теге яки бу геройның сөйләмен аерым бер төбәктә генә кулланылган сүзләр ярдәмендә баету, тәэсир көчен арттыру һ.б. өчен файдаланыла. Мәсәлән, М. Гафури әсәрләрендә очраган лексик-семантик диалектизмнардан *иртәдән соңга* / *иртәгә соңга* – әд. берсекөнгә; *тустак* – аш савыты, тәлинкә; *ялгаш* – бүрәнәдән чокып ясалган улак, тагарак; *пима* – киез итек; *нан* – икмәк; *һәргиз* – һәрвакыт; *алчак* – явыз, оятсыз; *ирештерү* – котырту, үртәү, үчекләү һ.б. аеруча игътибарга лаек. Әлеге лексик берәмлекләр Башкортстанда таралган күпчелек татар сөйләшләрендә һәм яләби әсәрләрдә актив кулланыла.

Башкортстан төбәгендә туып үскән шагыйрьләр һәм язучылар теленә *искәү* (әд. иснәү) фигылен

куллану хас: *Файда юк, искәсә дә, җаласа да* (М. Гафури).

Поэтик әсәрләрдә җирле сөйләм сүзләре яңгырашны, эмоциональлекне көчәйтү вазифасын да башкара. Мәсәлән, С. Рәхмәтулланың түбәндәге шигъри юлларында ***чәм*** сүзе ‘дәрт, теләк’ мәгънәсендә кулланыла:

*...Үзгәртүләр кирәк аңнарда!*
*Үзгәртергә – көрәшчеләр кирәк!*
*Җиңү **чәме** кирәк каннарда!*

Ә татар теленең урта диалектындагы богырыслан, минзәлә, стәрлетамак сөйләшләрендә *чәм* ‘гарьлек’ мәгънәсен бирә.

Шивә сүзләре телнең тарихи үсешен күзалларга да ярдәм итә. Чөнки җирле сөйләмдә әдәби телдә кулланылмаган, телнең аерым бер үсеш этабына гына хас булган сүз яки форма сакланып калырга мөмкин. Мәсәлән, Дәрдемәнд иҗатында халык теленнән алып кулланылган, бүгенге көндә диалектларда гына сакланып калган *ку* сүзе (‘ялангач’ дигән мәгънәдә) очрый:

*Сүнеп, вәйран булып мәгъмур*
*тиякләр*
*Җир астында төзелде **ку** сөякләр.*

*Ку, кыу* сүзе хәзерге вакытта себер диалектларында кулланыла: *кыу тал* – ялангач, яфрак ярмаган агач; *кыу өй* – ялгыз өй.

Билгеле булганча, әдәби текст телнең үз чаралары исәбенә баеый, сәнгатьчә яңгырашы ягыннан, башка стильләрдән аерылып тора. Анда төрле сөйләм үзенчәлекләре, образлы сурәтләү алымнары бергә кушыла һәм язучының үзенә генә хас стиль чаралары ачык чагыла.

Матур әдәбият стилендә бик үзенчәлекле телбизәкләрнең бер төркеме булып омонимнар санала. Бертөрле аваз составына ия булган төрле мәгънәле бу сүзләрне аваздашлар – «адаш»лар дип тә атарга мөмкин. Татар телендә аларны ясалышларына (төп һәм ясалма), лексик-семантик һәм грамматик мәгънәләренә (лексик, лексик-грамматик, грамматик һәм фразеологик омонимнар), әйтелеш һәм ясалыш үзенчәлекләренә (саф, омофоннар, омографлар, омоформалар) карап төркемлиләр. Г.Х. Әхәтов татар телендә омонимнарның өч тибын аерып күрсәтә: 1) ике төрле мәгънә белдерә торган сүзләр; 2) өч мәгънә белдерүче сүзләр; 3) өчтән артык мәгънә белдерүче сүзләр [Әхәтов, б. 43].

Омонимнарның стилистик вазифасы сөйләмнең яңгырашын күтәрүдә, аңа аерым бер аһәң бирүдә күренә. Төрле мәгънәдәге аваздаш сүзләр сөйләмнең эчтәлеген баета, укучы һәм тыңлаучының игътибарын үзенә җәлеп итә.

Теләсә нинди фонетик, грамматик шартларда аваз составы ягыннан да, тамыр хәлендә дә бер-берсенә охшаш булып кала торган, мәгънәләре ягыннан нык аерылган сүзләргә, ягъни саф лексик омонимнарга игътибар итик:

*Матурлыкта башка унбер айдан*
*Узып киткән нурлы ай бит ул,*
*Бөтен җанга тигез шатлык биргән*
***Май** бит...җанга якын **май** бит ул!*
(М. Гафури)

*Макталасың, тиргәләсең дә ул –*
*Дөнья булгач, төрле **чак** була.*
*Макталганда җанга рәхәт тә соң,*
*Тиргәлүе авыр **чак** кына.*
(Н. Нәҗми)

*Зилзиләләр артка чигә,*
*Юллар тар, текә* ***ярым****.*
*Атларымны тугармагыз,*
*Юлларда көтә* ***ярым****.*
(Д. Булгакова)

Язылышлары төрле, әмма әйтелешләре бертөрле булган сүзләр (омофоннар), гадәттә, уртак исемнәр белән ялгызлык исемнәр арасында туа:

*Исеме* ***Зифа*** *икән дә,*
*Буе да* ***зифа*** *икән.*
*Бер елмаеп караулары*
*Күңелгә шифа икән.*
(Н. Нәҗми)

*Аны* ***Газиз*** *үзеннән дә артык,*
*Үзеннән дә* ***газиз*** *күрә иде.*
(Ә. Атнабаев)

Шигырьләрдәге аерым сүзләр һәм сүзтезмәләрнең бер төрле яңгырау очраклары аеруча кызыклы. Мондый омофоннар да мәгънәләре һәм язылышлары белән генә аерылалар:

*«Иң оста чүлмәк ватучы»*
*Дип* ***аталган*** *Ибраһим.*
*Йөз чүлмәк ваткан өчен дә*
*Һай,* ***ат алган*** *Ибраһим.*
(Р. Миңнуллин)

*Безнең авыл юл* ***читендә***
*Җиде урман чигендә.*
*Туган җирләрендә яшәү*
*Рәхәт тә ул,* ***читен дә.***
(М. Нәзиров)

Бер үк төрле язылып та, басымнары аркасында төрлечәрәк әйтелә торган омоним сүзләр, ягъни омографлар да бар:

*Үзегезгә булсын* ***бүлмәге́з,***
*Юлларымны ләкин* ***бу́лмәгез.***
(Ә. Атнабаев)

Билгеле бер грамматик формада гына омоним булган сүзләр, ягъни омоформаларны лексик-грамматик омонимнар дип тә атыйлар. Аларга берничә мисал китерик:

1. Исем – исем:

*Сүндермәс өчен* ***утын,*** *өстә учакка* ***утын*** (Г. Ибраһимов).

*Сөю мәңге яшь ул:*
*Тал яңадан яшел,*
*Коя болыт* ***яшен,***
*Уйный күктә* ***яшен****...*
(М. Нәзиров)

2. Исем – хәзерге заман хикәя фигыль:

*Шундый дәһшәтле бер* ***кичә***
*Куркынычлы фаҗига баштан* ***кичә.***
(М.Гафури)

3. Исем – үткән заман хикәя фигыль:

*Анда кемдер учак* ***якты,***
*Монда тиклем төшә* ***якты.***
(Ә. Атнабаев)

4. Исем – киләчәк заман хикәя фигыль:

*Киләчәк тә безнең матур булыр:*
*Без төзербез сине,* ***Киләчәк!*** *–*
*Даһиларның хаталарын*
*Башта*
*Төзәтергә туры* ***киләчәк****.*
(С. Рәхмәтулла)

5. Исем – боерык фигыль:

*Зур болытлар күк йөзен каплап килә тау-тау булып,*
*Җимерелеп үскән игеннәргә карап, зур* ***яу*** *булып.*
*«****Яу****!» – дигән чакта яварсыз, гөрләтеп һәм шаулатып,*
*«Яума!» – дип әйткәч тә туктарсыз, калырсыз шаккатып.*
(М. Гафури)

Күргәнебезчә, омонимнарның һәр төре – сүз сәнгате өчен зур табыш. Алар сөйләмнең яңгырашын һәм аһәңен көчәйтүдә,

аңа стилистик-эмоциональ төсмерләр бирүдә зур урын тоталар. Эчтәлек белән бәйле рәвештә бер-берсенә аваздаш сүзләр каламбурларга якын торалар, сүз уйнату чарасын үтиләр, көтелмәгән һәм үткен рифма булып яңгырыйлар.

Сөйләмдә каламбурлар күпмәгънәле (полисемик) сүзләр, лексик-семантик һәм лексик-грамматик омонимнар белән төзелә ала.

*Әллә чын, әллә могҗиза –*
*Чымырдады* ***кинәт тән:***
*Елмаеп җибәрде Туфан*
*Көтмәгәндә* ***кинәттән.***
(Р. Миңнуллин)

*Булачак монда көрәш тә,*
*Булачак – җыр,* ***уен да****.*
*Шул бәхетсез бала турысында*
*Ниләр булмагандыр* ***уенда****.*
(М. Гафури)

С. Рәхмәтулла да аларны бик оста куллана:

*Урамнарга сөт исләре тула.*
*Урамнарга керә* ***көтүләр****.*
*Авылларда һаман борынгыча*
*Көтү көтеп дөнья* ***көтүләр.***

*Арбалар килә кызып –*
*Тузаннар кала* ***тузып****;*
*Җәйләр дә китә узып,*
*Арбалар бетә* ***тузып.***

Каламбурларда рифмадаш сүзләрнең төзелеше төрлечә була. Авазларның охшашлыгы нигезендә бер сүзгә ике сүз рифмалашу очраклары да күзәтелә:

*Өйрәтелгән маэмай кебек, әнә,*
*Туп берсүзсез тыңлый,* ***буйсына.***
*Ә сылуның матурлыкка гына*
*Яратылган бугай* ***буй-сыны.***
(Р. Миңнуллин)

*Үз чорымның давыллары аша*
*Үз юлымнан китеп* ***баруым****.*
*Үз күңелемнән чыккан*
*Үз җырымны*
*Үз халкыма илтү –* ***бар уем.***
(С. Рәхмәтулла)

Сүз уйнатулар теге яисә бу персонажны, күренешне сәнгатьчә югарылыкка күтәрергә ярдәм итәләр, шулай ук геройның рухи халәтен, аның эчке кичерешләрен ачып бирүнең бер чарасы булып торалар:

*Карагыз – Туфан Йолдызы*
*Чыкты икән* ***кай турга?!***
*Бөтенләйгә китте Туфан*
*Бөтенләйгә* ***кайтырга!***
(Р. Миңнуллин)

Илдар Юзеевта, градация рәвешендә килгән шигырь юллары каламбур белән тәгалләнеп, ике алым бер-берсе белән тыгыз кушылып китә:

*Ни ясар тимерче:*
*Атларга тышаумы,*
*Азатлык сөюче*
*Муенына кыршаумы?*
*Нәниләр сөенеп*
*Атыныр таганмы,*
*Сабанмы, кылычмы?*
*Кылычтан сабанмы?*
*Шатлыкмы, хәсрәтме?..*
*Таңнарга* ***ала чык.***
*Борчылып, сискәнеп*
*Көтә җыр –* ***алачык.***

Каламбурлар бигрәк тә көлкеле шигырьләрдә еш кулланыла. Шагыйрьләр аваздаш сүзләрне янәшә кулланып, аларны комик образ ясау, кызыклы юмористик хәлләрне күрсәтү өчен дә оста файдаланалар:

*Урланып беткәч тә әле*
*Җиз комган һәм* ***табалар,***
*Авыр хәлдән чыгу юлын*
*Егетләр тиз* ***табалар.***

Проза һәм драма әсәрләрендә дә охшаш яңгырашлы сүзләр, поэзиядәге шикелле үк, күбрәк очракта көлкеле сурәт тасвир итә. Сүзнең омонимик парын янәшә кулланып образ ясау, аеруча, балалар турында һәм балалар өчен язылган әдәбиятта үзенчәлекле төс ала. Мәсәлән:

*– **Атың** ничек?*

*– Мин үзем **ат**, абый. **Тай**дан да шәп чабам, «**тай**ганда»* (Ә. Атнабаев).

Драма әсәрләрендә омонимик сүзләрне кулланып сурәт ясау, шулай ук жанр үзенчәлегенә бәйле булып кала. Беренчедән, алар поэзиядәге шикелле комик образ барлыкка китерәләр, икенчедән, прозадагы шикелле персонажларны сыйфатлау чарасы булып та торалар:

*Фәзретдин: Мин хәзер чыгып китәм,бер генә **минутка** кердем.*

*Галиулла (Зәбирәгә): **Утка** кердем, диме?*

*Зәбирә: Бер генә минутка кердем, ди* (Ә. Атнабаев).

Әсәрләрдә омонимнарга берникадәр якын торган һәм сурәтләү чарасы буларак кулланылган паронимнарны да күпләп очратырга мөмкин. Тел гыйлеменнән билгеле булганча, паронимнар – тамыр һәм нигез морфемаларның этимологик уртаклыкка ия булган охшаш яңгыраштагы, әмма мәгънә төсмере белән сизелерлек аерылган сүзләр. Әдипләр паронимнарны төрле максатлардан чыгып файдаланалар: эчке һәм тышкы рифма кору, сүз уйнату, сүзләрне парлаштырып бирү, яңа гыйбарәләр ясау, юмор-сатира һ.б. хәлләрне сурәтләү өчен. Мисаллары аеруча Р. Миңнуллин шигырьләрендә еш очрый:

*Бер-беребезгә без кирәкбез,*
*Ходай, безне **аерма!***
*Әнкәемнең канатларын*
*Берүк кенә **каерма.***
*Безнең хисебез*
*Нурга **коенган** –*
*Безнең йөрәкләр*
*Нурдан **коелган**.*

Шагыйрьләр тамырдаш булмаган, очраклы рәвештә генә охшаш яңгырашлы сүзләрне, ягъни парономасларны да киң кулланалар:

*Яна, яна*
*Җанда яра.*
*Яра – **яна,***
*Яра – **яңа...***
(Р. Миңнуллин)

*Син кайгырма – без карт түгел,*
*Без нәкъ үз **яшебездә**.*
Төрле чак була торгандыр –
Әй кызык ***яшибез*** дә!
(С. Рәхмәтулла)

*Япа-ялгыз ятам. Ак кәгазьдә –*
*Тик яртылаш язган **шигырем.***
*Ә яп-якты бүлмәм язылачак*
*Шигырьләрем белән **шыгрым**!*
(Р. Миңнуллин)

Әлбәттә, гомумтел кануннарына туры килә торган аваздашлык Башкортстан язучылары иҗатына гына хас күренеш түгел. Шулай да, алда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, Башкортстан татар язучыларының иҗат хәзинәсе аларның төрле стилистик чараларны, телбизәкләрне оста файдалана белүе белән дә бәйләнгән. Әдәби әсәрләрдә туган телебезне баета торган сүз уйнатулар, каламбурларны

оста файдалану һәрвакытта диярлек көтелмәгәнлек эффектын барлыкка китерә, текстны эстетик һәм экспрессив-эмоциональ яктан баету мөмкинлеге бирә. Язучыларның үз туган төбәгендәге сөйләү телен яхшы белүе, диалекталь лексиканы әсәрләрендә уңышлы кулланулары исә иҗат җимешләренә кабатланмас үзенчәлекле төсмерләр һәм аһәңнәр өсти.

**Әдәбият**


*Атнабаев Ә.* Пьесалар. Уфа: БКН, 1978. 496 б.

*Атнабаев Ә.* Җиз кыңгырау моңнары. Шигырьләр, поэмалар. Уфа: Китап, 1998. 320 б.

*Әхәтов Г.Х.* Хәзерге татар теленең лексикологиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 130 б.

*Булгакова Д.* Шигырьләр, җырлар. Уфа: Китап, 1998. 128 б.

*Булатова М.Р.* Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана»: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2012. 262 с.

*Гафури М.* Әсәрләр: Дүрт томда. Казан: Татар. кит. нәшр.,, 1980. I т. 535 б.; 1980. II т. 598 б.; 1983. III т. 390 б.; 1981. IV т. 496 б.

*Дәрдемәнд.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 126 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр. Сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. II т. 479 б.

*Миңнуллин Р.* Талбишек. Шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 478 б.

*Нәҗми Н.* Милли җаным: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар, шигырьләр, поэма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 520 б.

*Нәзиров М.* Еллар кары. Шигырьләр һәм җырлар. Уфа: Китап, 2002. 320 б.

*Рәхмәтулла С.* Сулар үргә акса да. Шигырьләр, поэмалар, эпиграммалар. Уфа: Башк. кит. нәшр., 2001. 240 б.

*Юзеев И.* Мәхәббәт китабы. Шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 352 б.



***Булатова Миңнира Рәхим кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***А.И. Мансуров***

# Р. ГАТАШНЫҢ «ИРЛӘР БУЛЫЙК» ШИГЫРЕНӘ САЛЫНГАН ФӘЛСӘФИ ФИКЕР

В статье рассматривается творчество представителя татарской литературы 1960-х годов Радиф Гаташа, в частности стихотворение «Ирләр булыйк». Устанавливаются особенности стихотворной формы верлибра, анализируется отражение в произведении процесса становления настоящего мужчины. Раскрывается кораническая трактовка образа мужчины в стихотворении «Ирләр булыйк».

**Ключевые слова:** символический идеал, верлибр, образ, мужчина, мужество, философская лирика, публицистическая поэзия.

XX гасырның 60 нчы елларында илебездә барган демократик, сәяси һәм сәнгати үзгәрешләр нигезендә татар җәмгыятендә әдәбиятның роле югары күтәрелә. Бу чорда мәгълүматны тиз һәм төгәл җиткерә торган жанрларга ихтыяҗ туа. Шуның нигезендә, журналистиканың төрле жанрлары активлыгы көчәю белән беррәттән, фәлсәфи лириканың һәм публицистик поэзиянең дә үсеше күзәтелә. Р. Фәйзуллин (1943), Р. Гаташ (1941), Р. Харис (1941), Г. Рәхим (1941), Р. Мингалим (1938) һ.б. шагыйрьләр яңа образлар системасы, поэтик методлар, шигырь формалары куллана башлый. Әлеге вакытның традицияләре хәзерге татар әдәбияты үсешенә зур йогынты ясый.

Шул сәбәпле без дә, узган гасырның 60–80 нче елларында эшчәнлеген башлап, үзенең поэтик үзенчәлекләре белән бик күпләрнең игътибарын җәлеп иткән, татар әдәбиятының күренекле вәкиле Р. Гаташ иҗатына күзәтү ясауны максат итеп куйдык. Безнеңчә, бүгенге көндә аның шигъриятен системалы рәвештә өйрәнгән галимнәр, иҗатын төрле яктан чагылдырган хезмәтләр җитәрлек түгел. Шагыйрь иҗатын тикшергән Ә. Вәлиулла [1, 2], Р. Ганиева [3, 5], Т. Галиуллин [3, 192], Й. Нигъмәтуллина [4, 5], Ф. Хәсәнова [6, 7] үз хезмәтләрендә шагыйрь иҗатының аерым аспектларын гына өйрәнә.

Билгеле булганча, шагыйрь иҗатында көнчыгыш поэзиясе шигырь үрнәкләре дә, көнбатышыныкы да тигез дәрәҗәдә диярлек очрый. Ләкин без аның укучыда каршылыклы хисләр уяткан, битараф калдырмаган «Ирләр булыйк» шигыренә тукталырга булдык.

Р. Гаташның «Ирләр булыйк» шигырен дөньяны яхшы якка үзгәртә ала торган, башкалар өчен үрнәк булырдай идеаль ир-ат образын тудыруга бер омтылыш итеп кабул итәбез. Мондый «ир-ат»ның формалашуы – катлаулы процесс. Шуңа күрә дә, шигырьдәге тирән фәлсәфәне тиз генә аңлап та булмый. Ә бу фәлсәфәне укучыга җиткерү тагын да катлаулырак һәм автордан ае-

руча зур осталык сорый. «Ир-ат» образы, батырлыкка омтылыш күп кенә татар шагыйрьләренең иҗатында чагылыш ала. Әлеге тема Марсель Галиев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Һади Такташ, Хәсән Туфан һ.б.лар иҗатларында төрле яклап яктыртыла.

«Ирләр булыйк» шигыренең лирик герое үзенчәлекле карашка һәм характерга ия шәхес. Нәкъ менә аның фикерләре шигырьнең нигезен тәшкил итә дә инде. Гаташ герое чынбарлыкны үзенең хыял дөньясына каршы куя. Шулай итеп, лирик герой әйләнә-тирә белән конфликтка керә. «Ир-ат» булу идеалы аның көнелендә яши һәм җәмгыятьтәге үзгәрешләр белән килешергә ирек бирми. Шуңа бәйле рәвештә, шагыйрь лирик геройдан андый ир-атның формалашуы гомер буена бара торган, аерым бер гамәлләр нигезендә туып, озын, катлаулы процесс икәнен күрсәттерә.

Автор фикерләр, хисләр җыелмасын укучыга аңлаешлы һәм тиешле дәрәҗәдә җиткерү ихтыяҗын да оста хәл итә. Р. Гаташ, гадәти шигырь калыбыннан тайпылып, «Ирләр булыйк» шигырен верлибр формасына сала. Ирекле шигырь үзенең мәгънәви тирәнлеге, җыйнак калыбы, традицион булмаган ритм, рифмасы, эпоска охшаш булуы белән авторга поэтик максатларына төгәл ирешергә ярдәм итә.

Шигырь ир-ат тормышының төрле чорына багышланган биш өлештән тора. Төгәлрәк әйткәндә, автор ир-атның, малай вакытыннан алып, картайганчы узган тормыш юлын тасвирлый. Биредә без бик кызыклы бер үзенчәлеккә тап булабыз. Ир-ат булуга ирешү юлларын лирик герой бары тик бер генә хис – мәхәббәт белән генә бәйләп карый. Әле мәхәббәтнең дә гадие генә түгел – олысы – туганнарга, сөйгән ярга мәхәббәт, Туган якка, Туган йортка булган мәхәббәт.

Шигырьне ритмик буыннарга таркатып, ритмик системаны күзәтәбез. Бу күренеш шигырьнең интонациясенә йогынты ясый һәм кабатланып килә торган интонация верлибрның ритмын көйли. Ләкин беренче һәм икенче строфаны чагыштырып караганда төгәлсезлеккә дә очрыйбыз.

Ирләр булыйк / һәрвакыт һәм / һәр
адымда, /
малай чакта – /
уйнаганда, /
күккә карап / төрле уйлар / уйлаганда.
Кыйналганда./
(«Ирләр булыйк»)

Димәк, беренче строфа дүрт иҗекле кабатланып килә торган ритмик буыннардан гыйбарәт. Икенче строфада исә, шигырьнең ритмикасын үзгәрткән биш иҗекле ритмик буыннар килә. Шуңа күрә дә укучы, әлеге верлибрны укыганда, ритмны саклар өчен, артык иҗекләрне әйтмичә (кызыңа – кыз(ы)ңа, оял(ы)п), кыскартып китәргә мәҗбүр була:

...Ирләр булыйк /– үсмер чакта, /
беренче кат / яратканда: /
яшьтәш кызыңа, / оялып, бер көн /
аңлатканда.
Үпкәләшеп / йөрешкәндә. /
Килешкәндә. /
(«Ирләр булыйк»)

Фәндә бу күренешне редукция термины белән атыйлар. Редукция – озынлыгы кыскаруы

нәтиҗәсендә авазның артикуляцион һәм акустик характеристикалары үзгәрүе ул [8, 232].

Р. Гаташның «Ирләр булыйк» шигыренең тагын бер үзенчәлеге – бик күп сандагы төгәл рифмалар. Рифмалар ачык. Строфалар буенча анализ ясасак, түбәндәге күренешкә тап булабыз. Беренче строфада өч рифма (уйнаганда уйлаганда, кыйналганда), икенчесендә – дүртәү (яратканда, аңлатканда, йөрешкәндә, килешкәндә), өченчесендә – бишәү (аерылганда, сагынганда, арган чакта, калган чакта, барган чакта), дүртенчесендә – алтау (җиңелгәндә, чигенгәндә, килгәндә, көрәшкәндә, бәхәсләрдә, вәгъдәләрдә), бишенчесендә – дүртәү (булгач та, картайгач та, ирләр булыйк, тотып торыйк). Рифмаларның шулай күп санда булуы, шигырьнең ритмын бай һәм матур итә. Тик, күргәнебезчә, алар нигездә фигыль рифмалар, ә тоташ килгән фигыль рифмалар әдәби тәнкыйтьтә гел уңай бәяләнми. Шуңа күрә дә, Р. Гаташның «Ирләр булыйк» шигырендә рифманың фигыльләргә генә корылуы тулысынча уңай күренеш түгел.

Игътибарыбызны шигырьдәге ир-атларга хас булмаган «кыйналу», «оялу», «үпкәләү», «чигенү» кебек төшенчәләр җәлеп итте. Алар бик үк урынлы кулланылмаган кебек. Ир-ат бер вакытта да кыйналмый, ә үзен һәм якыннарын яклап сугыша. Ә эшеңне ярты юлда калдырып чигенү – бөтенләй матур күренеш түгел. Ә беренче тапкыр гашыйк булган егет? Тәҗрибәсе булмаган килеш үзен чын ир-атларча тота аламы? Димәк, малай чакта да, егет чакта да «ир-ат» булып булмый әле.

Автор «булыйк» сүзен бик еш куллана. Ул үзе ирләр булырга чакыра, ә үзе нәрсә эшләргә кирәк икәнен төгәл күрсәтми. Бары тик логик фикерләү нигезендә генә нинди гамәлләр кылырга икәнен фаразлап була. Асылда, җәмгыятьтә барган әхлакый, мәдәни, сәяси үзгәрешләр, техник алгарыш «ир-ат» булганнарга да таләпләрне үзгәртергә мөмкин. Бу яктан караганда, автор позициясен аңлап та була. Шуны истә тотып, Р. Гаташ «ир-ат»ларның төгәл сыйфатларын күрсәтүне максат итеп куймый да кебек. Ләкин, икенче яктан караганда, теләсә кайсы ир-ат, әлеге шигырьне укып, үзенең әдәп-әхлак нормаларына туры килми торган сыйфатларын да аклый, уңайлар рәтенә кертә ала. Бу аңа үзен «ир-ат» дип атарга мөмкинлек тудыра.

Шигырьдә еш очрый торган «ир» сүзенең мәгънәсенә дә игътибар итмичә булмый. Малайлык, егетлек чорын үткән, олыгайган кешегә *ир-ат* диләр. Ә *ир булу* – өйләнү, никахка керү дигән сүз. Р. Гаташ үзенең шигырендә моны исәпкә алып тормый. Бәлки, авторга физик үсеш-үзгәреш мөһим дә түгелдер. Ул басымны күбрәк әдәп-әхлакка, рухи үсешкә, тормыш тәҗрибәсе, акыл туплауга ясаган. Аның «ир» сүзен куллануын да шуның белән аклап була.

Бер карасаң, бар да гади кебек. Ләкин бу әле шигырьнең күзгә ташланып торган, беренчел мәгънәсе генә. «Ирләр булыйк» шигыре Совет чорында, дин кысрыкланган вакытта язылса да,

Коръән ярдәмендә аңлатып карауны кирәк таптык. Күп кенә сүрәләрнең аятьләрендә «ир-ат нинди булырга тиеш?» дигән сорауга җавап бар.

Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Кешеләр дөяләр кебек: йөзе арасыннан авырлык белән генә йөрергә яраклы берне табарсың», – диелә. Әлеге гадәти булмаган чагыштыру безгә аналогия үткәрергә ярдәм итә. Тормышта да (хәдистәге сүзләр белән әйткәндә «йөрер» өчен) кешеләрдә тиешле сыйфатлар, омтылышлар, бурычлар, максатлар булырга тиеш.

Ислам динендә ир-атның да, хатын-кызның да үз бурычлары һәм хокуклары бар. Элекке заманнардан ук, ислам хатын-кызның иреген чикли дигән ялгыш фикер яшәп килә. Дин буенча, ирләр дә, хатыннар да тигез, алар үз гамәлләре өчен җаваплы, шул ук вакытта һәрберсенең үз хокуклары да бар. Ә иң мөһим хокук – ир-атта. Ул гаилә башлыгы булырга тиеш.

Ә хатын-кыз – беренче чиратта, гаилә җылысын саклаучы. Ул үзенең ирен хөрмәт итәргә, аның малы белән идарә итәргә, балалар тәрбияләргә, ирен башка ир-атлар белән чагыштырмаска, аның өчен һәрвакыт матур булырга, иренең әти-әнисен хөрмәт итәргә тиеш.

Димәк, Коръәндә чагылган төп фикер түбәндәгедән гыйбарәт: сакал-мыек йөрткән һәр кешене чын ир-ат дип атап булмый эле. Ир-ат булыр өчен, югары әхлак, акыл, рухи көч таләп ителә. Моннан чыгып, Р. Гаташның шигырендәге «ир» төшенчәсенең кешенең яше белән генә билгеләнмәвен өстәп куйыйк. Мисал өчен, 60 яшьлек бабай да, үзенең яшенә хас акылга ия булмыйча, ахмак гамәлләр кылырга мөмкин. Ә 20 яшьлек егет, киресенчә, төпле фикер йөртеп, файдалы эшләр эшли ала.

«Ирләр булыйк» шигыренең соңгы строфасы аеруча кызыклы. Без монда лирик геройның каршылыклы хисләре белән очрашабыз, аның буталып беткәнен аңлый башлыйбыз. Верлибрның башыннан ахырына кадәр диярлек, романтик герой үзенең «ир-ат» булу турындагы идеаль күзаллавын җиткерә дә, ахырда ачы чынбарлык белән очраша. Нәтиҗәдә, ул үзе дә һәрвакыт ирләрчә төпле гамәлләр генә кылып яшәп булмый икәнлеген аңлый һәм бу проблемадан чыгу юлын күрсәтә:

...Һич югында
күк гөмбәзен иңебездә
бары бер көн тотып торыйк.
Ирләр булыйк!

Баксаң, һәрвакыт батырлыклар кылып йөри алмасак та, безгә Р. Гаташ шигырендә күрсәткән идеалга омтылырга, бары бер көн генә булса да «ирләр» булырга мөмкинлек бар икән.

Шулай итеп, бу хезмәттә Р. Гаташның «Ирләр булыйк» шигыренең эчтәлеге һәм формасы бер-берсенә тыгыз бәйләнештә икәнен күрә алдык. Мондый гармония шигырьнең эчке фәлсәфәсен, яшерен мәгънәсен аңларга ярдәм итә. Ә «ир булу» – физик халәткә бөтенләй бәйле түгел икән. Ул – акыл, тырышлык, намус, камиллеккә омтылу күрсәткече.

**Әдәбият**

*Вәлиулла И.* Һәр шагыйрь – бер дәрья...: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 208 б.

*Вәлиулла И.* Мәңгелек Бәхет эзләреннән...: эсселар, әдәби тәнкыйть мәкаләләре / кереш сүз авт. Р. Ганиева. Казан: Школа, 2004. 128 б.

*Гаташ Р.К.* Сайланма әсәрләр: 3 томда / Рәдиф Гаташ; кереш сүз авт. Р. Ганиева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. / 3 т.: Хиссият аятьләре: шигырьләр. 2009. 351 б.

*Нигматуллина Ю.* Методология комплексного изучения художественного творчества. Казань: КГУ, 1983. 102 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 176 с.

*Хәсәнова Ф.Ф.* Мәхәббәт шагыйрен таный белегез! // Казан утлары, 2011. № 3. Б. 143–149.

*Хасанова Ф.Ф.* Основные мотивы в поэзии Р. Гаташа // Проблемы филологии народов Поволжья. Материалы Всероссийской научно-практической конференции (7-9 апреля 2011 г.) Выпуск 5 (Отв. ред. А.Т.Сибгатуллина). М. – Ярославль: Ремдер, 2011. С. 340–348.

*Реформатский А.А., Зиндер Л. Р.* Общая фонетика: Учеб. пособие. 2-е изд., перераб. и доп. М.: Высш. школа, 1979. 312 с.

Коръән / китапны бастыру өчен җаваплы Вәлиулла хәзрәт Ягъкуб. Казан: Иман, 2009.

***Мансуров Алмаз Илдар улы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге аспиранты,*
*Казан шәһәре Яңа Савин районы «7 нче интернат лицей»ның татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*e-mail: almaz.mansurov.91@gmail.com*

УДК 398.2=512.145

*И.И. Ямалтдинов*

## ТУКАЙ ТУРЫНДА БӘЕТЛӘР

В статье рассмотрены два варианта баита, посвященного смерти поэта Г. Тукая. Баит – произведение лиро-эпического жанра татарского народного творчества – является своеобразным способом реакции на то или иное общественно значимое событие, чаще – переживанием горя. В этом отношении баиты Тукая свидетельствуют не только о широком признании творчества поэта, но отражают всенародную любовь к нему.

**Ключевые слова:** баит, Габдулла Тукай, варианты баита, композиция.

Тукай бәетләренең «Шагыйрь Тукай бәете», «Тукай бәете» исемнәре белән басылып чыккан ике варианты бар. Төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребездән язып алынган әлеге бәетләр Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең фольклор фондында саклана. Беренчесе халкыбызның бөек шагыйре Тукай үлеменә багышлап, «Тукай үлү мөнәсәбәт илә. Илаһи бәет» исеме белән тәүге тапкыр «Кояш» газетасында «Г» имзасы белән басыла [Кояш, 1913, № 93, 11 (24) апрель]. Бәетнең кайда язып алынуы һәм язып алучының фамилиясе газетада күрсәтелмәгән. Соңрак әлеге вариант, тулысынча яисә кыскартылып, «Татар халык иҗаты» һәм «Бәетләр» җыентыкларында (1951, 1954, 1960, 1983) урын ала. Бәетне матбугатка тәкъдим итүче кеше кайсыдыр бер авыл яшьләренең яраткан шагыйрьләре үлүен ишеткәч үк бәет чыгаруын хәбәр иткән, аның аңлатмасында мондый юллар бар: «Безнең авылга мөхтәрәм шагыйремез Габдулла Тукаев җәнапларының вафат хәбәре шимбә көн сәгать 10 да килеп җитте. Килү белән хәбәр бөтен авылга таралып та өлгергән. Шул көнне килгән ике нөсхә «Кояш», өч нөсхә «Йолдыз» йорттан йортка йөртелеп укылган. Яшьләр, картлар, карчыклар – авыл халкы аның яшьли заигъ булуына чын күңелдән кайгырганнар. Кич, ясигъдан соң, күл буена төшеп утырдым. Миннән ерак та түгел, бер мунча янында, авыл яшьләре җыелып, касдан моң гына, зәгыйфь кенә чыгарылган гармонь тавышына бер-икесе авылда гына була торган саф тавыш белән җырлыйлар, башкалары тыңлыйлар иде. Җырлары ачык ишетелмәсә дә, арада «шагыйрь Тукай» дигән сүзләр ишетелә иде. Мин: «Бу ни! Болар ни җырлыйлар? дип чынлап тыңлап карасам, үзләренең шагыйрьләре хакында бер бәет тәртип кылып, шуны көйләп утырганлыкларын сиздем. Иртәгесен бәетләрен табып алдым» [Кояш, 1913, № 93, 11 (24) апрель ].

Икенчесе турында «Тукай Башкортстанда» (1966) китабының аңлатмалар өлешендә 1948 елда Башкортстанның Чакмагыш

районы «Йөрәктау» колхозчысы Шаһибәк Биктимеров кулъязмаларыннан күчереп алынганлыгы, башлап «Башкорт халык иҗаты» җыентыгының I томында (1954) басылганлыгы әйтелә, ләкин «Татар халык иҗаты. Бәетләр»-нең (1983) искәрмә һәм чыганаклар өлешендә Тукай бәете алда аталган «Башкорт халык иҗаты» җыентыгыннан алынганлыгы күрсәтелсә дә, «кемнән язылганы күрсәтелмәгән» дигән хәбәр бар [Татар халык иҗаты. Бәетләр, 1983, б. 296].

Халыкның Тукайга кайнар мәхәббәтен чагылдырган бу бәетләрнең башлам өлешендә, XIX йөзнең урталарыннан алып революциягә кадәр чыгарылган бәетләргә хас булганча, «бисмиллаһи вә биллаһи» белән башланып, традицион рәвештә вакыйганың елы, ае, көне күрсәтелә һәм сүзнең кем турында баруы белдерелә. Бу традиция, нигездә, безнең тарихи бәетләребез өчен хас күренеш. XVI йөзләрдә язылган бәетләрдә үк кереп киткән бу традиция соңгы чорларда да дәвам иткән.

Бисмиллаһи вә биллаһи, укыдык
корбан гаетен,
Без әйтәбез, сез тыңлагыз Тукай
шагыйрь бәетен.

Тукыз йөздә унөч елда, апрель
икесендә,
Тукай мескен вафат булган Клячкин
больницасында.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 37].

Бисмиллаһи вә биллаһи, җитте
корбан гаете,
Без әйтәек, сез тыңлагыз мәрхүм
Тукай бәетен.

Тарих мең дә тугыз йөздә унөч елы
бу вакыт,
Апрельнең икесендә җырчыбыз
Тукай вафат.
[Тукай Башкортостанда, 1966].

яисә икенче вариантта:

Бисмиллаһи вә биллаһи, җитте
корбан гаете,
Без әйтәек, сез тыңлагыз мәрхүм
Тукай бәетен.

Тарих мең дә тугыз йөздә унөч елы
бу вакыт,
Унбишенче апрелендә җырчыбыз
Тукай вафат.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 38].

Әлеге юллардан күренгәнчә, шагыйрьнең вафат булган көне беренче вариантта икенче апрель дип юлиан, ә икенче вариантта унбишенче апрель дип григориан календаре – яңа стиль буенча күрсәтелгән.

Тукай бәетләре фаҗигале. Алардагы фаҗига аерым шәхес фаҗигасе генә түгел, ә вакытсыз үлем нәтиҗәсендә барлыкка килгән халык фаҗигасе буларак яңгыраш ала. Халык үзенең яраткан бөек шагыйрен бик яшьли, бик иртә югалта, бәетләрдә дә шуңа басым ясый, ә беренче вариантта, килешмәскә тырышып, Әҗәлгә дәгъва да белдереп ала:

Ак келәтнең келәсен элә белми
эләсең,
«Әҗәл» агай, син нишлисең, килә
белми киләсең.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 37].

Яшьли китте шагыйрь Тукай,
чәчә-чәчә нурларын,
Аллы-гөлле күп чәчәкләр куйды
халык каберенә.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 38].

Беренче вариантта халык үзенең сөекле шагыйрен бик иртә югалтуын, аның яшен күрсәтеп, аерым юллар аша да бирергә тырыша:

Ак келәтнең алдында калды бәнем
җиләнем,
Егерме алтыда үлеп китте Тукай
шагыйрь, сөйгәнем.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 37].

Институт архивында сакланган кульъязма битләрдәге юлларда Тукайга үпкә белдерү дә сизелә:

Ташладың син безне,Тукай,
мәңгелеккә ташладың,
Инде дөньяда түгел син, үзгә хәят
башладың.
[Язма һәм музыкаль мирас үзәге,
колл. 39, тасв. 1, сак.бер. 286, Б. 5–6].

Авыл яшьләре дә, картлар да Тукай үлеме турындагы хәбәрне ишетү белән тирән кайгыга чумалар:

Ызба артында алмагач, кисеп җиргә
салмагач,
Җырла, моңай, саргай, үл, матур
Тукай калмагач.

Тауга менсәм – тау биек, түбән
төшсәм – тамырлык,
Тукаен җуйган яшьләргә ходай
бирсен сабырлык.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 37]

Алар турыдан-туры Тукайга эндәшү аша мәңге истә тотачаклары турында вәгъдә һәм шул ук вакытта, яраткан шагыйрьләренең әйләнеп кайтмый торган бакый дөньяда булуына ышанмыйчарак, үгетләү катыш сорау да бирәләр:

Тукай абзый, яшь чагыңнан белә
идек без сине,
Онытырлар дип уйлама, онытмабыз
без сине.
Алма бирдем – алмадың, тәңкә
бирдем – сайладың,
Безнең матур дөньябызда ник
ике-өч ел калмадың?
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 37]

Тукайның 26 яшендә үк вафаты – көтелмәгәндә чыккан бәхетсез хәлләр нәтиҗәсендә килеп туган драматик фаҗига – трагизм категориясе белән якын гына тормыйча бер-берсенә күчә – тиңдәшсез зур югалту булып аңлашыла. Бу – фаҗиганең аянычлы нәтиҗәсе, аның кайтара алмаслык олуг югалту кичерүе.

Шагыйрьләргә шагыйрь иде ул
Тукай заманында,
Куркып тормыйча әйтер иде
яхшысын, яманын да.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 38]

яисә архивтагы кульъязма битләрендәге юллар:

Син идең бит һәммәбезнең моңлы
җанлы шагыйре,
Син идең бит халкыбызның солтаны
һәм шаһ ире,

Син идең бит барча акын, бар
шагыйрьнең акыны,
Бар кешенең, бар халыкның
җан-күңелдән якыны.

Ни дигән сүз: милли шагыйрь
Габдулла Тукай вафат?
Бумы? Бу бер якты йолдыз яки
нурлы ай вафат.
[Язма һәм музыкаль мирас үзәге,
колл. 39, тасв. 1, сак. бер. 286, Б. 5–6]

Мәсҗет башы манир-манир, манир
саен бер талир,
Безне ятим калдырып, китте безнең
шәп шагыйрь.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 37] һ.б.

Әлеге юллардан күренгәнчә, фаҗигале хәл тудырган югалту, халык чыгарган нәтиҗә буларак, түбәндәгечә гәүдәләнә: матурлык юкка чыккан, яшь гомер харап булган һәм иң мөһиме – халык ятим калган.

«Тукай бәете» әсәрендә башка вариантлар белән чагыштырганда, фаҗига тудыручылар, турыдан туры булмаса да, гаепләнә:

Мохтаҗлыкта яшәде ул, байга
бурычка батып,
Сәүдәгәрләр баедылар аның
китабын сатып.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 38]

Әлеге юллардан аңлашылганча, җәмгыятьнең төзелеше, аның башында торучы түрәләр халкыбызның сөекле улын шундый көнгә китереп җиткерә.

Тукай бәетләренең бетем өлеше дә бар. Беренче вариантта ул мәңгелеккә саубуллашу буларак яңгырый:

Актыр җиләнем минем, күктер
җиләнем минем,
Кабереңдә тыныч йокла, җаным,
шагыйрем минем.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 37].

«Җырлый-җырлый үләрмен мин, –
диде Тукай, – үлгәндә дә».
Тере калды җыры белән, җисемен
җиргә күмгәндә дә.
[Татар халык иҗаты.
Бәетләр, 1983, 38].

Икенче вариантның бетем өлешеннән күренгәнчә, Тукайның үз сүзләре китерелеп, шагыйрьнең үлемсезлеге «яшәү һәм үлем фәлсәфәсе» аша аңлашыла.

**Әдәбият**

*Бакиров М.Х.* Татар фольклоры. Казан, 2008. – 359 б.

Бәетләр / Төз., кереш мәкалә һәм аңлатмалар язучы Х. Ярми. Казан, 1960. 388 б.

Татар халык иҗаты. Бәетләр / төз. Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова; кереш мәкалә авт. Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, Р.Ф. Ягъфәров. Казан, 1983. 352 б.

Татар халык иҗаты / төз.: Г. Бәширов, А. Шамов, Х. Ярми, Х. Усманов; ред. Х. Ярми; СССР ФА. КФ. ТӘТИ. Казан: Татгосиздат, 1951. 524 б.

Татар халык иҗаты / төз. Г. Бәширов, А. Шамов, Х. Ярми, Х. Госман; СССР ФА КФ ТӘТИ. 2 басма. Казан: Татгосиздат, 1954. 604 б.

Тукай Башкортостанда: Истәлекләр, шигырьләр, хикәяләр һәм мәкаләләр / төз., сүз башы һәм аңлатмалар авт. С. Сафуанов. Уфа, 1966. 208 б. (башкорт телендә).

*Урманчеев Ф.И.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2002. 335 б.

*Урманчеев Ф.И.* Халык авазы. Казан, 1974. 178 б.

Язма һәм музыкаль мирас үзәге, колл. 39, тасв. 1, сак.бер. 286, б. 5–6.

*Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. Казан, 1967. 307 б.

***Ямалтдинов Илмир Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире*
*jailmir@mail.ru*

УДК 94(47)

*Р.Р. Исхаков*

# XVI–XVII ГАСЫРДА ИДЕЛ–УРАЛ ХАЛЫКЛАРЫН ХРИСТИАНЛАШТЫРУ ҺӘМ ТАТАР-КЕРӘШЕН КОНФЕССИОНАЛЬ БЕРЛЕГЕН ФОРМАЛАШТЫРУ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

В статье рассмотрена политика по христианизации нерусских народов Волго-Уральского региона в XVI – XVII вв., приведшая к формированию татаро-кряшенской конфессиональной общности. На историческом материале рассмотрены этноконфессиональные процессы среди крестившихся татар, христианско-просветительская деятельность православной церкви, внутриполитический курс московского государства в отношении коренного населения Казанского края.

**Ключевые слова:** христианизация народов Волго-Уралья, история татар-кряшен, межконфессиональные отношения.

Керәшеннәрнең (старокрещеных татар) этноконфессиональ берлеген формалаштыру православие чиркәвенең христиан-мәгърифәтчелек эшчәнлеге һәм Идел–Урал регионында берничә йөз еллар дәвамында барган катлаулы этномәдәни процесслар белән бәйләнгән. Бүгенге тарих белгечләре фикеренчә, керәшеннәрнең бабалары христианлыкка мөрәҗәгать итү XVI гасырның икенче яртысында, Казан ханлыгы руслар тарафыннан яулап алынгач башлана. Иван IV сәясәтенең иң мөһим аспектларының берсе – яулап алынган крайдагы җирле халыкны христианлаштыру була. Шушы максаттан Казанда 1555 елда Троицк-Селижаров монастыре игумены Гурий (1490–1563) җитәкчелегендә епархия оештырыла. 1552 елда ук инде Казанда – Зилантов, Свияжскида – Успенский, 1556 елда Казанда – Спасо-Преображенский, 1557 елда Казанда – Иоанно-Предтеченский һәм Чабаксарда Троицкий монастырьлары төзелә.

Әйтеп үтелгән чорларда регионда христианлыкны тарату сәясәте әле көчле булмый. Әледән-әле кабатланып торган халык күтәрелешләре, регионда чиркәү-миссионерлык челтәренең зәгыйфь булуы, дәүләт эчендә һәм аның көнбатыш, көнчыгыш чикләрендәге тотрыксызлык нәтиҗәсендә, Мәскәү администрациясенең чукындыру акциясен массакүләм күренешкә әйләндерергә мөмкинлеге булмый. Миссионерлар хезмәтенең төп объектын татар халкы тәшкил итә. Бигрәк тә аның хәрби-сәяси элитасын христианлыкка әйләндерүгә зур игътибар бирелә. Инкыйлабка кадәр дә, хәзер дә шушы өлкә белән махсус шөгыльләнә торган тикшеренүчеләрнең күбесе [Можаровский, 1871; 1880, с. 10–23; Хрусталев,

с. 2–16; Григорьев, с. 22–23; Ермолаев, с. 18–19; Загидуллин, с. 34–38] шул фикерне куәтлиләр. Моны күпсанлы тарихи процессларны, вакыйгаларны тасвирлаган хезмәтләр (нарратив) дә раслый. Иван IV тарафыннан Казан архипастырена бирелгән, Урта Идел регионында миссионерлык эшчәнлеген алып баруның тәфсилле инструкциясенә әйләнгән «Хәтер күрсәтмәсе»ндә («Наказной памяти») митрополит Гурийның һәм аның көрәштәшләренең төп игътибары элеккеге Казан патшалыгы халкына юнәлдерелергә тиешлеге ассызыклана. Нигездә, әлеге документта татардан («татаровя», «татара») башка нинди дә булса милләт искә алынмый [Акты..., с. 259–261].

Татарларга карата мондый игътибарның сәбәпләре күптөрле, ә иң мөһиме – Мәскәү дәүләтенең сәяси-идеологик мәнфәгатьләре [Можаровский, 1880, с. 16], дип әйтергә кирәк. Кичәге хәрби оппонентлары христианнарына мөрәҗәгать итеп, хөкүмәт буйсынмас крайны үзенә күндерергә, анда «чын» динне (христианлыкны) таратырга ният тота. «Патша» диненә күчүчеләр яңа хакимияткә яраклашуларын раслыйлар, хокукый яктан «руслар»га әйләнә.

Мондый карашның, чыннан да, реаль нигезе бар. Рәсми рәвештә кайсы да булса диндә исәпләнү, ул динне кабул итүченең (прозелит), дини генә түгел, сәяси яктан да карашларын чагылдыра. Моннан тыш, конфессиональ бирелгәнлек, социаль статус белән беррәттән, этник страфикациянең состав өлешен тәшкил итә; бу очракта ул «руслык»ның мөһим күрсәткече булып санала. Затның рәсми яктан кайсы да булса бер дингә бирелгәнлеге, киң мәгънәдә алганда, аның мәдәни-цивилизацион юнәлешен дәлилли. Урта гасырларда конфессиональ бирелгәнлеккә мондый мөнәсәбәт христиан Европасы һәм мөселман көнчыгышы илләренең күбесенә хас күренеш булган. Россиядә әлеге караш Яңа заманда да (XVI–XVII гасырда да) саклана, ул самодержавиенең дини сәясәтенә йогынты ясавын дәвам итә, илнең башка диндәге халыкларын дини унификацияләү юнәлешендә дәүләт катнашын активлаштыруда мөһим фактор булып тора [Исхаков, с. 16–18].

Шуннан соңгы вакыйгалардан аңлашылганча, дәүләтнең яңа гражданнарына карата күтәрелгән сәяси максатлары үзләрен аклыйлар. Яңа чукындырылганнар (керәшен татарлары) регионда Рус дәүләтенең таянычына әверелә. Алар 1555 елгы баш күтәрүләрне бастыруда, 1550–1580 елларда Казан татарлары һәм чирмешләр (марилар) белән сугышларда русларны яклап чыгыш ясыйлар, озак елларга сузылган Ливон сугышында рус атлы гаскәренең регуляр булмаган (иррегуляр) часте сыйфатында катнашалар [Можаровский, 1871, с. 23; Галлямов, с. 53–63].

Православиегә күчүнең төп фазасы 1550 елның икенче яртысы – 1560 елның башына туры килә. Инкыйлабка кадәрге чиркәү тарихы фәнендә (историография) ул турыдан-туры Казанның

беренче митрополиты Гурий һәм аның якын көрәштәшләре Варсонофий белән Герман эшчәнлегенә бәйләп күрсәтелә. 1560 еллар уртасына татарлар арасында миссионерлык хәрәкәте сүлпәнләнеп кала. Чөнки әлеге сәясәтнең баш идеологлары һәм гамәлгә ашыручылары җирле халыкны христианлыкка күчерүдә актив эшчәнлек алып бара алмыйлар. Митрополит Гурий гомеренең соңгы елларында көчле авырый (1564 елда вафат була) һәм мөстәкыйль хәрәкәтләнә алмый, Спасо-Преображенский монастыре архимандриты Варсонофий (татар телен белүче бердәнбер изге ата) 1567 елда Тверь шәһәренә күчерелә [Загидуллин, с. 43].

Чукындыру, нигездә, Казанны алгач ук башлана. 1553 елда Мәскәүдә Казан патшалыгының законлы соңгы хакимнәре Сафагәрәйнең кечкенә яшьтәге улы Үтәмешгәрәй (чукындыргач – Александр) һәм Ядегәр Мөхәммәт хан (чукындыргач – Симеон) православиене кабул итә [Ногманов, с. 22]. Казан хакимнәрен чукындыру акты, ханлыкның элеккеге гражданнарының христианлыкка актив мөрәҗәгать итүе, символик күренеше буларак, аеруча мөһим идеологик вакыйга төсен ала.

Казан артында (Казан өязендә) чукындыру үзәге булып Казан Спасо-Преображенский монастыре санала. 1566–1568 елларда Казан буенча исәпкә алу кенәгәсендәге (писцовая книга) мәгълүматлардан билгеле булганча, чукындыру өчен махсус «три кукоти полотнаны, что крестят новокрещен» [Список..., с. 30] эшләнә. Тау ягында исә (Свияжск өязендә) Свияжскидагы Успенский монастыре шушы максатларны тормышка ашыра. Социаль планда караганда, христианлаштыру йомышлы (служилый) катлау вәкилләре арасында актив алып барыла. Р.Ф. Галләмов исәпләре буенча, XVII гасыр башына Кама буйларындагы йомышлы татарларның 40% ы чамасы чукындырыла, ә башка катлауларда бу күрсәткеч 5% тан артмый [Галлямов, с. 46].

Аерым чыганаклардан мәгълүм булганча, татарлар белән беррәттән, крайда яшәүче рус булмаган башка халык вәкилләре дә христианлыкка күчә башлый (дөрес, аларның саны күпкә аз була). Керәшен татарлары арасында аларның интеграцияләнүе ихтималын да онытырга ярамый, чөнки аларны йола-гадәтләр, көнкүреш, тел охшашлыгы, озак еллар Идел–Урал төбәгенең уртак тарихи-мәдәни шартларында яшәү берләштерә. Болардан тыш, Кама буе керәшен татарлары составына, күп кенә үзенчәлекле сыйфатларын һәм телен югалтып, татарлашкан, әмма үзләренең этник культурасының нигезләрен онытмаган башка милләт вәкилләре төркемнәре дә кушыла. Яңа керәшеннәр арасындагы этноконфессиональ процессларга һәм аларның культурасына, дингә табыну формаларына үзенчәлек өстәгән мөһим факторлардан яңа керәшеннәргә карата дәүләт һәм чиркәү хакимиятләренең аерым позициясен әйтеп үтәргә була. Кабиләдәшләре арасында христианлык юнәлешен саклау

катлаулы булачагын истә тотып, дәүләт администрациясе православиегә күчкәннәрне чукындырылмаган халыктан аерырга омтыла. Бу чаралар Иван IV улы – патша Федорның 1593 ел, 18 июльдә Казан гаскәре башлыклары (воевода) И.М. Воротынский белән А.И. Вяземскийга җибәргән грамотасы (аның нигезендә чукынганнар белән чукындырылмаганнарга бергә яшәү тыела) һәм чукындырылмаган татарларга православныйларны урнаштыруны тыю хакындагы 1622 ел, 16 июль указы белән законлаштырыла [Законадательные..., с. 113]. Бу боерыклар XVIII гасыр урталарына кадәр гамәлдә була. Крайдагы җирле халыкның христианлыкка күпләп күчүе белән бәйле рәвештә, Яңа чукындырылганнар конторасы («Новокрещенских дел конторы») эшчәнлеге елларында гына ул үтәлүдән туктый. Чиркәү һәм җирле дөньяви органнар (яңа чукындырылганнар командасы) мондый зур масштаблы бурычларны үтәргә сәләтле булмый. Өстәвенә, христианлыкны яңа кабул итүчеләр һәм аларның чукындырылмаган кабиләдәшләре үзләренең туган якларын, яшәгән җирләрен ташлап китәргә теләмиләр. Шул сәбәпле, чукындырылган татарларның күбесе мөселман кабиләдәшләре янында яшәп кала, һәм бу күренеш XIX гасырда һәм XX гасыр башында аларның кире исламга кайтуына сәбәп була.

Дәүләт төрле тыюлар юлы белән һәм җирләр биреп, яңа чукынганнарның миграцион процессларына контроль урнаштырырга омтыла һәм күп очракта ул аңа ирешә дә. 1565–1568 елларда патша окольничийлары Н.В. Борисов белән Д.А. Кикинның Казан һәм Казан өязен исәпкә алу язмаларындагы, шулай ук 1602–1603 елларда Иван Болтинның исәпкә алу кенәгәсендәге мәгълүматлар буенча ул чорларда Казан өязендәге[1] кайбер авылларда яңа чукындырылганнар, татарлар, әсирләр («полоненики») һәм чувашлар яшәгән булсалар, 1771–1773 еллардагы ревизия нәтиҗәләре бу чорда Казан наместниклыгында «иске керәшен» авылларында составлары ягыннан тулысынча диярлек бер диндәгеләр яшәвен күрсәтә. [Сборник..., 1908].

Әлеге сәясәтнең тагын да мөһимрәк нәтиҗәсе керәшен татарларының бер өлешенең тиз арада руслашуында чагыла. Дөньяви һәм дини органнарның керәшеннәр белән татарларны бергә яшәүдән тыю, керәшеннәрнең христиан дине кануннары нигезендә яшәвен генә түгел, ә аларны руслаштыруны да күздә тотып эшләнә. Бу күренеш чиркәү ведомствосына караган (архирей һәм монастырь җирләрендәге) торак пунктларда аеруча нык сизелә [Историко-статические..., с. 32–33; Ермолаев..., с. 20]. Рус крестьяннарын, ирекле колонизацияләү дә алып барыла. Аларны керәшеннәр яши торган авылларга күчерәләр. Руслар арасында яшәгән керәшеннәрнең шактые үзләренең элеккеге конфессиональ юнәлешләрен генә түгел, ә этник үзенчәлекләрен дә югалталар. Бу процесс бигрәк тә чукындырылган татарларның хәр-

би-феодаль югары катлавында киң үсеш ала. Рус дворяннары арасындагы төрки фамилияле затлы нәселләр нәкъ менә шулардан күтәрелеп киткән дә инде.

XVI гасыр ахырына христианлаштыру акцияләре масштабларын югалтсалар да, керәшеннәр формалашу белән бәйле этномәдәни процесслар аннан соңгы йөзьеллыкларда да дәвам итә. Керәшеннәр сафына аерым затлардан яки крайдагы христианлыкны кабул иткән татарларның һәм башка җирле халык вәкилләренең азсанлы төркемнәреннән торган яңа этник элементлар кушыла бара.

Әлеге конфессиональ төркемнәр формалашу процессын бәяләгәндә, аңа күпчелекне тәшкил иткән этномәдәни (төрки-татар) бергәлекнең һәм башка чит этник элементларның ассимиляцияләшүе дип карарга кирәкми. Бу процессны, сыйфат ягыннан, үзенә бер яңа этномәдәни бергәлекне формалаштырган берничә этник элементның консолидациясе (берләшүе, туплануы) дип бәяләү дөресрәк булыр. Керәшеннәрнең һәм аларга килеп кушылган, чыгышы белән татар булмаган төркемнәрнең кыска вакыт аралыгында шулай кушылып китүе урта гасыр ахырларында региондагы җирле халыклар арасында анык кына этномилли чикләр булмавын аңлата. Алар арасындагы чикләр конфессиональ һәм социаль хәлләренең аерымлыклары ягыннан гына саклана [Исхаков, с. 59]. Христианлыкны рәсми кабул иткәннән соң, бу аерымлыкларның күбесе юкка чыга, бу күренеш җирле халык вәкилләренең мәдәни һәм этник яктан якынлашуына уңай шартлар тудыра. Кама буе керәшеннәрен берләштерүче этник һәм мәдәни «үзәк» ролен татарлар үти. Керәшеннәрнең электән сакланып килгән традицион мәдәнияте – татар теле, гореф-гадәтләре, дини-мифологик күзаллаулары өстенлек итә. Күпсанлы тарихи чыганаклар һәм керәшеннәрнең матди һәм рухи мәдәниятен өйрәнү мәгълүматлары белән беррәттән, аерым нәселләрнең һәм авылларның килеп чыгышы турында аларның үзләрендә сакланган күптөрле тарихи риваять-хикәятләр дә сөйли [Износков: М., 1895; Казань, 1895; Емекеев: 1902, с. 343–346; 1904, д. 305 и др.].

Керәшеннәрнең этник составы чукындырылганга кадәр аларның кайсы диндә булуын билгеләргә мөмкинлек бирә. XVI гасырга караган күпчелек чыганаклардан мәгълүм булганча, татарлар үзләре яшәгән тирәлектәге башка милләтләр тарафыннан регионда ислам традицияләрен йөртүче мөселман дөньясы вәкилләре буларак кабул ителәләр. Рус телендәге документларда «татары» сүзенең синонимы итеп бисермяне/басурманы/агаряне конфессионимнары кулланыла. Шунысы кызык, XVI–XVII гасырларны яктырткан рус телле чыганакларда христианлыкны кабул иткән татарларны бу этноним белән атамаганнар, чөнки «татарлар» сүзе аларның элекке конфессиональ статусы белән ассоциацияләшә. Татарларның мөселманнарга тәңгәллегенә чит ил замандашлары

да игътибар итә. Иван IV сараендагы Австрия илчелеге әгъзасы С. Герберштеин болай дип яза: «татары разделены на орды… все исповедуют магометанскую веру; если их называют турками, они бывают недовольны, почитая это за бесчестье. Название же бесермяне их радует. И этим именем любят себя называть» [Герберштеин, с. 167].

Җучи олысы (Алтын Урда) тарихының башлангыч этапларында аның составында христиан кабиләләренең титуллы затлары яшәүгә, христианнар дәүләте белән мәдәни элемтәләр булуга карамастан, мондый мәгълүматлар хакында дәлилле фактлар очрамады. Г.М. Макаров бу хакта бик ачык яза: «...признаков их присутствия (татар-христиан. – *Р.И.*) в этот период письменными источниками, как церковными, так и светскими не выявлено. Не известны также материалы о каких-либо легендарных церквях и монастырях, о жизни христиан в ханскую эпоху, о святых христианских мучениках и воителях за веру. Христианство является религией с развитыми традициями письменности, однако каких-либо памятников христианско-тюркской письменности до XVI века не обнаружено… Вышеприведенные сопоставления являются достаточными аргументами в пользу того, что тюркские христианские общины, как полноценные социальные структуры в татарском феодальном обществе, в частности, в Казанском ханстве, к середине XVI века едва ли существовали» [Макаров, 2001, с. 22].

Казан ханлыгы территориясендә христианлыкка табынган күпме төрки халык төркемнәре яшәгән булса, ул чорның рус телле чыганакларында алар турында яктыртылмый калмас иде. Казан ханлыгы озак вакытлар Мәскәү дәүләтенең геосәяси дошманы булып кала бирә, шуңа күрә рус елъязмачылары күрше дәүләттә барган вакыйгалар, анда яшәүче халыкларның дини һәм сәяси омтылышлары белән яхшы таныш була, һәм алар бу хакта үз хезмәтләрендә тәфсилләп теркәп баралар. Христиан дине тәгълиматларын дәвам итүчеләр мондый вакыйгаларны тарихи документларда яктыртып кына калмыйча, алар рус сәяси һәм чиркәү элитасының хәрби оппоненты белән барган идеологик көрәшен рус патшасының казанлыларга дәгъваларын нигезләүдә файдаланган булырлар иде. Моннан тыш, христианлыкның мондый җирлеге тарихи риваятьләрдә, халык хәтерендә, фольклорда чагылыш тапкан булыр иде, әмма алар региондагы татарларда да (шул исәптән керәшеннәрдә дә), башка халыкларда да сакланмаган.

Димәк, Казан татарларының рәсми рәвештә мөселман конфессиясе вәкилләре булуы хакында ныклы ышаныч белән әйтә алабыз. Җирле халык арасыннан аерым төркемнәрнең исламны кабул итү дәрәҗәсен билгеләү бераз катлаулырак. Бу сорауга җавап бирү өчен җитәрлек күләмдә тәҗрибәләргә нигезләнгән мәгълүматларга ия булу зарур. Урта гасыр төрки-татарларын (бигрәк тә мөселман мәдәни үзәкләре са-

налган эре шәһәрдә яшәүчеләрне) исламлаштыруга караганда, XIX гасырда һәм XX гасыр башында Идел–Урал татарларын исламлаштыру мөһимрәк саналуына бернинди шик юк. Минемчә, бүгенге заманның күп кенә тикшеренүчеләре, Урта гасырлардагы дини процессларны бәяләп, империя дәверенең институциональ эпохасында (татарларның мәдәни тормышында динитәгълимат хәлиткеч роль уйнаган чорда) барлыкка килгән социомәдәни реалияләрне үткәннәргә күчереп һәм арттырып күрсәтәләр. Моның сәбәпләре күп төрле, шуларның берсе – XVIII–XIX гасырлар татар тарихы белемендә «исламның алтын гасыры» дигән караш хөкем сөргәндә, яшәп килгән традицияләрне мификлаштыру: әйтик,Урта Идел буйлары кяферләр тарафыннан яулап алынганнан соң, рус хакимлеге урнаштыру фикерен күтәрү. Монда идеологик спекуляция шаукымы чалымлана, проблеманың фәнни ягы үзгәртелеп, дини белем дискурсы тарихчыл, әхлакый-этик яки дини тәгълиматка алыштырыла.

Бераллалык традицияләрен кабул итү (үзләштерү) катлаулы һәм озак дәвам итә торган процесс, ул берничә йөз елларга сузыла, аның барышында, әкренләп, дини аң, йола-гадәтләр, дөньяның дини-мифологик картинасы үзгәрә. Татарларда бу процесс Казан краеның Мәскәү державасы составына кертелүенә кадәр дә тәмамланмаган була. Әлеге тезисны, татарлар белән бергә, региондагы бераллалык традицияләре нигезендә яшәүче башка этник төркемнәргә – рус халкына карата да кулланырга була. Хәзерге заман тикшеренүчеләре раслаганча, авыл җирләрендә яшәүче русларны чиркәүгә тарту фәкать XVIII–XIX гасырларда гына тәмамлана. Аның мәдәниятендә православие ритуаллары һәм борынгы славяннарның мәҗүсилек йолалары, күзаллаулары яшәү дәвам итә [Levin, p. 31–52].

Хан дәвере «татар» исламын ике төп юнәлешкә бүлеп карарга кирәк: «элитар», «халыкчан». Беренчесе исламның ортодоксаль нормаларына һәм мөселманнарның «югары» культурасына нигезләнгән шәһәр элитасы казанышы булса, икенчесе синкретик характерга ия һәм ул авыл халкы тормышында мөһим урын тота. Җирле кешеләрнең халыкчан исламны кабул итүләрендә җитди аерма бар. Бу чорда татарга тәңгәлләшкән һәм рәсми мөселман конфессиясенә хас сыйфатларны үзләштергән, аларның яңа этник һәм социаль статусының состав өлешен тәшкил иткән фин-угыр һәм төрки телле чуваш халыклар вәкилләре өчен исламга күчү стадиясе башлангыч этабын кичерергә тиеш була. Җирле йомышлы катлау составындагы шактый зур төркем саналган утрак халыкның һәм төрки-кыпчак чыгышлы күчмә-килмешәкләрнең мөселман динен тоту дәрәҗәләре дә аерылып торырга тиеш була. Бераллалыкка (Аллаһ ихтыярына) нигезләнгән (Откровение) башка диннәрдәге кебек үк, ислам тәгълиматы да утрак халык өчен якын була. Үзенчәлекле культура, социаль һәм көнкүреш

шартларында гомер кичергән күчмә төрки халыкларга ислам бик акрын иңә, чөнки аларда дини инануның традицион позицияләре көчле саклана. Бу хакта XI–XV гасырларда Җүчи олысы биләмәләрендә булган гарәп илгизәрләре раслый, алар үзләренең хезмәтләрендә җирле төркиләрнең дини күзаллаулары хакында әһәмиятле мәгълүматлар язып калдырганнар [Тизенгаузен, с. 457–458; Становление..., с. 151–176]. Алар, шулай ук, Көнбатыш Европа замандашлары язмаларында да урын алган [Гарустович, с. 94].

Мөгаен, исламлашу дәрәҗәсе әллә ни югары булмаган татар халкы төркемнәре, Казан яулап алынганнан соң, христианлаштыруның төп объекты булган. Сәяси режим тамырдан үзгәртелгән вәзгыять шартларында татарларның бер өлеше үзләренең конфессиональ юнәлешләрен үзгәртәләр. Бу процессның нигезе яңа хакимиятнең ачыктан-ачык мәҗбүр итүе белән бәйләнмәгән булса кирәк. Ирекле рәвештә христианлыкка күчүдәге өстенлекләр митрополит Гурийга бирелгән «Хәтер күрсәтмәсе»ндә («Наказной памяти») дә ассызыклана [Можаровский, с. 15]. Әлбәттә, бу – христианлыкны бөтенләй үк ирекле тарату белән бәйләнмәгән, чөнки әлеге ысул Рус дәүләте һәм патша сарае даирәсендә зур абруйга ия булган, шулай ук чиркәүнең, яшьлегендә ярсу холыклы, «Явыз» кушаматлы Иван IV нең ышанычын яулап өлгергән «иосифлылар» сафы эшлеклеләренең дини-сәяси карашларына туры килеп бетми. Монда җирле халык белән җитди конфликтлар булдырмаска тырышу да мөһим сәбәпләрнең берсе санала. Ачыктан-ачык көчләү гамәле әле болай да катлаулы вәзгыять хөкем сөргән, ныклап «буйсындырылып» бетмәгән крайдагы барган сугыш һәм баш күтәрүчеләр хәрәкәте территорияләренең тагын да киңәюенә китерергә мөмкин. Моннан тыш, Мәскәү җитәкчелеге рус патшасына уңай (лояль) мөнәсәбәттә булган һәм гаскәрләре составында шактый өлешне тәшкил иткән йомышлы татар-мөселманнарның да мәнфәгатьләрен истә тотарга тиеш була.

Әмма XVI гасырның икенче яртысындагы хәрби-сәяси вакыйгалар шартларында буйсындырылган халыкны рәхимсез рәвештә көчләп чукындыру очраклары да аз булмаган, алар хакында татар-мөселманнарда, шулай ук керәшеннәрдә сакланып калган тарихи риваятьләр сөйли. Аларда Казан җиңелгәннән соң христианлыкка көчләп күчерүнең ямьсез картиналары сурәтләнсә дә, бу әле югары хакимият тарафыннан алып барылган максатчан сәясәтне характерламый.

Үзләре теләп чукыну очраклары аз булмый, әмма әлеге гамәлне ирекле акт дип әйтә алмыйбыз. Ул, тыныч юл белән алып барылган миссионерлык эшчәнлегенә бик үк бәйле булмаган, мәҗбүри адым була. Басып алынган Казан краена җибәрелгән, татар телен белмәгән рус миссионерларының аларны дошман санаган халык арасында, үзләренә куркыныч янаган шартларда рус динендә булмаганнарга

(неофитларга) православие дине хакында вәгазь укып йөрүләрен, бөтенләй башка дини-мәдәни системада яшәгән халыкны христианлыкны кабул итәргә күндерүләрен күз алдына китерү дә кыен. XIX гасырның икенче яртысына кадәр православиенең җирле халык дини-мәдәни традицияләренә әкрен үтеп керүе нәкъ шуның белән бәйле. Шуннан соң инде Казан миссионерларына христианлаштыру ысулларының яңалары, йогынтылырагы тәкъдим ителә. Рус тарихчылары мәгълүматларына караганда, христианлыкка күпләп күчү күренеше Казан епархиясе оешканчы (ягъни крайда православие тәгълиматлары барлыкка килгәнче) ук шактый киң җәелгән булуы да игътибарга лаек. 1552 елда, мәсәлән, татар кенәзләре һәм морзалары арасыннан әсирлеккә төшерелгән 500 кеше Үзәк Россиянең православие монастырьларына эшкә җибәрелә, һәм алар тиздән христианлыкны кабул итәләр [Татищев, с. 357]. 1553 елда Казан елъязмачысы бу хакта түбәндәгеләрне хәбәр итә: «...казанские люди евси, живущие в окрестных странах града того, вся земля казанская, тако же и вся земля Сибирская с молением прихождаху к царю государю великому князю, покоряющиеся, повинии себя творяху и милости прошаху и во всю волю вдашаяся православному царю государю. Мнози же от неверных прихождаху з женами и з детьми и крещахуся» [Полное собрание русских..., с. 478]. Әлеге өзектән кызыклы гына берничә нәтиҗә ясарга мөмкин. Җирле халыкның яңа патшага буйсынуы һәм халык массасының аның каршысына «баш иеп» килүе фактыннан тыш, аларның бер өлешенең христианлыкка күчүе дә игътибарны җәлеп итә. Шулай ук, бу документтан аңлашылганча, әлеге гамәл, миссионерлык акты нәтиҗәсе булмыйча, сәяси адым, неофитларның яңа патшага буйсынуы күренеше буларак карала.

Православие миссионерлары күздә тотканча, Казан епархиясе оешкач, христианлыкка күчүнең мөһим һәм иң тәэсирле механизмы булып югары хакимият тарафыннан билгеләнгән һәм «Хәтер күрсәтмәсе»ндә («Наказная память») теркәлгән аерым хокукларны (мәсәлән, югары дәрәҗәле рухани затларга патшадан кемнеңдер гаебен кичерүне үтенү – «печалование» – мөмкинлеген) санаган була. Христианлыкны кабул иткән кеше, чиркәү органнары протекциясе буенча, җинаяте өчен җәзадан азат ителә. Шушы ук чара, рус гаскәрләре белән хәрби бәрелешләрдә катнашып, әсирлеккә алынганнарга карата да кулланыла. Христианлыкны кабул итү, кемнеңдер элеккеге хәрби-сәяси ориентациясеннән яки яңа хуҗасыннан баш тартуына караганда, табигыйрәк җәза булып санала, һәм югары хакимият каршында да, чиркәү даирәсе өчен дә аның гаебен кичерү һәм җәзадан азат итү өчен җитәрлек дәрәҗәдәге әһәмиятле аргумент булып исәпләнә. XVII гасырда бу преференциягә салым кимелү һәм чукынучыларны крепостнойлыктан азат итү кебек чаралар өстәлә

[Полное собрание законов, с. 312–313; 644–645].

Христианлыкка мөрәҗәгать итү формаларының тыштан караганда, мөһим дини установкаларында әллә ни зур аерма булмау һәм аның православие конфессиональ статусын рәсми үтәүгә кайтып калуы чукынучыларда табигый реакция – үзләренең элеккеге халәтләренә кире кайту теләге уята. Керәшеннәрнең күбесе, православиене рәсми кабул итүләренә карамастан, чукынганга хәтле булган яшәү рәвешләрен дәвам итәләр. Патша Иван Федоровичның Казан митрополиты Гермоген (Ермолай) (1589–1602) хәбәренә нигезләнгән 1593 ел, 18 июль грамотасында керәшеннәрнең хәле болай сурәтләнә: «В Казани и в Казанском и Свияжском уездах живут новокрещеные с татары, и с чуваш, и с черемисы и с вотяк вместе… и к церквам Божьим не ходят, и крестов на себе не носят, в домах своих божьих образов и крестов не держат, и попов в дома свои не призывают, и отцов духовных не имеют, и к роженицам не зовут, только не сам поп, сведав роженицу, приехав даст молитву; и детей своих не крестят, только поп не обличит их; и умерших в церкви хоронити не носят, кладутся по старым своим татарским кладбищам; а женихи к невестам своим по татарскому своему обычаю приходят, а венчаться у церкви, и снова венчаются в своих домах попы татарскими, и во все посты и среды и пятницы скором едет… да и многие скверные татарские обычаи новокрещены держат бесстыдно, а христианской веры не держат и не навыкают; и он Ермоген Митрополит в прошлом году февраля в 12 день со всего Казанского уезда призывал новокрещенов в соборную церковь Пресвятые Богородицы и поучал их от божественного писания и показывал и не по один день, как подобает крестьянам житии, и новокрещены учения не принимают и от татарских обычаев не отставают, а живут в великом бесстрашье и, конечно, от христианской веры отстали» [Акты..., с. 436].

Әлеге документтан аңлашылганча, христианлыкны рәсми кабул итүләренә карамастан, керәшеннәрнең дини хәле чукынмаган кабиләдәшләренекеннән әллә ни аерылмый. Алар үзләренең элеккеге инануларына таяналар, «татар поплары»н чакыралар, мәетләрне иске гадәтләр буенча, шул ук зиратларга җирлиләр, рус руханиларыннан читләшәләр һ.б. Чиркәү учреждениеләре челтәре зәгыйфьлеген, православиенең мәхәлләләрдә җирле халык телен белгән квалификацияле вәгазьчеләре булмауны, яңа чукынучыларның иске йола-гадәтләренә һәм диннәренә бирелгәнлеген, әлегә кадәр хөкем сөргән мәдәни нигезләрдә яшәүләрен дәвам итүләрен формаль актлар белән генә читләштереп булмый әлбәттә.

Боларны аңлаган чиркәү җитәкчелеге христианлыкны әле генә кабул иткән диндәшләре (прозелит) арасында провославие йогынтысын көчәйтүнең яңа адымнарын ясый. Казан епархиясенең беренче җитәкчесе тара-

фыннан монастырьлар каршында керәшеннәргә православие дине нигезләрен укыту өчен махсус мәктәп ачу – шул адымнарның берсе [Рыбушкин, с 109; Никольский, с. 45].

Тарихи риваятьләрдә дә митрополит Гурийның региондагы җирле халык арасында христианлыкны таратуга православиене кабул иткән татарларны җәлеп итүе хакында мәгълүматлар сакланган. Этнограф һәм тарихчы И.А. Износков тарафыннан 1860 елларда бик өлкән яшьтәге кенәз Искаковтан (аның Исхак исемле ерак бабасы Казанны яулап алуда катнашкан) язып алган хикәяттә мондый юллар бар: «...арскими наездниками казаками; конница его тревожила русские укрепления на Арском поле, а сам он участвовал во многих битвах с русскими по дороге из Казани в Арск. По взятии Казани свят. Гурий, крестив Василия (старший брат Искака, татарское имя, бывшее у него до принятия крещения, неизвестно. – *Р.И.*) и Искака, рукоположил их во священники, первого в Дюртели, а второго в с. Богородское Казанского уезда. Оба брата обратили… многих своих родственников мухаммедан в христианство. Старший же (из братьев. – *Р.И.*) остался мухаммеданином и жил в том месте Лаишевского уезда, где теперь находится татарская дер. Большие Нырсы» [Износков, с. 9]. Язып алынган икенче риваятьтә чукындырылган Искак морзаның Дүртөйле-Субаш авылында православие гыйбадәтханәсе салдыруы, ә XVIII гасыр урталарында аның Казан губернасы, Лаеш өязе, Карабаян авылына күчерелүе бәян ителә [Историко-статистическое..., с. 75]. Агиографик (изгеләрнең тәрҗемәи хәлләрен тасвирлаучы) әсәрләрнең берсендә Казанның беренче изгеләре, шул исәптән, христианлыкны кабул иткәннән соң, үзләренең татар туган-тумачалары арасында шушы юлны пропагандалаган өчен алар тарафыннан үтерелгән Стефан белән Петр турында язылган [Можаровский, с. 23].

Безнең кулда әлеге хикәятләрне турыдан-туры раслаучы мәгълүматлар булмаса да, аларның нигезендә реаль тарихи вакыйгалар булу ихтималын инкарь итә алмыйбыз. Һәм әлеге фактларны дөрес дип уйласак та, әйтелгән вакыйгаларга алар җитди йогынты ясый алмаган, чөнки алар чикләнгән характерда гына булган. Христианлык белән үзләре дә бик аз таныш прозелитлар эшчәнлеге фәкать тышкы формада гына алып барылган.

Рус руханилары һәм җирле епархиаль җитәкчелек тарафыннан ачыктан-ачык оештырылган вәгазьләр керәшеннәрнең дини аңына артык зур йогынты ясый алмаган. Моңа мәхәллә халкы белән чиркәү дин әһелләре (клир) арасындагы тел, социаль һәм этник аерымлыклар да комачаулаган булса кирәк. Пастырьлык һәм миссионерлык хезмәтенең төп авырлыгы йөкләнгән православие руханиларының аз санлы, шуның өстенә әзерлек дәрәҗәләре түбән булу аларга яңа чукындырылганнарны чиркәүгә тарту эшчәнлеген дөрес алып барырга комачаулый. Моннан тыш,

яңа чукындырылганнарның шактый зур территорияләргә җәелгән мәхәлләләрен чиркәү контролендә тотарга җайсызлык тудыра. Ә бу неофитларның яңа дингә инануларын зәгыйфьләндерә һәм аларда элеккеге дини күзаллауларының саклануына китерә торган мөһим фактларның берсе булып санала. Казан краена көчеп килгән, җирле халык яшәеше белән аз таныш, шул ук вакытта аз санлы православие монастырьлары һәм мәхәлләләре (приходлары) «башка диндәгеләр диңгезендә»ге кечкенә «утраулар»ны хәтерләтәләр. Яңа чукындырылганнарның дини карашларына йогынты ясауның реаль механизмнарына ия булмаган чиркәү дәүләт-административ чараларыннан файдаланырга мәҗбүр була.

Аларның берсе – керәшеннәргә татар авылларына урнашып яшәүнең тыелуы. Яңа чукындырылганнар өстеннән югары администрация тарафыннан ныклы контроль куела. Казан яулап алынганнан соң христианлыкка күчкән затларның исәбе алына. Моннан тыш, яңа чукындырылганнарның барысын да бер конфессияле аерым торак пунктларга (бистәчеләргә) күчерү күздә тотыла. Керәшеннәрне православиедә көчләп тотуга юнәлдерелгән катгый чаралар эшләү хөкүмәт өчен шулай ук җитди бурыч булып санала. Патшаның Казан воеводалары И.М. Воротынский белән А.И. Вяземскийга юнәлдерелгән 1953 ел, 18 июль грамоталарында болай диелә: «А которые новокрещены христианские веры крепко держати и поученья митрополита и отцов духовных слушати не учнут, и вы б тех велели смиряти, в тюрьму сажати и битижелези и в чеписажати». Бу гамәлләрнең төп максаты: «чтоб одноличноновокрещенов всех во христианскую веру привесть крепко и утвердить, а от татарския веры отучити и острашати»дан гыйбарәт була [Акты..., с. 437].

Чуваш тикшеренүчесе Д. Макаров әлеге грамота турында болай дип яза: «...составляет определенную грань в миссионерской политике царизма в Поволжье и Приуралье. С этого времени насильственный характер христианизации становится более отчетливым и временами принимает открытую форму» [Макаров, 2000, с. 54]. Дини мәсьәләләргә карата дәүләтнең һәм чиркәүнең карашы үзгәрү яңа хакимиятнең Казан краенда торган саен позициясе ныгу, җирле халыкның хәрби активлыгы кимү һәм, шуннан чыгып, җирле халыкның состав өлешен илдә хакимиятлек итүче дингә әкренләп күчерүне күздә тоткан эчке сәяси курсын гамәлгә кую белән бәйләнгән була.

Дәүләти миссионерлык, христианлаштыруның административ формалары һәм православиедә тоту чукынучыларның дини карашларын барыбер тамырдан үзгәртә алмый. Бу гамәлләр проблеманы чишү түгел, ә аны тагын да тирәнәйтә генә. Чукындырылганнар, җәза бирелүдән куркып, тыштан гына булса да, христианлыкның төп күрсәтмәләрен үтәргә һәм иске диннәре кагыйдәләреннән баш тартырга мәҗбүр булалар. Әмма аларның

христианлык белән бәйле дини күзаллауларында эчке үзгәрешләр чагылыш тапмый.

Федор Иванович һәм Борис Годунов идарә иткән чордагы аяусыз миссионерлык сәясәтеннән соң, югары хакимиятнең йогынтысы көчсезләнү еллары башлана. Бу вазгыять илдә фетнә-чуалышлар һәм крестьян күтәрелешләре башлануга сәбәп була. Бу яңа чукындырылучылар өстеннән чиркәү административ контролен дә көчсезләндерә, һәм, нәтиҗәдә, христианлыкка көчләп күчерелгәннәрнең бер өлеше кире үз диннәренә кайта. Мондый күренешләрне 1646 елгы исәп кенәгәсендә (писцовые книги) чукындырылганнарның күбесе рус дип түгел, ә төрки исемнәр белән язылуы раслый [Галлямов, с. 52]. Исем конфессиональ статусның әһәмиятле бер күрсәткечен тәшкил иткән чорда бу факт әлеге затларның этномәдәни һәм дини өстенлегенең ачык дәлиле булып тора.

Илдәге хәлләр әкренләп тотрыклана барган саен бу процесс та юкка чыга. Христианлыкны кабул итүчеләрнең православиедән китүләрен туктату өчен 1749 елгы Рус дәүләте законнары җыелмасында (Соборное Уложение), чит диннәр йогынтысын чикләү максатыннан, православие христианнарына чукындырылмаган кабиләдәшләренә һәм чит ил кешеләренә хезмәт итү һәм алар белән бергә яшәү тыела. Прозелитизмның һәм православиегә каршы пропаганданың, башка дингә күчүнең теләсә кайсы формасы зур җинаять булып санала. Аерым алганда, православие вәкилен башка дингә тарткан өчен түбәндәге җәзалар карала: «того басурмана по сыску казнить, сжечь огнем без всякого милосердия» [Полное..., с. 71].

XVII йөзьеллык Идел–Урал регионында христиан мәгърифәтчеләре өчен катлаулы чор саналса да, бу елларда татарларның һәм башка милләт вәкилләренең христианлыкка мөрәҗәгать итүе тукталмый. Бу эшчәнлек Каманың түбән агымы буйларындагы элек Казан ханлыгына кергән районнарда, Нократ белән Кама аралыгындагы территорияләрдә дәвам иттерелә. Инкыйлабка кадәрге чиркәүләрне өйрәнгән тарихчы, профессор И.М. Покровский мәгълүматларына караганда, Җөри даругасының төньяк-көнчыгыш өлеше авылларындагы татарларны һәм удмуртларны чукындыру вакыты XVII гасыр азагына туры килә. Вакытлар узу белән анда үзәге Казан губернасы, Мамадыш өязе, Оштырма Юмья авылы булган керәшен православныйлар мәхәлләсе (приходы) барлыкка килгән [Историко-статистическое..., с. 232].

Православие чиркәве, җирле халыкны христианлаштыру өчен мөмкинлекләре чикле булганга, регионда, һич югы, үзенең йогынтысын һәм биләмәләрен киңәйтергә омтыла. Бу елларда яңа чукындырылганнар күпләп яшәгән авылларда беренче православие гыйбадәтханәләре салына. Казан губернасы, Мамадыш өязенең Мамадыш һәм Тау иле авылларындагы, чиркәүле авыл Мамадыштагы (Трехсвятское) гыйбадәтханәләр XVII гасыр башында ук төзелә [Историко--

статистическое..., с. 297], Троицкий монастыре һәм аның каршында чиркәүләр төзү 1616 елда тәмамлана. Шушы ук йөзьеллыкның икенче яртысында Кама аръягындагы Зәй һәм Минзәлә каравыл ныгытмаларында чиркәүләр сафка баса.

Империя системасын формалаштыру өчен, XVIII гасыр башында идарәчел катлауның рус булмаган халыкларны, дини унификацияләү юлы белән, дәүләт системасына интеграцияләү процессын активлаштыруы таләп ителә һәм, шуның белән бәйле рәвештә, Казан краенда христиан-мәгърифәтчелек эшчәнлеген оештыру да сизелерлек үзгәреш кичерә [Каппелер, с. 131].

Петр I дәвере законнар җыелмасында дин тоту мәсьәләсендә дәүләтнең позициясе кырыслана. 1713 ел, 3 ноябрь Указы нигезендә йомышлы татарларның җәмгыятьтәге статусына, аларның дини табынуыннан бәйле рәвештә, катгый таләпләр урнаштырыла. Мөселман алпавытлар, үзләренең православие динендәге крепостной крестьяннарын саклап калу өчен, указ чыкканнан соң алты ай эчендә христианлыкны кабул итәргә тиеш булалар. Шулай эшләмәгәндә, аларның утарлары (имениеләре) казна файдасына күчерелә [Полное собрание законов – 1]. 1720 елның 1 сентябрь указы белән православиене кабул итүчеләр өч ел дәвамында барлык төр җыемнарны һәм дәүләт файдасына алына торган имана-салымнарны льгота нигезендә түлиләр [Полное... – 1, т. VI, № 2734; № 2920]. 1722 елда чукынучылар рекрутлык йөкләмәсеннән азат ителә, 1723 елда православие неофитларның җинаятьчел гамәлләре өчен җәза тәртибен җиңеләйтү карала [Полное... – 1, т. VII, № 3637; № 4123].

Христианлыкны кабул итүчеләргә вәгъдә ителгән өстенлекләр һәм җиңеллекләр закон белән ныгытылганнан соң, дәүләт һәм чиркәү органнары рус булмаган халыкларны массакүләм христианлаштыру сәясәтен тормышка ашыруга керешәләр. Моның өчен 1731 елда Свияжскида Казан һәм Түбән Новгород мөселманнарын чукындыру комиссиясе («комиссия по крещению казанских и нижегородских мусульман») оештырыла, 1740 елда ул Яңа чукындырылганнар конторасы («Новокрещенских дел контору») итеп үзгәртелә [Ислам, 1999; 2005].

Архиепископ Лука (Конашевич) Казан кафедарасында архиерей булып эшләгән 1742–1755 елларда Яңа чукындырылганнар конторасы эшчәнлеге үзенең апогеясына күтәрелә. Бу чорда мөселманнарның бик күп гыйбадәтханәләре җимертерелә, рус булмаган халыкны көчләп чукындыру активлаша, бу процессны тизләтүгә полиция хезмәткәрләре һәм хәрби частьләр җәлеп ителә, һәм христианлаштыру ачыктан-ачык көчләү гамәлләре белән тормышка ашырыла. Бу елларда Урта Идел регионындагы рус булмаган җирле халыкның төп массасы чукындырыла. Фәкать татар-мөселманнар гына үзләренең конфессиональ бөтенлеген саклап кала. Ф.Г. Ислаев мәгълүматлары буенча 1744–1762 елларда барлыгы

12615 татар гына чукындырыла [Ислаев, с. 99; 176].

XVIII гасырның беренче яртысында, Идел–Урал регионындагы рус булмаган халыкларны күпләп чукындыру белән беррәттән, чиркәү православиене элегрәк кабул иткәннәр арасында христианлык йогынтысын көчәйтү юнәлешендә дә эш алып бара. Шушы максаттан епархиаль җитәкчелек чукындырылганнарның дини-әхлакый хәлләре турында мәгълүматлар җыя башлый, православие руханилыгына милли кадрлар әзерләү өчен конфессиональ мәктәпләр (яңа чукындырылганнар мәктәпләре) ача, яңа мәхәлләләр туплый.

Җирле чиркәү органнары дини ведомстволары һәм мәхәллә причтлары соравы буенча 1720–1730 елларда әзерләнгән рәсми документлардан күренгәнчә, керәшен-татар мәхәлләләрендә дини ситуация тотрыклы булмый. XVI–XVII гасырларда чукындырылганнар, шактый еллар православие чиркәве кул астында яшәүләренә карамастан, православие тәгълиматлары белән таныш булмыйлар. Казан митрополиты Сильвестр (Холмский-Волынец) (?–1735) тәкъдиме белән чыгарылган Указда Зәй авылы мәхәлләсеннән ерак булган авылларда чукындыру, никах һәм мәет күмү йолалары православие чиркәве таләпләре буенча алып барылмавы, аларның кемнәргә кагылуы турында мондый юллар бар: «Казанского уезду арские и зюрейские дорог деревни Сарсаз, деревни Налим, деревни Средний Багряш, деревни Иванаевы, деревни Федоровы, деревни Ураевы, деревни другие Федоровы, деревни Елтановы, сотнику Никите Яковлеву, выборному Василию Матвееву, старосте Якову Федорову и всем мирским людям, лета от Рождества христова 1729 году марта в 6 день» [Матвеев, с. 6]. Митрополит Сильвестр билгеләп үткәнчә, 1729 елның февралендә ул Арча һәм Җөри даругаларының (Казан губернасындагы Мамадыш өязенең булачак территориясе) керәшен-татар авылларында була. Җирле кешеләр, тылмач аша, аңа үзләренең моннан 170 еллар элек чукындырылулары, рус телен белмәүләре, чиркәүләрнең ерак булуы («верст на 40») сәбәпле, «молитву Иисусову творить на мало умеют и то не все, а крестное знамение воображать и закон христианский в твердости исполнять и содержать от ненаучения и непризрения не умеют», дип белдерәләр [Ильминский, с. 252]. 1736 елда митрополит Сильвестр тарафыннан Изге Синодка җибәрелгән хәбәрдәге юллар тагын да күңелсезрәк картинаны гәүдәләндерә: «видел их в богомерзких жительствах весьма закоснелыми и упорными» [Ильминский, с. 252].

Димәк, тарихи чыганаклардан билгеле булганча, XVII гасырда һәм XVIII гасырның беренче яртысында чукындырылганнарның дини культурасына православие тирән үтеп керә алмый. Чиркәү документларында бик хаклы рәвештә әйтелгәнчә, мондый хәлнең төп сәбәбе – чукындырылганнар белән чиркәү арасында бәйләнешнең тиешле дәрәҗәдә куелмавы. Үзләренең

мәхәллә башлыклары – рухи аталары белән элемтә булмау, үз авыллары тормышы эчендә бикләнеп яшәү нәтиҗәсендә алар элек-электән килгән табыну йолаларын дәвам итәләр, ә православие традицияләре турында ныклы күзаллаулары булмый. Православие йогынтысы көчәюенең әйтеп үтелгән сәбәпләре белән бергә, ул ассимиляция процессларына да тәэсир итәргә тиеш була. Чукындырылган татарлар һәм башка халык вәкилләре русларга тәңгәллекнең мөһим гәүдәләнеше булган православиене кабул иткәч, әкренләп үз милли үзенчәлекләрен югалтып, көнкүрештә һәм мәдәни өлкәдә җирле рус халкы белән якынлаша [Историко-статистическое..., с. 32]. Шулай итеп, христианлык йогынтысына ныграк буйсынган һәм башка шартларда, мәдәни бәйләнешләр һәм гаилә элемтәләре аша үз кабиләдәшләрендә православиене ныгытуга хезмәт итә торган затлар, әкренләп, рус булмаган җирле халыкларның этномәдәни киңлегеннән төшеп калалар. Моннан тыш, «рус» динен кабул иткәннән соң, руслашу процессы һәм элеккеге этномәдәни тәңгәллек үзгәрә һәм рус булмаган, әмма чукындырылган халык арасында үзләренең элеккеге яшәү рәвешләрен, көнкүрештәге яшәү шартларын саклау теләге уяна.

Казан митрополиты Сильвестр, бу хәлдән котылу өчен, яңа гыйбадәтханәләр ачарга омтыла. Аның таләбе буенча 1729 елда Уфа губернасы, Минзәлә өязенә караучак Зәй мәхәлләсенең Налим авылында Покров Пресвятой Богородицы хакына агачтан чиркәү салына. Бу яңа мәхәлләгә аңа якын авыллардан Урта Баграж, югары Баграж (Чувай), Сарсаз, Сармаш[2], Федоровка авыллары кертелә. Шушы ук вакытта Җөри, Юкәче, Мунчала күле (Мочалкино озеро) [Историко-статистическое..., с. 5], Отарка, Чура (Мамадыш өязенә караган) һәм Апаз (Казан өязенә караган) [Ляпидовский, л. 61] авылларында православие гыйбадәтханәләре төзелә башлый. Бу чиркәүләр җирле епархиаль җитәкчелекнең бердәм планы нигезендә салына [Ляпидовский, л. 61]. Яңа гыйбадәтханәләр ачылгач барлыкка килгән православие мәхәлләләре, вакытлар узу белән, керәшен авылларында чиркәү-миссионерлык үзәкләренә әвереләләр һәм җирле халыкны православиегә тартуда, аларны христиан йолалары белән таныштыруда мөһим роль уйныйлар.

Элеккеге кебек үк, христиан-мәгърифәтчелек эшчәнлеген җәелдерүне тоткарлаучы төп сәбәпләрдән мәхәллә руханиларының әзерлеге түбән булуны, мәхәлләгә кергән җирлектәге халыкның телен белмәү нәтиҗәсендә пасторьлык хезмәтен тиешле дәрәҗәдә оештыра алмауны әйтергә кирәк. Моны чиркәүләрдә сакланган язма документлар раслый. Император галиҗәнабләренең Алабуга дини идарәсенә караган 1760 елгы 31 декабрь Указында Налим авылы руханилары Максим Егоров белән Борис Михайловка, татар телен белмәгәнлектән, үзләренең мәхәлләләрендә вәгазьләрне һәм дини күрсәтмәләрне

мимика ярдәмендә үтәргә («как чинится исповедь глухонемым») [Матвиев, с. 8] тәкъдим ителә. Табигый ки, миссионерлык эшчәнлегенең мондый юлы белән мәхәлләдәге халыкның дини инануларын тамырдан үзгәртү, аларга христианлыкның төп эчтәлеген сеңдерү мөмкин булмый.

Яңа чукындырылганнар конторасы эшләп торган дәвер (ул 1764 елда рәсми ябыла) керәшеннәр арасында алып барылган миссионерлык эшчәнлеге тарихында билгеле бер этап булып тора XVIII гасырның 40–50 нче елларында Идел–Урал регионындагы рус булмаган халыкларны чукындыру сәясәтен тормышка ашыру барышында чукындырылган татарларның яңа төркеме барлыкка килә, рус телендәге чыганакларда аларны «новокрещены» (яңа керәшен), ә элек (XVI–XVII гасырларда) чукындырылганнарны «старокрещены» (иске керәшен, таза керәшен) дип атыйлар. Православиене кабул иткән татарларның болай рәсми бүленеше дәүләтнең 1722 елгы беренче ревизиясеннән соң барлыкка килә [Ислаев, с. 276]. Иске керәшеннәрнең халык культурасы системасы һәм синкретик дини күзаллаулар нигезендә формалашкан конфессиональ үзаңы күтәрелеше, шулай ук аларның татар халкының төп массасыннан (шул исәптән яңа керәшеннәрдән дә) аерып торган православие конфессиясендә булуы да шушы вакытка карый. Иске керәшеннәрнең аңына сеңдерелгән, тора-бара шушы берлек вәкилләрен характерлаучы үзенчәлек тә әлеге чорда барлыкка килгән булса кирәк. С.Х. Алишев мәгълүматлары буенча, нәкъ менә XVIII гасырның икенче яртысында татар телле чыганакларда, чукындырылган татарларны атау өчен, керәшен сүзе кулланыла башлый[3].

Татарлардан иске керәшен һәм яңа керәшен төркемнәре формалашу турында сүз барганда шуны билгеләп үтәргә кирәк: традицион культураларында һәм дини юнәлешләрендә төрлелекләр булуга карамастан, XIX гасырның икенче яртысына кадәр әлеге төркемнәргә бүлеп карау күп яктан шартлы характерда гына була. XVIII гасырның икенче яртысы дәвамында, ә кайбер очракларда соңрак та, иске керәшеннәр составына яңа керәшеннәр төркеме, шулай ук христианлыкны кабул иткән, шул тирәдә урнашып яшәүче башка милләт вәкилләре дә керә. Мәлки керәшеннәре (Казан губернасы, Тәтеш һәм Цивильск өязләре) проблемасына аерым тукталу урынлы булыр. Бабаларының төп массасы христианлыкка XVIII гасырның беренче яртысындагы христианлаштыру елларында мөрәҗәгать иткәнлектән [Филиппов, с. 4–25], алар «татарлардан чыккан яңа керәшеннәр» булып саналалар[4]. Шуңа да карамастан, аларда православие конфессиясенә тәңгәллек сыйфатлары XIX гасыр һәм XX гасыр башында гына көчәя башлау сәбәпле, алар керәшеннәр берлегенә аерым этнотерриториаль төркем буларак килеп кушылалар.

**Әдәбият**

*Levin E.* Dvoeverie and Popular Religion // Seeking God: The Recovery of Orthodox Russia, Ukraine and Georgia, 1991.

Акты археографической экспедиции. Т.1. СПб. 1836. №241/II.

Акты археографической экспедиции. Т.1. СПб., 1836. №358.

*Галлямов Р.* После падения Казани… Казань, 2001.

*Галлямов Р.Ф.* Этнические процессы в Предкамье после завоевания его Русским государством // Межэтнические и межконфессиональные отношения в Республике Татарстан. Казань, 1993.

*Гарустович Г.Н.* Религиозная ситуация в Золотой Орде глазами современников // Ислам и власть в Золотой Орде // Сборник статей / под ред. И.М. Миргалеева, Э.Г. Сайфетдиновой. Казань, 2012.

*Герберштейн С.* Записки о Московии. М., 1988.

*Григорьев А.Н.* Христианизация нерусских народностей как один из методов национальной политики царизма в Татарии. Со второй половины XVI в. до февраля 1918 года // Материалы по истории Татарии: сб. ст. Казань, 1948.

*Емекеев С.* Ногайбаки // Православный благовестник. 1902. №24.

*Ермолаев И.П.* Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII в. Казань, 1982.

*Ермолаев И.П., Липаков Е.В.* Крестьяне дворцовых сел Казанского уезда в конце XVI – первой четверти XVII в.: по материалам дозорных и переписных книг // Иследования по истории крестьянства Татарии дооктябрьского периода. Казань, 1984.

*Загидуллин И.* Причины отпадения старокрещеных татар Среднего Поволжья в мусульманство в XIX в. // Ислам в татарском мире: история и современность: материалы международного симпозиума. Казань, 29 апреля – 1 мая 1996 г. Казань, 1997.

Законодательные акты Русского государства второй половины XVI – первой половины XVII вв. Тексты. Л., 1986.№119.

*Износков И.А.* Список населенных мест Казанской губернии с кратким описанием их. Лаишевского уезд. Вып.1, 2. Казань, 1895.

*Износков И.А.* Материалы для истории христианского просвещения инородцев Казанского края. Изд. 2-е. М., 1895.

*Ильминский Н.И.* Записка по вопросу об отпадениях крещеных татар Казанской губернии 1881 года // Христианское просвещение и религиозные движения (реисламизация) крещеных татар в XIX – начале XX вв. Сборник материалов и документов / сост., авт. вступительной статьи, приме¬чаний, научно-справочного аппарата Р.Р. Исхаков. Казань, 2011.

*Ислаев Ф.Г.* Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: от конфронтации к веротерпимости. Казань, 2001.

*Ислаев Ф.Г.* Православные миссионеры в Поволжье. Казань, 1999;

*Ислаев Ф.Г.* Религиозная политика российского государства и ее реализация в Волго-Уральском регионе (XVIII в.): дис. … д-ра ист. наук. Казань, 2005.

Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. Вып.6. Г. Мамадыш и Мамадышский уезд. Казань, 1904.

*Исхаков Д.М.* Методологические аспекты изучения этногенеза и этнической истории тюркских народов Волго-Камья // Региональные энциклопедии: проблема общего и особенного в истории народов Среднего Поволжья и Приуралья: материалы научно-практической конференции (20–22 сентября 2006 г.). Казань, 2007.

*Исхаков Д.М.* Молькеевскиекряшены: проблема формирования и демографическое развитие в XVIII – начале XX вв. // Молькеевскиекряшены. – Казань, 1993.

*Исхаков Р.Р.* Миссионерство и мусульмане Волго-Камья (последняя треть XVIII – начало XX в.). Казань, 2011.

*Каппелер А.* Две традиции в отношениях России к мусульманским народам Российской империи // Отечественная история. 2003. № 2.

*Ляпидовский Г.* Краткие сведения о Чуринском приходе Мамадышского уезда Ядыгаровской волости // ОРРК КФУ. Ф. И.А. Износкова. Д. 2244. Л. 61.

*Макаров Г.М.* Перспективы развития традиционной культуры кряшен в современных условиях // Этнические и конфессиональные традиции кряшен: история и современность: материалы научно-практической конференции. Казань, 2001.

*Макаров Д.М.* Самодержавие и христианизация народов Среднего Поволжья (XVI–XVIII вв.). Чебоксары, 2000.

*Матвеев С.М.* О крещеных инородцах Уфимской епархии. Уфа, 1910.

*Можаровский А.Ф.* Изложение хода миссионерского дела по просвещению казанских инородцев с 1552 по 1867 год. М., 1880.

*Можаровский А.Ф.* Покорение Казани русской державе и христианству. Казань, 1871.

*Никольский Н.В.* Народное образование учуваш // Собрание сочинений. Т. II. Чебоксары, 2007.

*Ногманов А.* Самодержавие и татары. Очерки истории законодательной политики второй половины XVI–XVIII веков. Казань, 2005.

Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565–1568 гг. / сост. Д.Н. Мустафина. М., 2006, Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов / сост. Р.Н. Степанов. Казань, 1979.

Полное собрание законов – 1. Т. 2, № 867. С. 312–313; № 1099.

Полное собрание русских лебописей, т. 19.

*Рыбушкин М.* Краткая история города Казани. Казань, 1834. Ч. 1. С. 109

Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в. / под ред. проф. Д.А.Корсакова. Казань, 1908.

Список с писцовых книг по г. Казани с уездом. Казань, 1877.

Становление и расцвет Золотой Орды. Источники по истории Улуса Джучи (1266 – 1359 гг.) / сост., вступ. ст., коммент., указатели М.С. Гатин, Л.Ф. Абзалов. Казань, 2011.

*Татищев В.Н.* История Российская. Т. VII. Л., 1968.С.357.

*Тизенгаузен В.Г.* Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Т. 1. Извлечение из сочинений арабских. – СПб., 1884.С.457–458.

*Филиппов Г.* Из истории христианского просвещения крещеных татар-мещеряков Тетюшского и Цивильского уездов Казанской губернии // ИКЕ. 1915. № 37.

*Хрусталев А.* Очерк распространения христианства между инородцами Казанского края // Миссионерский противомусульманский сборник: труды студентов миссионерского противомусульманского отделения при Казанской духовной академии. Вып. V. Казань, 1897.

## Искәрмәләр

[1] Бу чорда Казан өязе зур территориягә ия була.Яңа керәшеннәрнең төп массасы яши торган Казан арты һәм Каманың түбән агымы буйлары территорияләре аның составына керә.

[2] Кама аръягының көнчыгыш өлешендә урнашкан керәшен авылларындагы православие гыйбадәтханәләренә өстәлеп, 1771 елда Ляки авылында чиркәү төзелә.

[3] Иске керәшен татарларын атый торган «керәшен» (дөресрәге «чукындырылган») сүзе 1846 елда – И. Ляпидовскийның Казан губернасы, Мамадыш өязе, Чуринск мәхәлләсе турындагы этнографик язмаларында теркәлә (ОР РНБ. Ф. 573 (СПбДА). Оп. 1. Д. А I / 232. Л. 14–18 об.).

[4] XVIII гасырның икенче яртысы – XIX гасырның беренче яртысына караган дәүләт һәм статистик материалларда «новокрещеные чуваши» билгеләмәсе дә очрый.

***Исхаков Радик Равил улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Керәшеннәр һәм нагайбәкләрнең тарихын өйрәнү үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 94(47)

***И.А. Мөстәкыймов***

# XVII ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ – XVIII ГАСЫР БАШЫ УРТА ИДЕЛ ТАРИХЫНА КАРАГАН ИКЕ МӘГЪЛҮМАТ

В статье рассматриваются два сообщения «татарских летописей» – хроникальных записей XVIII – первой половины XIX в. Публикуемые и разбираемые сообщения ранее не публиковались. В одном сообщении говорится о возведении стены вокруг казанской Татарской слободы в 1677 г., в другом сообщении нашел отражение набег казахского султана (позднее – хана) Абу-л-Хайра на Закамье, совершенный им в 1715, 1717 или 1720 г.

**Ключевые слова:** татарские хроники, татары, казахи, Казань, Татарская слобода, Среднее Поволжье.

Бу мәкалә татар елъязмасына кагылышлы ике мәгълүматны, төгәлрәге, XVIII–XIX гасырның беренче яртысындагы хроникаль язмаларны тикшерүгә багышлана.

Әлеге хроникаль язмалар Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә ике кулъязма булып саклана. Икесе дә шактый җентекләп эшләнгән. Игътибарыбызны җәлеп иткән әлеге мәгълүматлар башка татар хроникаларында безнең күзебезгә чалынмады һәм, ялгышмасак, басылмады; алар хакында белдерү дә булмады.

Беренче мәгълүмат ике бит язмадан тора. 1б–2а битләрендә (сак. бер. 1589т.) мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәеновның җәйге кыска көннәрдә мөселманнарның кичке (ястү) намазын уку турындагы фәтва (дини-хокукый карар) исемлеге бирелгән. Фәтва 1821 елның май аенда фарсы телендә язылган. Икенче б битендә «Фи бәйанет тарих» («Тарихны бәян итү») исемле язма бирелгән. Анда 1552 елда Казанны басып алудан башлап (һиҗри елы буенча 959 ел дөрес күрсәтелгән; гадәттә татар хроникаларында ул 961 ел итеп бирелә, бу очракта Казанны яулап алу вакыты 1553 елның 7 декабреннән 1554 елның 25 ноябре арасына туры килә), 1762 елда кояш тотылуга кадәр булган вакыйгалар исемлеге китерелгән. Язылган кәгазьнең җитештерелгән елын да күрергә була. Анда «1819» дип язылган. Димәк, кулъязма XIX гасырның 20 нче елларында төзелгән.

Безнең игътибарыбызны җәлеп иткән мәгълүмат болай яңгырый: «...тарих мең дә сиксән йитедә, барыс йылында, М.хавич Й.лашай дигән байар бистә тигрәсенә кальга суктырды». (ОРРК НБЛ КФУ, сак. бер. 1589т, б. 2).

Кем соң ул бояр һәм дивар төзү уе ничек туган? Иң элек

шуны әйтеп узарга кирәк, бу хәбәрдә төрки-монгол календаре һәм мөселман ай календаре буенча саннарда аермалыклар бар. Төрки-мөселман чыганаклары өчен мондый аермалыклар сирәк күренеш түгел. Һижри 1087 елга иң якын барс елы 1674 елга туры килә. Иван Черновның 1840 елда дөнья күргән «Казан шәһәре Күрсәткече»ндә китерелгән мәгълүмат буенча, 1673 елның 27 июленнән Казан воеводство җитәкчеләре булып, кенәз Юрий Иванович Ромодановский һәм бояр Иван Павлович Акинфов булалар; сәркәтипләре – Яков Портомоин һәм Каллинник Патрикеев. Әмма Акинфов һәм Портомоин вафат булу сәбәпле, аларның урыннарына, шул ук елда булса кирәк, воевода Григорий Степанович Караулов килә. 1673 елда воевода булып, бояр Иван Богданович Милаславский килә, Григорий Степанович Караулов аның ярдәмчесе итеп билгеләнә. Сәркәтипләре – Аврам Кощев, Иван Ярославцев (Чернов, 1840, б. 377). Әлеге кешеләр 1674 елда да вазифаларын башкаралар.

Һижри 1087 ел юлиан календаре буенча 1676 елның 6 мартыннан алып 1677 елның 22 февраленә туры килә. 1677 елда Казан воеводалары булып Михаил Львович Плещеев, Василий Лаврентьевич Пушечников хезмәт итәләр. Сәркәтипләре – Иван Родионов һәм Борис Корелин (Чернов, 1840, б. 377). Татар чыганакларында күрсәтелгән «М.хавич Й.лашай» исемендә беренче сүз Михаил Львовичның исеме һәм әтисенең исеменә, ә ахыргы сүз, хаталы булса да, – П.лашай – Пеләшәй, ягъни «Плещеев» фамилиясенең татарча яңгырашына туры килә. Бу фикерне бер факт дәлилләп тора: 1667 елның 22 мартында Казан воеводлары М.Л. Плещеев һәм В.Л. Пушечниковка патшадан әмер бирелә: «…в Казани многие торговые люди, не явясь в таможне с товары своими, проезжают в Татарскую слободу тайно, по ночам и товары свои складывают в той слободе у татар. И в том казанским таможенным пошлинам чинитца убыль многая. И столником и воеводам Михаилу Плещееву с товарыщи о том в Казани велеть учинить заказ крепкой и таможенным головам и целовалником приказать смотрить и беречь накрепко, и в той Татарской слободе учинить сторожи крепкие, чтоб одноконечно торговые какие люди с товары не явясь в таможне головам и целовалником, в тое Татарскую слободу тайно не ездили» (Димитриев, с. 358). Әлеге күрсәтмәләрне үтәү һәм татар бистәсенә килә торган сәүдәгәрләр өстеннән ныклы күзәтү булдыру өчен, бистәне дивар (стена) белән әйләндереп алу карары кабул ителгәндер, күрәсең.

Татар бистәсен стена белән әйләндереп алу хроникада телгә алынган икән, бу гадәти генә факт түгел. Беренчедән, шунысы кызык, «стена» мәгънәсен бирү өчен текстта гадәттә ныгытма, крепость сүзен аңлата торган «кальга» термины кулланылган. «Кальга» сүзе «крепостная стена» терминына якын мәгънәдә Урта гасыр азакларында Бохарада кулланылган. Икенчедән, бу

очракта датаны һиҗри елы белән билгеләү, хайван календаре белән күрсәтүгә караганда, күпкә төгәлрәк булып чыккан.

Икенче мәгълүмат – 4199т шифры астында саклана торган кульъязма – 1973 елда археографик экспедиция вакытында Пермь өлкәсе Кунгур районы Усть-Турка авылында табыла. Ул 6 биттән тора һәм бер кеше кулы белән язылган. Хроникаль язманың 1а–2б битләрендә төрле вакыйгаларның «Фаслы тарих дастанында» дип исемләнгән кыскача исемлеге бирелгән. Ул пәйгамбәрләрнең (Адәм галәйһиссәламнән башлап) күпме гомер яшәве турындагы мәгълүмат бирүдән башлана һәм һиҗри 1145 елда Ырынбур крепосте төзелү, шуңа бәйле рәвешле башкорт восстаниясе турындагы вакыйганы искә алу белән төгәлләнә.

Кульъязманың 3а–4б битләрендә фарсы телендәге поэтик әсәрнең бер өлеше, ә 5а–6б битләрендә төрки телдәге әсәрнең өземтәсе бирелгән. Без бу язмаларны атрибуцияли алмадык. Кульъязмаларның кәгазе саргайган, тузган, шуңа җитештерү елын да белү мөмкинлеге булмады. Язма якынча XVIII гасырның икенче яртысы – XIX гасырның башларына карый.

Безнең игътибарыбызны җәлеп иткән мәгълүмат болай яңгырый: «Тарих мең дә йөз дә йегерме түрттә Сыр дәрйасындын Төркестан йирендин ләшкәр берлә Әбелхәйер солтан килеп, шәһре Болгарны һәлак кылып багындыра башлады. Шәһре Болгар халайыкы ләшкәр төзеп каршы торып, Әбелхәйер солтанны һиммәт кылып качырдылар. Йир селкенде, йир-күк гөрләде, туп аткантик тавыш булып, халайык тәмам ишеттеләр» (ОРРК НБЛ КФУ, ед. хр. 4199т, л. 2б).

1124 һиҗри елы юлиан календареның 29 гыйнвар 1712 – 16 гыйнвар 1713 елына туры килә. Әлеге язмада сүз казакъ солтаны (соңыннан ханы) Әбелхәирнең Кама аръягына яу белән килүе турында бара. Бу сугышлар 1715, 1717, 1720 елларда була [Ерофеева, с. 151–152].

Бу мәгълүматта «шәһәр» сүзенең «область, төбәк, юрт» мәгънәсендә кулланылышы игътибарны үзенә җәлеп итә. Татар һәм башка төрки халыкларда бу термин гадәттә «шәһәр» мәгънәсен аңлата бит. Әлеге хроникада «шәһре Болгар» сүзе Урта Идел мәгънәсендә тагын бер тапкыр кулланылган: «Тушкан елы булды, ашлыг-тарыг булмады шәһре Болгарда төн тарафларында» (ОРРК НБЛ КФУ, сак. бер. 4199т, б. 2а).

«Шәһәр» сүзенең, төп мәгънәсенә өстәп, «өлкә, төбәк» мәгънәләрендә кулланылуы төрек теленә дә хас [Redhouse, p. 1143]. Мәсәлән, «төбәк» мәгънәсе төрек солтанының 1565 елда Кафа санҗакбәенә җибәргән әмерендә күренә: šehr-I Azaqda – Азов төбәгендә [Numarali, s. 190].

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: безгә төрки-татар хроникаль язмаларны җыярга һәм туплап бастырырга кирәк. Кыскалыгы, хронологик яктан буталчыклыгына карамастан, бу язмалар татар халкының тарихын, телен өйрәнү өчен кыйммәтле чыганак булып торалар.

**Әдәбият**

*Димитриев В.Д.* «Царские» наказы казанским воеводам XVII века // История и культура Чувашской АССР: Сборник статей. Вып. 3. Чебоксары, 1974. С. 284–419.

*Ерофеева И.В.* Хан Абулхаир: полководец, правитель, политик. Алматы, 2007. 456 с.

ОРРК НБЛ КФУ, ед. хр. 1589т.

ОРРК НБЛ КФУ, ед. хр. 4199т.

*Чернов И.* Указатель города Казани, или Памятная книжка для жителей Казанской губернии на 1840 год. Казань, [1840]. – 14 см.

5 Numaralı Mühimme Defteri (973/1565–1566): Tıpkıbasım. Ankara, 1994. 703 s.

*Redhouse, J.W.* A Turkish and English Lexicon. İstanbul, 2006. 2224 p.

***Мөстәкыймов Ильяс Альфред улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең архив документларын фәнни куллану һәм халыкара элемтәләр секторы җитәкчесе*

УДК 821.512.145

*Ф.З. Яхин*

# ТАТАР ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕНДӘ ГАЛИ ХАЛИТ

В статье дается анализ научно-исследовательской деятельности Г. Халита, татарского советского литературоведа XX века, которым были разработаны принципы изучения истории татарской литературы на основе социально-генетической методологии, оценивающей и рассматривающей художественные произведения как проявление общественной мысли. В статье автор доказывает поэтапный отход ученого от социально-генетического подхода к литературе, раскрывает особенности творческих поисков ученого, выявляет, что именно Г. Халиту принадлежат теория синтеза реализма и романтизма в татарском литературоведении, а также теория ускоренного развития татарской литературы начала XX века. Автор оценивает и объясняет сущность данных теорий.

**Ключевые слова:** социологизм, социально-генетическая методология, татарская литература начала XX века, история общественной мысли, народность, классовость, советское литературоведение, теория ускоренного развития литературы.

Гали Халитнең (1915–1992) нинди зур галим булуын аңлау-аңлату өчен татар әдәбият белеме фәненең тарихчысын берникадәр искә төшереп алу хәерле. Ерак китмибез. Аның әдәбият белеме өлкәсенә килү елларына гына күз салабыз.

XX йөзнең 20–30 нчы елларында әдәбият белеме фәне бөтен асылы белән диярлек социаль-генетик принципларга, гадирәк итеп әйткәндә, социологизмга корылып өлгерде. Социалистик җәмгыять төзү өчен, киләчәктә ирешеләчәк коммунизмга дөрес баруда әдәбият-сәнгать тулысынча сәяси-идеологик таләпләргә җавап бирергә һәм хезмәт итәргә тиеш иделәр. Татар әдәбияты гыйлеме бу яктан алдынгы булды, аның авангардында данлыклы революционер әдип Г. Ибраһимов барды. Ул татар тарихын ничек социологизм һәм революцион большевизм юлында дөрес ачыклап корса, тел һәм әдәбият фәннәрен дә социологизм принципларында өйрәнү ягында иде. Бу фәнни өлкәләрдә Г. Ибраһимов 1917 елга кадәр танылып өлгергән, рус әдәбияты-теле галимнәре А.А. Потебня һәм аның укучылары хезмәтләренә таянып фикер йөртүче алдынгы сафлардагы тәнкыйтьче дә булып җитешкән иде, югыйсә. Аның карашларының киңлеге, фикерләренең тирәнлеге һәм стиленең бәхәскә этәрү көченә ия булуы сокландыра, әлбәттә. Рус эстетика һәм поэтика мәктәбе фикерләмәләрен кабул иткән һәм татар тәнкыйте өлкәсендә үстерә алган Г. Ибраһимов, алга таба В.И. Ленинның һәм Г.В. Плехановның өйрәтмәләренә таянып, татар әдәбиятының пролетарий

һәм революцион катламын ачып сала, өйрәнү һәм бәяләү эшен башлый. Ул гына да түгел, 1906 елда ук «Матур әдәбият һәм капитализм» хезмәтен бастырган һәм әдәбиятны өйрәнгәндә һәм бәяләгәндә иҗтимагый-генетик методны файдалана башлаган, 1917 нче елдан соң аның методологиясен эшләгән В.М. Фриче хезмәтләрендәге фикерләрне дә ачык аңлап кабул итеп, татар әдәбият белемен марксизм нигезенә кора. Шул сәбәпләргә бәйле, без Г. Ибраһимовны татар фән дөньясында социологизм принципларын үзлегеннән һәм үзенчә җитештергән галим буларак та беләбез. Әмма Үзәк, ягъни һәртөрле милли-мәдәни хәрәкәтләргә сизгерлек күрсәткән Мәскәү, Г. Ибраһимовның карашларына корректура кертергә ашыкты. «Демократик централизм» дип аталган большевистик принцип әдәбият һәм сәнгать өлкәсенә генә түгел, фәнгә дә баш була барды. Мәдәният өлкәсенә бәйле социологизм теориясе марксизмнан үсеп чыккан иде. Ул социал-демократ, революционер һәм гомумән дә революцион фикерләр иясе, әмма халыкчан рухлы Г.В. Плеханов тарафыннан нигезләнгән һәм төгәл аңлатылган, алга таба В.М. Фриче хезмәтләрендә конкретлаштырылган, системага салынган, XX йөзнең беренче чирегендә үстерелгән теория буларак, советлар чорында әдәбият һәм сәнгать үсешен билгели һәм бәяли торган, әдәби-мәдәни тормышны аңлатып бирә алучы бердәнбер принципка әйләнеп калды. Яңа совет мәктәпләре укучыларны һәм вузлары исә гыйльми кадрларны өлгер рәвештә шушы социологизм методикасын һәм методологиясен өйрәтү, принципларын аңлату һәм төшендерү эшенә керештеләр. Әдәбият иҗтимагый фикер өлкәсенә әверелде. Әмма социологистлар, болар белән генә канәгатьләнә белмичә, сәясәткә дә үтеп керә башладылар һәм шуның нәтиҗәсендә «вульгар-социологистлар» ярлыгын алдылар. Эшләре каты тәнкыйть уты астында гына түгел, бәлки юк ителү белән тәмамланды.

Социологизм принцибы әдәбиятны һәм мәдәниятне турыдан-туры сыйнфый-революцион үзаң белән тәңгәл куя, шул үзаңны тәрбияләүгә яраклы булу-булмавына карап бәяли иде. Фәнне дә ул феодаль, буржуаз, пролетарий, вак буржуаз (крестьян) карашлар буларак, сыйнфыйлаштырып күзаллау ягында торды. Әгәр әдәби әсәр феодализм чорында язылса, анда феодаль карашлар хөкем сөрә, әгәр капитализм дәверендә тудырылган икән, ул вакытта – буржуаз була. Халыкчан икән – вак буржуаз, революцион икән – пролетарийлашкан һ.б. Бу формулалар, әлбәттә, гадиләштереп аңлатуыбыз һәм күпләр аны шулай гадиләштереп аңлый һәм кабул итә, шуңа таянып фикер дә йөртә, социологизмны вульгарлаштыра иделәр. Һәм мондый карашлар хаталануларга китерделәр. Татар әдәбияты фәнендә һәм тәнкыйтендә тиздән яңа буын, милли кадрларның милли хаталарын төзәтү өчен Мәскәү вузлары тарафыннан әзерләнгән алдынгы кадрлары да барлыкка килде,

алар, чын галимнәр буларак танылып, алдынгы сафларга чыктылар. Араларында иң танылганы Г. Нигъмәти иде.

1920 нче елларда әдәбият белемендә барлыкка килгән иҗат методы төшенчәсе дә социологизм методологиясе тарафыннан алга чыгарылды. Һәм ул, әүвәле, әдәбият һәм сәнгатьнең үзләренә түгел, бәлки аларны өйрәнүче һәм бәяләүче әдәбият белеме фәненә карый, әдәби күренешләрне анализлауда һәм төркемләүдә төп чараларның берсе иде.

Әдәби иҗат методы төшенчәсе марксистик карашлар нигезендә барлыкка килгән һәм социологизм юлы белән әдәби әсәрләрне анализлауда һәм бәяләүдә иң катлаулы чишелешле мәсьәлә буларак күзаллана башлады. Әсәрнең талантлы яки талантсыз язылуы, мәгънәле яки мәгънәсез булуы әдипнең гүяки иҗтимагый аң үсешендә марксист булуына бәйле, имеш. Иҗат методы, ягъни тормышны чагылдырганда язучының күңел эшчәнлегенең очраклы хисләргә корылмавын ачыклау, әлбәттә, фәнни әһәмияткә ия мәсьәлә. Социологизм вәкилләре исә аны төп, әдәби иҗат принцибы буларак карый, ачыклый, күрсәтә башладылар. Социологизмның әһәмияте «социалистик реализм» төшенчәсе барлыкка килгәч һәм совет әдипләренең бердәнбер иҗат юлы, принцибы дип игълан ителгәч, тагын да актуальләште. Социологизм теориясе белән коралланган галимнәр иҗат методын әсәрдә төп, әдәби әсәрнең асыл эчтәлеген һәм төгәл формасын, аның уңышын-уңышсызлыгын күрсәтүче фактор рәвешендә дә белдерә һәм аңлата башладылар. Социалистик реализм тәнкыйди реализмнан, ә тәнкыйди реализм үзе мәгърифәтчелек реализмыннан үсеп чыккан дип күзаллау һәм раслау аларның фикерләмәләренең асылына әверелде. Социологизм вәкилләре бу фәнни юнәлешне «иҗтимагый-генетик анализ методы» исеме белән атадылар. Прогрессив, киләчәккә төбәлгән романтизмның яңа совет җәмгыяте рухи күтәрешендә роле ачык аңлашылып, социалистик реализмны исә, тормышны үсештә тасвирлаучы метод буларак, романтизм чараларын да ят итмәвен алар күрергә тиеш иделәр. Һәм социологистлар кешелек мәдәниятен сыйнфый эчтәлектә генә күзаллап, шуның нигездә әдәби әсәрләрне бәяләү һәм иҗтимагый үсеш өчен яраклы булганнарын гына сайлап алу ягында тордылар. Мәктәп, вуз программалары, уку-укыту, тәрбия эшләре шушы социологизм вәкилләренең өйрәтмәләренә корылган иде.

Шушы чорда, нәкъ менә 1930 нче елларда әдәбият дөньясына шагыйрь буларак аяк баскан Г. Халит, әдәби тәнкыйтькә һәм фәнни-тикшеренүләргә дә тартылып, социологизм методологиясен иң яхшы үзләштергән, ышанычлы яшь буын вәкиле буларак, тиз арада танылу ала. Аның Г. Ибраһимовны вак буржуаз әдип буларак бәяләве, Дәрдемәндне эре капиталистларның хисләрен җырлаучы буржуаз, декадент шагыйрь дип аңлатулары, социаль-революционерлар

партиясе вәкиле С. Рәмиевне «революцион позицияләрдә тормады» дип раслап язулары һәм башка шушындый фикерләрдән гыйбарәт, эчке мантыйкка, фикерне төгәл белдерүгә корылган, марксистик-ленинчыл аңлы мәкаләләре матбугатта урын ала башлый. Аның өчен романтизм вак буржуаз хис-тойгылар чыганагы сыман күзаллана. Хәер, алгарак китеп әйтсәк, Г. Халитнең социологизмнан читләшә башлавы исә (бу хәл соңрак була) нәкъ менә шушы романтизмның социалистик реализмдагы урынын күреп алуыннан башланып китә дә инде, югыйсә.

Г. Халитнең заманча аңлы, фикерле, белемле һәм, иң кирәге, матур аһәңле, сыгылмалы, әмма катгый һәм мантыйклы тел белән мәкаләләрен язуы күпләрне сокландыра. Ни генә дисәк тә, ул үзен бик яшьли талантлы галим сыйфатында күрсәтә, фәннәрне системалы үзләштерүе аның акыл эшчәнлегенә һәвәслегенә һәм характерына бәйле килгәнлеге язмаларыннан сизелеп тора.

Утызынчы елларның икенче яртысында социологизм методы һәм методологиясе каты тәнкыйтьләнә башлый, аны фәнне, бигрәк тә марксизмны вульгарлаштыруда гаеплиләр, Г. Ибраһимов та, Г. Нигъмәти дә кулга алыналар һәм хөкемгә тартылалар. Бөтен хикмәт – әдәби әсәрләрне иҗтимагый-идеологик-сәяси яктан гына бәяләүдә, югары әхлак принципларын, сәнгатьлелек дәрәҗәсен социологизмның исәпкә алмавыннан килә, югыйсә. Әмма социологизмның вульгарлашуын әдәбиятны сыйнфый позицияләрдән торып кына бәяләүгә кучүеннән дип белделәр. Әгәр дә әдәби әсәр эксплуататор сыйныф вәкиле тарафыннан язылган икән, ул – әхлаксыз, ул – бозык хисләргә корылган, ул – череп баручы хистойгыларны сурәтли, ул романтизм методында иҗат ителгән. Ә менә, мәсәлән, М. Горькийның «Тормыш төбендә» яки башка әсәрләре югары әхлакны матурлык тойгысында тасвир итә, имеш. Чөнки ул әдип – пролетарий сыйныфының хисләрен җырлаучы, социалистик реализмны нигезләүче язучы, тәнкыйди реализмнан үсеп чыккан даһи.

Социологизм методын ныгыткан һәм үстергән, аның методологиясен һәм принципларын эшләгән, социализм төзүчеләрне сыйнфый үзаң белән тәрбияләүдә төп әһәмияткә ия булуын аңлата-төшендерә алган В.М. Фриче әдәбиятны һәм сәнгатьне сыйнфый-иҗтимагый аңның үзенчәлекле-специфик формасы буларак бәяли һәм шушыны төп эстетик закон буларак игълан итә [Курилов, 307 б.]. Язучының тормышын һәм эшчәнлеген аерым сыйныфка бәйле тикшерү дә социологизм методологиясендә төп әһәмияткә ия саналган. Г. Ибраһимов кына түгел, татар әдәбият белеме фәне дә һәрьяктан төгәл принциплар нигезендә, мантыйклы һәм ачык эшләнелгән социологизм теорияләрен 1920 елда ук үзләштерергә өлгереп, аны төп фәнни-тикшеренү юлы буларак алга таба үстерә башлый. Шушы карашларны яхшы үзләштергән Г. Халит исә әхлак һәм әдәбилек мәсьәләләренә бәйле

эзләнүләрен дә мәкаләләрендә сиздереп ала. Шунысы әһәмиятле, ул аларны яңа җәмгыять төзүгә бәйле мәсьәләләр белән берләштерә ала. Әмма аның һәр фикере һәм карашы революцион-сыйнфый идеаллар белән тәмам сугарылган була.

Г. Халитнең шушы чорда, 20–25 яшьләрендә язылган күләмле монографиясе «Мәҗит Гафури иҗаты» дип атала. Ул хезмәте 1941 нче елда Казанда Татгосиздатның укыту-дидактик әдәбият секторы тарафыннан редакцияләнеп, «Мәктәп сериясе»ндә бастырып чыгарыла. Г. Халит үз хезмәтен «критик очерклар» дип атый. Моңа кадәр, 1939 елда, шул ук нәшрият аның «Халык шагыйре Тукай» дип аталган мәкаләләр җыентыгын бастырып чыгарган була.

Хезмәтләрнең икесе дә социологизм методологиясе нигезендә язылганнар. Аларда Г. Тукай да, М. Гафури да демократ революционерлар (революцион-демократлар) буларак бәяләнәләр, иҗатлары да сыйнфый-демократик карашлар кысаларында анализлана. Әмма яшь галим, социологизм принципларыннан үсеп чыга барып, әдипләргә аерым сыйныфларга бәйләп, ярлыклар тагудан котылырга тырышып, әдәбиятны иҗтимагый фикер үсеше юнәлешендә тикшерү юлына баса һәм, социологизм методологиясен файдалануына карамастан, аны, иҗтимагый аңны, катлаулы һәм четерекле мәсьәлә – әдәби-эстетик үзенчәлекләрне өйрәнүгә таба бора. Ачык фикерле, аңлы булуы һәм фәнни-тикшеренү стилендә яза белү осталыгы аны беренче адымнарыннан уңышка китерә. Г. Халит бу хезмәтләрендә мәгърифәтчелекнең һәм халыкны агарту идеалларының татар әдәбиятында ничек барлыкка килүен һәм аларның алга таба, ныгый һәм җәелә барып, азатлык хәрәкәтен тудыруын, аерым алганда, Г. Тукай һәм М. Гафури иҗатлары мисалында конкрет анализлар белән аңлатып, раслап бирә. Шушы рәвешле бу ике бөек әдипнең иҗат мирасы тәмам социальләштерелә һәм идеологик кысаларга кертелә. Г. Халит, яшь галим булуына карамастан, максатчыл фикерләмәләр корып язу манерасына ирешүен М. Гафури иҗатын тикшерүгә багышлаган монографиясендә ачык күрсәтә. Моның өчен ул мантыйклы, фикерләп, ачык мисаллар белән язу стилен корал итә. Аның язганнарына ышанмый мөмкин түгел, алар укучы фикерен үзләренә ияртеп бару көченә ия. Һәм шушы яклары аны фән дөньясына зур галимнең килүе буларак таныталар да. Аннары, Г. Халит, күренеп тора, хезмәт сөючән, һәр мәсьәләне җентекләп өйрәнүне максаты итеп куя белгән. Шунысы кызык, М. Гафуриның әсәрләренә анализ ясаганда, Г. Халит аның кадимче буларак тәрбияләнүен, җәдитчелекнең бер дә кабул итмәвен, битарафлыгын, уку өчен сайлаганда җәдит мәктәпләрен түгел, кадими мәдрәсәләргә керүен бөтенләй дә искәртми. Чөнки фәнни карашлары хаталы булачагын ул аңлап эш итә. Менә шуңа күрә дә «Мәҗит Гафури иҗаты» монографиясенең беренче бүлеге

беренче параграфы «Мәҗит Гафури – мәгърифәтче» дип атала да. Җәдитчелек, әлбәттә инде, татар буржуазиясенең идеологиясе буларак күрсәтелә.

XX йөз башы әдәбият үсешен Г. Халит Россиянең эчке шартлары белән бәйли һәм иҗтимагый үзаң үзгәреше белән характерлый. Асылы социологизмга корылса да, юнәлешендә революцион-демократик идеалларны барлаудан гыйбарәт булуы сәбәпле, галимнең хезмәтләре җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап кабул ителә. Алга таба Г. Халит XX йөз башы татар әдәбиятының үсешен мәгърифәтчелектән тәнкыйди реализмга күчеш буларак аңлату юнәлешендә фәнни тикшеренүләрен алып бара башлый. «Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре» (1948) хезмәте шул фикерләрен раслау юнәлешендә языла. Иҗат методы төшенчәсе әдәбият фәненә социологизм вәкилләре тарафыннан кертелгән булуын да исәпкә алсак, Г. Халитнең тәнкыйди реализмны революцион-демократик фикер үсеше белән бәйләп аңлатуы социологизм теориясеннән берникадәр азат булуын да күрсәтә, ягъни ул әдәбиятны сыйнфый яссылыкта караудан читләшә. Әмма бу очракта да әдәбият иҗтимагый аңның бер өлкәсе буларак бәяләнә, югыйсә. Мантыйклы фикерли белүе, әдәби-тарихи материалны максатлы файдалану осталыгы, иҗтимагый-сәяси яктан аңлылыгы Г. Халиткә хезмәтләрендә социологизм карашларын саклап калу һәм үстерү мөмкинлекләрен бирде.

1950–1960 нчы елларга татар әдәбияты тарихы фәне тулысынча Г. Халитнең карашларына нигезләнеп үсте һәм үстерелде. Шул елларда фәнгә килгән И.З. Нуруллин да, башка галимнәр дә аның фикерләре тәэсирендә формалаштылар. Шулай итеп, татар әдәбияты белеме фәне XX гасырның 40 нчы елларыннан Г. Халит тоткан юнәлеш белән үсте һәм, әдәбиятның әдәби үзенчәлекләрен түгел, бәлки татар иҗтимагый фикере үсешен өйрәнүче өлкәгә әверелде.

1950 нче елларның икенче яртысында әдәби мирасыбызны кайтару юнәлешендә зур эшләр башланып китә. 1920 нче елларда әдәбият тарихыбызны системалаштыру юнәлешендә хезмәтләр басылса да, алар ничек фәнни фикер үсешеннән өзеп-өзелеп калдырылсалар, инде хәзер бу эшнең яңара баруы, әмма тарихи барышның дәресләре тирән яралар калдыруы сәбәпле, галимнәрне шактый саклык белән эш итәргә этәрде. Социологистлар тарафыннан буржуаз фикер иясе буларак бәяләнгән һәм декадент дип белдерелгән Дәрдемәнд иҗаты да кайтты, башкаларныкы да. Г. Халит шушы чорда «реализм һәм романтизм синтезы» мәсьәләсен өйрәнүгә кереште һәм XX йөз башы татар әдәбиятына бәйле шул «синтез» теориясен эшләде. Бу исә татар әдәбият белеме фәненең социологизмнан ерагая баруы һәм әдәбиятның үзен өйрәнүгә күчүе хакында да сөйли иде. Менә шул чорда Г. Халит әдәби-эстетик анализның фәлсәфи чикләре киң, эчтәлеге шактый тирән икәнлеген аңлап

алды. Менә шуңа күрә дә ул 1959 нчы елда В.М. Фриче методының хаталы икәнлеген атап белдереп язып чыкты [Халит, 260–280 б.], Г. Нигъмәтинең романтизм теориясендә гыйльми хаталар булуын, романтизмның прогрессив юнәлешен яклап язды [Халит, шунда ук], хәтта иҗат методын кире кагу мәсьәләсенә дә якынайды һәм аны талисман итмәскә чакырды [Халит, 281–300 б.]. Шушы язмалары белән Г. Халит үзен сүздә һәм фикердә социологизмнан тәмам аерылган, котылган галим сыйфатында күрсәтте. Әмма безнең татар әдәбияты белеме татар иҗтимагый фикере үсешен өйрәнүче өлкәгә әверелеп беткән, асылы белән социологизм принципларына корылган иде инде. Бу бигрәк тә XX йөз башы татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә бәйле шулай булды. Әдәбият теориясе дә социаль-генетик өйрәтмәләргә корылган иде. Бер методны әдәби тарихи үсештә икенчесе алыштырып килүе, язучыларның иҗат методы эчендә төркемләнүе, бер төрле иҗат методы белән язуларынраслаулар – болар барысы да социологизмнан килә иделәр. Әдипләрне вак буржуаз, буржуаз, пролетарий һәм башка шундый сыйнфый классификацияләр ярдәмендә төркемләү һәм бәяләүләр онытылып бетмәгән кебек, иҗат методларына бәйле билгеләүләр дә табигый хәл кебек аңлашыла иде. Г. Халитнең реализм һәм романтизм синтезы теориясе татар әдәбиятында модернизм-декадентлык хакында сүз алып бармау өчен дә яраклы иде. Җитмәсә, XX йөз башы татар әдәбиятын шул теория нигезендә аңлату татар әдәбияты фәненең алдынгы өлкәсенә әверелде. М.Х. Хәсәнов шушы теория белән бәйләнештә хезмәтләр язып, тиздән зур галим буларак танылды. Татар әдәбиятының барча модернистик хәрәкәтләре һәм үсеш юнәлешләре реализм һәм романтизм синтезы теориясе белән алыштырылды һәм һәртөрле әдәби-эстетик мәсьәләләрне чишү һәм аңлату өчен универсаль формулага әверелде. Бу синтез, әлбәттә, зур ачыш иде. Барча теоретик карашлар шушы синтез нигезендә корыла башладылар.

XX йөз башы татар әдәбияты үсеше тарихы ул чорда җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә тартып тора иде. Моның сәбәбе билгеләп үтелә торган юбилейларга бәйле булды. Г. Тукай, Г. Ибраһимов һ.б. XX йөз башы әдипләре иҗат мирасын пропагандалауга багышланган фәнни конференцияләр елдан-елга активрак рәвештә, киңрәк даирәләрдә оештырыла торды. Фикерләр ешрак туды. Фактлар төгәлрәк барлана башладылар. Бу эшкә коммунистларның җитәкче органнары һәм шәхесләре тартылды. Шулай килеп, 1980 нче елларда XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүгә бәйле «тизләтелгән үсеш» теориясе тудырылды. Чөнки татар әдәбияты XX йөздә бер дистә ел эчендә мәгърифәтчелектән социалистик реализмга кадәр үсеш юлы узды, арада символизм, тәнкыйди реализм, экспрессионизм һ.б. иҗат методлары чорлары бар иде, әдипләр бер иҗат методыннан икенчесенә күчә барды, диделәр, Европада бу әдәби иҗат

юлын ике йөз ел буена кичтеләр, диделәр. Димәк, татар әдәбияты тарихына бәйле караганда, XX йөз башы тизләтелгән үсеш чоры булган икән.

Г. Халит шушы юнәлештә фикерле башлап, бу теориягә бәйле мәкаләләрен дә әзерләргә кереште. Бу теория әлеге дә шул ук социологизмнан котылып җитмәүдән килә иде. Бер иҗтимагый формацияне икенчесе алыштырып баруын марксизм-ленинизм аңлаткан кебек, бер иҗат методына икенчесе алмашка килүен, шулай әдәбиятның үсеше күзәтелүен социологистлар үз чорларында раслаган иделәр. Татар әдәбият теориясе исә һаман шул караштa торды. Галимнәр бер чор әдипләренең төрлетөрле методларда иҗат итәргә хаклары барлыгын танымадылар, язучылык эше – күңел эше, ә күңел эшенең талантка бәйле икәнлеген аңлый һәм аңлата алмадылар. Шул сәбәпле, икенчел, өченчел законнарны алар беренчел итеп алга чыгардылар. Әдәби әсәрнең әдәбилеген ачканда һәм аңлатканда, метод һәм алым мәсьәләренә тукталулар анализ нәтиҗәсе генә була ала, югыйсә.

Мисалга XX йөз башы татар әдәбиятын гына алып карасак та, иҗат алымнары, юллары, методлары ягыннан чыннан да чуар чор ул. Бу төрлелекне Г. Халит бер тәртипкә кертергә теләде. Әдәбиятның «тизләтелгән үсеше» рус һәм европа әдәбиятларына бәйләнешнең, рухи-мәдәни интеграциянең көчәя баруы белән аңлатылды. Ә хикмәт татар халкында мәгариф эшенең үсешенә, халыкта грамоталык артуга, әдәби талантларга мәйдан алу мөмкинлеге барлыкка килүгә бәйле иде, югыйсә. Дөрес, ул талантлар мәйданга чыккан һәм тарихи үсештә онытылган да иделәр. Әмма галимнәр аларны өйрәнә башлады, әсәрләрен бәяләү, тикшерү мөмкинлекләре туды. Шулай да Г. Исхакый, Й. Акчура, И. Гаспринский, С. Максуди, Г. Баруди кебек үз чорларында киң танылган әдипләрнең иҗат мирасын өйрәнүдән читтә калдырырга туры килә иде. Алар хакында сүзләр 1980 нче еллар ахырында гына куера башладылар.

Г. Халит аларны тарихка кайтару яклы булмады. Әмма кискен каршы да чыкмады. Бу елларда татар әдәбият белемендә аның теорияләре һәммә әдәби күренешне ачыклый һәм аңлата алырлык, системалы иде. Яңа заманны да ул «татар әдәбиятында тизләтелгән үсеш» теориясе белән каршы алды һәм аңа бәйле фикерләре сәяси хәрәкәтләр белән уртак яңгыраштa кебек иделәр.

Г. Халит үзенең теоретик карашларын 1985 нче елда Казанда рус телендә чыккан «Портреты и проблемы» һәм 1990 нчы елда басылган «Многоликая лирика» китапларында туплап бирде. Алар аның гыйлем дөньясын бар тулылыгы белән диярлек ачып бирәләр.

Г. Халит социологизмнан әдәби-эстетик фикерләүгә таба катлаулы юл үтте. Әмма, әдәби әсәрләрне бәяләгәндә, иҗтимагый-генетик метод һәм методологиянең фикерләрен һичбер вакытта да читкә куймады. Алар аның күңеленә яшьли салынган

орлыклар гына түгел, гыйлем дөньясы да иделәр. Әдәбият барышын һаман да иҗтимагый фикер үсеше кысаларында, аның белән тыгыз бәйләнештә каравы аны какшамас материалист итеп тә күрсәтә иде. Ул гыйльми юнәлешеннән һәм фикерләреннән баш тартмыйча, аларны үстерә дә белде.

Татар әдәбияты тарихын бүгенге көндә дә Г. Халитчә аңлату яшәп килә. Чөнки фәнни теорияләрнең нигезенә аның карашлары салынган. Әдәбият-сәнгатьнең үз үсеш закончалыклары бар, югыйсә. Талант иҗтимагый формациягә, сыйныфка һәм хәтта биографиясенә бәйсез рәвештә туа. Әмма аның ачылуына, үсешенә, күренә башлавына, фикерләренә җәмгыять, әйләнә-тирәсе, тормышы тәэсир итми калмыйлар, әлбәттә.

**Әдәбият**

*Курилов А.С.* Социально-генетическое литературоведение // Русская наука о литературе конца XIX – начала XX века. М.: Наука, 1982.

*Халит Г.* Портреты и проблемы: Избранные статьи разных лет. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985.

***Яхин Фәрит Зәкиҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*e-mail: yafaz@mail.ru*

*Хәсәнгата Габәши*

# ТӘРҖЕМӘИ ХАЛЕМНӘН, ГЫЙЛЬМИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ ХЕЗМӘТЛӘРЕМНӘН БЕРКАДӘРЕСЕ*

## 1895–1915 сәнә

Мәхкәмәи шәргыябездә казый мөхтәрәм Хәсәнгата әл-Габәши хәзрәтләре! Казан арты кебек мөтәгассыйб[1] бер урында хезмәт итә башлавыгызга бу ел гыйнвар аенда 25 ел тулып үтте. Ул тарафта һичбер авылда ысулы җәдид мәктәбе булмаганы хәлдә, төрле манигъларга[2] күкрәк киереп, шундый бер тәгассыб[3] учагында башлап шул җәдид мәктәбе ачтыгыз. Авыл вә әтрафыгызны яктылык, мәдәният вә иҗтимагый хәяткә җитәкләүдә иҗтиһадыгызны сарыф иттегез. Иҗтиһадыгыз бер Казан артына гына мөнхәсыйр[4] булып калмаенча, мөселман мәркәзе булган Уфага килүегез белән гыйльми вә иҗтимагый хезмәтегез Русия мөселманнарына тагын киңрәк җәелде. 1895 нче елда мәхкәмәи шәргыягә казый булып килгәнегездән соң бу фазыйфаңызда мөхитъ[5] мөсагадә[6] иткән кадәр хезмәт иттеңез. Казыйлык вазыйфасы өстенә гыйльми хезмәтләр дә булынып, иң мөкатдәс булган тарихе миллиябез өчен мөһим материаллар хәзерләдегез. Һәм төрк кавемнәренә гаид[7] булган мөһим әсәрегезне мәйданга куярга муаффыйк[8] булдыгыз.

Икенче мәртәбә казый булып килүегез дә сездән Уфа мөселманнары дәхи артыграк истифадә[9] иттеләр. Һәрвакыт җәмгыяте хәйрия мәҗлесләрендә ак вә изге юллар күрсәттегез. Зәкят сандыклары тәэсис[10] итү хакында мөһим булган фикерләрегезне җәмгыятьтә ашкярә[11] сөйләдегез. Милли хәятебез өчен бик мөһим булган әдәбият вә музыкабызга кылынган һөҗүмнәргә каршы мөдафәгада[12] булындыгыз. Һәм шуның мөбах[13] бер эш икәнен гамәлегез белән күрсәттегез. Җәмәгатькә гаид нинди генә эш булса да, армый-талмый шул изге эшләрнең эчендә булып, хезмәт итә килдегез. Рус зыялылары вә җәмәгать хадимнәре тарафыннан җәмгыятьләрдә әгъза булып, шулардан Уфа мөселманнарының

---

* Башы 2 нче санда.

[1] Мөтәгассыйб – фанатик.

[2] Манигъ – тыючы, киртә.

[3] Тәгассыб – артык омтылу.

[4] Мөнхәсыйр – камалган, чиге билгеле булган.

[5] Мөхитъ – әйләнә-тирә.

[6] Мөсагадә – булышу, ярдәм итү.

[7] Гаид – бәйләнеше булган.

[8] Муаффыйк – туры килгән, яраклы.

[9] Истифадә – файдалану.

[10] Тәэсис – оештыру.

[11] Ашкярә – ачыктан-ачык.

[12] Мөдафәга – каршылык күрсәтү.

[13] Мөбах – эшләсәң гөнаһ та, савап та булмый торган эш.

истифада итүләренә васитачы[1] булдыгыз.

Хәзер без шул гали хезмәтләрегездән аерылуыбызга тәәссеф[2] итәбез. Уфадан китүегез мөнәсәбәте белән мәзкүр хезмәтләрегезне дәхи бер кат искә төшереп, хатирә өчен бер кечек һәдия белән шушы адресны тәкъдим итәбез. Моннан (ары да) соң да сезнең армый-талмый милләтебезгә хезмәт итүегезне өмет белә юанып калабыз. (адрес тәмам).

Кечек һәдия дигәннәре – берүзе зиннәтләр белән катнаштырылып кызыл агачтан ясалган кыйммәтле башенный буе бик суга торган зур гына өстәл сәгате. Бронза тактага: 1895–1915 казый Хәсәнгата хәзрәт Габәшигә Уфа мөселманнарыннан ядкарь, дип язып, түбән кырына беркетелгән. Бу ядкарь сәгать 12 елдан бирле язу өстәлемдә минем каршымда утыра. Күтәрелеп караган саен өстендәге язуына күз төшә дә, «ядкарь»гә сәбәпләрне вә ядкарь бирүчеләрне ядка төшерә. Моңлы, озын тавышы белән сугып, адресның ахыргы җөмләсен: «Моннан соң да сезнең армый-талмый милләтебезгә хезмәт итүегезне өмет илә юатып калабыз» җөмләсен хәтергә төшерә. Һәм шулай армый-талмый хезмәт итәргә тәшвикъ[3] итә, дәрт кузгата.

Бу адреска Уфаның, шул вакытта Уфада булган (чөнки вакыт җәй көне, күп кеше Уфадан таралган иде) зыялылардан, галимнәрдән, сәнәгать хезмәтчеләреннән, гыйлемгә дус кешеләрдән 33 кеше имза кылган.

Петроград, Мәскәү, Уфа, Казан съездларында мине тәшкилят, күбрәк мәгариф комиссияләренә, президиумнарына сайлап киләделәр. Мәскәүдә инкыйлабтан соң, берничә Бөтенрусиядән вәкилләр һәм голямалар җыелган зур съезд мине президиумга голямадан вәкил итеп сайлаганнар иде. Шул съездга рәис итеп сайланган кавказ юристы Әхмәдбай Салихов миннән президиум мәҗлесендә бер мөшкил мәсьәлә хакында фикер сорап, хәл кылганым өчен, бик мәмнүн булганын Фатыйх Кәрими вә башкаларга сөйләгән иде. Бу да яшерен калмасын, Уфада милләт мәҗлесендә вәкилләр, төрекчеләр вә туфракчылар исемендә ике фракциягә бүленгәннәр иде. Мин башта битараф калырга уйласам да, ләкин Галимҗан иптәш Ибраһимов сәбәпчелеге белән һәм электән дә үз фикерем шул тарафта булганлыктан, туфракчылар фракциясенә кушылдым. Милләт мәҗлесендә туфракчылыкны яклар өчен билгеләнгән хатибларның[4] берсе мин идем. Озак тартыштан соң, төрекчеләрнең күп булуларына карамастан, мәҗлесне үз фикеребезгә канагать иттерә вә карар бирдерә алдык. Шул вакыт алынган рәсемнән күренүенә күрә, безнең туфракчылар фракциясендә

[1] Васитачы – арадаш.
[2] Тәәссеф – кайгыга төшү, кайгыру.
[3] Тәшвикъ – кызыксындыру, өндәү.
[4] Хатиб – вәгазь сөйләүче, оратор.

булганнар барысы да диярлек бу көндә дә гыйлемгә вә халыкка һәм мәмләкәтебезнең рәваж[1] вә тәрәккыйенә хезмәт итәләр.

Шушы урында Уфадагы хезмәтләремне туктатып торып, Казанга, авылыма кайтканнан соңларыны, гәрчә мөхарәҗә вә инкыйлаб[2] вә тәшвиш[3] вакытлары булганлыктан, күп булмасалар да, үз фикеремчә әһәмиятлеләрен язам. Аннан соң тәэлифләремне[4] бәянга керешеп, соңыннан тәрҗемәи халь ахырында янә беркадәр хезмәтләремне язармын.

**Казанга кайткач төрле комитетларга, съездларга, земствога һәм думага сайлаулары.**

Казанга – авылыма кайтканнан соң волосларда нинди генә җәмәгать хезмәте булмасын, мәсәлән: тынычлыкны саклау, мәҗрухларга вә гаскәриләр гаиләләренә ярдәм, мәгариф эшләре комитетларына, өяз земствасына, Г. думага кандидатлыкка, голяма съездына, Мәскәүдәге зур җыелышка, Казандагы вә Уфадагы милләт мәҗлесләренә, милли идарәнең мәгариф бүлегенә вә күп җыелышларда рәислеккә вә президиум әгъзалыгына вә төрле фракция, комиссияләргә халык мине сайлыйлар иде. Алдымда да сайлыйлар, шаять гаммә хезмәтеннән баш тартмас дип артымда да сайлыйлар. Мөселманнары да сайлый вә руслары да сайлыйлар. Ләкин, табигый, зря сайламыйлар, бәлки үзараларындагыдан артыграк, җитдирәк хезмәт көтеп сайлыйлар. Мин дә гаммә халыкның миңа бу кадәр хөсне тәвәҗҗеһне[5] игътибарсыз калдырмадым. Һәм электәге гадәтемчә, көткәннәрне бушка чыгармаска тырыша идем. Мин боларның тәфсиленә[6] керешә тормыйм, фәкать ядкәр өчен берсен генә язам: 1917 нче елда 13 нче апрельдә 1105 нче рәкымлы[7] «Кояш» гәзитәсеннән күчерәм: «Дәгъвәтнамә[8] Суыксу вә Алат волосларында тәшкил ителгән «Тынычлык һәм халык ихтияҗын саклый торган комитет» әгъзаларыннан булган берләшкән редакционный комитет, Казан өязендәге имам, мөгаллим, учитель вә башка аңлы кешеләрне Суыксу волосной правлениесенә 23 нче апрель якшәнбе көн сәгать 11 дәге «Милли сәяси-иктисади комитет» тәэсис итү мәҗлесенә дәгъвәт итәдер. Мәҗлестә өяздәге авыллар өчен хәзерге вакытта иң мөһим мәсьәләләр каралачак булганлыктан, һәркемнең килүе мәтлубтыр[9]. Ошбу дәгъвәтнамә бөтен Казан өязендәге имам, мөгаллим, учитель вә аңлы кешеләргә таратылды.

Редакционный комитет рәисе: Хәсәнгата Габәши, әгъзалар:

---

[1] Рәваҗ – таралу

[2] инкыйлаб – асты өскә килү, революция.

[3] Тәшвиш – каршылыклы булу, буталдыру.

[4] Тәэлиф – китап (әсәр) язу.

[5] Хөсне тәвәҗҗеһ – яхшы караш.

[6] Тәфсил – җентекләү.

[7] Рәкым – цифр, сан.

[8] Дәгъвәтнамә – чакыру кәгазе (билеты).

[9] Мәтлуб – теләнгән, соралган.

Зиятдин Хуҗаши, Гатаулла Хәмиди, Хәсән Мәнаши, учитель Сәидвафа.

Бу комитет әгъзалары миннән башкалары барысы да вафат. Бичараларны ядка[1] алучы бармыдыр, юкмыдыр, белмим. Әмма миннән бер искә төшерү булсын өчен тәрҗемәи халемә яздым. Каберләрегездә тыныч ятыгыз рәфикълар[2]! Бу мәхүмнәр дә мине артымда сайлаганнар иде.

Фәкать әһәмияте зур булганга күрә, бер-ике юл белә бу вакыйганы да язаем. Казан өязендәге думага, сайлаучы ителенеп, ике урын бирелгән иде. Халыкның санына нисбәтән, алар икесе дә татарлардан үтәчәк иде. Шуны сизеп, ул вакытның губернаторы берсе рустан сайлануны шарт итте. Шул сәбәптән, без ике урынга сайланачак кандидатлар бер урын белән калдык. Мәсьәлә нәкъ Уфадагыча булды. Халык, сайлаучылар бөтенләй диярлек әллә нинди тәэсирле сораулар белән минем сайлануымны сорасалар да, мин имтинагы[3] итеп миңа күрә күбрәк хезмәте өчетле булган берәүне үз урыныма дәляләт[4] итеп сайлаттым.

**Икенче баскыч совет мәктәбе укытучылыгына тәгайен[5], мөдирлегенә дә тасдыйк[6] ителүем:** инкыйлабтан соң арча кантоны халыклыры руслар вә татарлар өчен советлар хөкүмәте берәр икенче баскыч мәктәп ачарга карар бирде. Минем уку-укыту эшендә байтак тәҗрибәм һәм багажым булганлыгы Арча кантон мәгариф шөгъбәсенә мәгълүм булганлыктан, татар-мөселманнар өчен булачагын үз йортымда ачуны һәм шунда мөгаллимлек тә, мөдирлек тә итүне миннән сорады. Һәм: «Закон истиснасыз[7] булмый», дигән кагыйдәгә бина кылып, ул вакытта кантон мәгариф мөдире булган Сабирҗан иптәш Шульский минем нинди ләвазимда[8] булуыма карамыйча һәм аларны ташлауны миннән сорамыйча ук, мине шул 2 нче баскыч советлар мәктәбенә мөгаллим һәм мөдир итеп тасдыйк итте. Мин дә көтелгән хезмәтне бушка җибәрмәскә тырыштым. Мәктәпнең рәваҗе вә тәрәккыйена көчем кадәре энергия сарыф иттем. Бу мәктәпнең ачылуына укытучылар вә гыйлем әсбабы җитештерүгә (хәтта беркадәресен Мәскәүдән китертеп) шул вакыт Алат волосында инструкторлык иткән Фазылҗан иптәш Хәмидуллинның бик җитди вә бик зур булышлык итүен тәшәккер[9] белән яд итәм. Ләкин Хәмидуллин иптәш инструкторлыгын – хезмәтен ташлап, урынына гайре милләт адәме тәгайен ителеп, аның бу мәктәпкә карашы башкачарак

---

[1] Яд – искә төшерү, телгә алу.
[2] Рәфикъ – иптәш, юлдаш, дус.
[3] Имтинаг – баш тарту, үзеңне тыю.
[4] Дәляләт – димләү, өйрәтеп күрсәтү.
[5] Тәгайен – билгеләү.
[6] Тасдыйк – раслау, дөреслеген тану.
[7] Истисна – чыгарма, исключение.
[8] Ләвазим – хезмәт урыны, дәрәҗәсе.
[9] Тәшәккер – яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.

булу сәбәбеннән, ахыргы елда коллегия таралды. Ярты кыш бер ялгызым алып бардым.

**Самакурсларда һәм экскурсияләрдә:** Алат волосында урыс вә татар укытучылары катыш самакурсларда тарих һәм местный край хакларында миннән дәрес укыталар иде. Хәтта бер вакыт: «анатомия, гыйльме тәшрих[1]»тән урыс һәм татар укытучылары арасында дәрес укыттылар. Һәм бу хосуста миндә башкалардан багажны күп артык күреп, дәресемнән бик мәмнүн[2] булганнарын белдерделәр.

Беренче һәм икенче баскыч мәктәп укучыларын тирә-юньгә экскурсиягә алып йөреп, җирле әтраф халкында аларга күп мәгълүмат бирдем. Алат волосы урыс һәм татар укытучыларыннан катыш бер һәйәт[3], Фазылҗан Хәмидуллин юлбашчылыгы белән Сибириягә, Урал тауларына, Свердловскига һәм Омскига кадәр экскурсиягә бардык. Свердловскийда озак калып мәктәпләр, музаханәләр, көтепханәләрне карау өстенә, анда булган осерваторияне дә карап, аның бөек манарасыннан үзебезгә махсус дәрес укыдык. Свердловскида ул вакытта мәгариф шөгъбәсендә булган Сәмигулла иптәш Салихов һәм аның рафикасы булган Зөһрә ханым безгә бик зур булышлыклар һәм хөрмәтләр иттеләр. Шулай ук Омски шәһәрендә ул вакытта анда мәгариф эшендә булган Мәхмүд иптәш Арысланов та безгә зур ярдәм күрсәтте. Тәфсиленә керешмичә генә моны да әйтеп узыйм: Омскида без, экскурсантлар, бик уңайсыз вә куркынычлы хәлгә төштегебездә, ялгыз минем иҗтиһадым[4] аркасында ул уңайсызлыктан котылдык. Йөргән җирләрнең әхвале тарихисе хакында мин иптәшләргә көчем кадәр мәгълүмат бирә йөрдем.

Яшем зур булуга карамастан, әле үземдә гыйлем дәрте сүнмәгән. Мәдәният вә халыкка хезмәткә дә үземдә куәт кимемәгәнне сизәм. Гыйлем юлында бәгъзе юлдашлар, гыйльми хезмәтләр итәр өчен мәгариф комиссариатына Вятка центрга хезмәт гарыз[5] итәргә тәшвикъ[6] итәләр. Миңа хезмәткә муафыйк өч урын күрсәттеләр:

1 – Педагоглар җәмгыяте.

2 – Татарны өйрәнү җәмгыяте.

3 – Әйләнә-тирәне өйрәнү җәмгыяте.

Педагогиядә минем тәҗрибәләрем бәлки искергәндер. Шулай булса да, кулымдагы материалларым һәм бәгъзе тәҗрибәләрем эшкә ярар, дип уйладым. Әмма татарны вә әйләнә-тирәне өйрәнү хосусларында бу көнгә кадәр матбугат мәйданына чыкмаган бәгъзебер материаллар булганлыктан, аларда хезмәт итәргә үзем дә имкян[7] табамын.

---

[1] Гыйльме тәшрих – тәннең төзелешен тикшерү.
[2] Мәмнүн – разый, шат.
[3] Һәйәт – комиссия, комитет.
[4] Иҗтиһад – тырышлык.
[5] Гарыз – тәкъдим итү.
[6] Тәшвикъ – өндәү, кызыктыру.
[7] Имкян – мөмкинлек.

Инде хәзер китаплар язуым бабына күчәмен.

**Китаплар язу дәверем:** мин мәдрәсәдә вакытымда ук вак-төяк шигырьләр[1], аннан соң китаплар яза башлаган идем. Китап язарга кулга каләм тотмас борын элек безнең төрек-татар халкының, хосусан түбәнге катлавының, ни хосуста нинди китапларга ихтияҗы бар? – шуны тикшердем. Күзгә чалынганнарның иң зурысы – татар массасында балалар тәрбиясенең бик начар булуы, бу хакта һәм хифзыссыйхәт[2] турысында элементарный мәгълүматлар булмавы, бу хосусларда заман вә әхвальгә муафыйк һәм асат аңлаешлы юлбашчы булырлык китапларының да халык арасында юклыгы күренде. Менә мин хезмәте каләмиямне шул юлдан башлап, 1 нче китабым: «Тәрбияле бала» китапчысын яздым. Бу хакта үз тарафымнан сүз озайтмай, ялгыз мәшһүр вә кадерле мөхәррирebез (тиз көннән сәламәтләнсен) Галимҗан иптәш Ибраһимовның «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» исемле 1925 нче елда басылган китабыннан сүз күчерәм. Ул 123 нче биттә болай язган: «1889 нчы елда Казан шәһәрендә «Тәрбияле бала» исемендә басылган бер китап Хәсәнгата мулла Мөхәммәд угылының әсәре. Башыннан аяк шундый садә[3] насирине[4] тәмам рәхәтләндерерлек, үз юлының көчәя башлавын күрерлек саф татарча язылган», дигән дә, күрсәтер өчен аннан шушы өч юл гыйбарәне күчергән: «Тәрбияле бала ашаганда һич ашыкмас. Ашыгып ашап ашҗаулыкның тышына икмәк вә тәгам[5] валчыклары төшермәк бик гаеп. Акрын-акрын гына ашаса, яхшы итеп тамагын туйдырыр һәм бер дә кимчелек кылмаган булыр» (9 нчы биттән алынды), дигән. Икенче күзгә бәрелгән нәрсә, халкыбызның, хосусан түбән катлауның хифзыссыйхәт – гигиена җәһәтләренең бик начар булуы һәм бу хосуска бирәүнең дә игътинаэ[6] кылмаулары күренде. Бу сәбәптән, гомум балаларының, хосусан түбән катлау балаларының бик нәзафәтсез[7], бик шахшы йөрүләре сәбәбеннән, һәртөрле тышкы авыруларга, мәсәлән: күз, колак, авыз, борын, кул вә башка тире авырулары белә җафаланалар. Шулай ук тәрбиясез вә йә зарарлы нәрсәләр ашауларыннан һәртөрле мигъдә[8] вә эчәгеләр авыруларына, салкыннан саклана белүләреннән, хосусан, теш, бугаз, күкрәк авыруларына дучар булалар. Шулай ук йогышлы хасталарны танымаудан вә

[1] Бер шигырь белә язылган мәктүпне күчереп Гали Рәхим иптәшкә биргән идем. Шигырь белә язылганнар байтак бар (автор искәрмәсе).

[2] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.

[3] Садә – гади, катлаусыз.

[4] Насир – чәчмә стильдә язучы.

[5] Тәгам – ашамлык.

[6] Игътинаэ – әһәмият бирү, игътибар итү.

[7] Нәзафәт – арулык, пакьлек.

[8] Мигъдә – ашказаны.

аннан саклана белмәүләреннән шул авылларга мөбтәля[1] булалар. Шушы белмәгән вә сакланмаганлык сәбәбеннән генә никадәрле балалар төрле авырулар белән җафа вә газап чигәләр. Доктор ишекләреннән вә амбулаторияләрдән туктый алмыйлар. Бәлки теге дөньяга китәргә мәҗбүр булалар. Булмаганнары да начар, зәгыйфь адәм булып җитешәләр. Балаларда гына түгел бу хәл, хәттә зурларда да бик күп күренә. Бу сәбәпләрдән үлү (вафат булу) вакыйгасы статистикаларның күрсәтүенә күрә, безнең халыкта, хифзыссыйхәткә игтинаэ кылган башка халыкларга караганда, күп артык була. Бу исә милләтнең кимүе, инкыйразга[2] йөз тоту дигән сүз була. Бу эштә мөтәрәккый[3] милләтләр, хосусан французлар котлары чыгып куркалар. Ә безнең халык ул вакытта моны исәпләп тә карамыйлар иде. Менә мин шуның өчен икенче китапчым булган бик элементарный гына «Сагълык» рисаләчәгемне яздым[4].

Телне шул «Тәрбияле бала»дагы шикелле мөмкин кадәр татарлаштырдым. Исемен шуннан артык садәләштерә алмадым. «Сәламәтлек» дисәм, гарәпчә була. «Саулык» кына дисәм, Казан артында күп җирдә бикәч бәтине «саулык» диләр. Чар вә начар «Сагълык» дидем. Болар фән җәһәтеннән «Тәрбияле бала»дан башка-башка нәрсәләр булсалар да, ләкин икесе ике – туган шикелле булганлыктан, икесен бергә үк бастыруны мәгъкуль күрдем. Шәмсетдин Хөсәенев: «Сатып булыр микән?», – дип бик авырсынып кына алып бастырган иде. Бу да яшерен калмасын, боларның мөндәриҗәләре[5] бик аз, бик ансат нәрсәләр булганлыктан, үз исемемнән генә нәшер итә ала идем. Ләкин ул вакытта язылганнар язучыларына карап кабул ителәләр иде. Әгәр мин үз исемемнән генә мәйданга чыгарсам, кем икәнне белеп, сыналып җитмәгән бер шәкерт әсәренә халык бер дә илтифат итәчәк түгел иде. Шуның өчен ул вакытта «Мөдафәга[6]»лары, «Истишарә[7]»ләре «Яуропада бер җәвәлан[8]» вә башка әсәрләре белә безнең халкыбызның мәхәббәтен вә игътибарын җәлеп иткән мәшһүр төрек мөхәррире Әхмәд Мидхәтнең, шул ук исемдәге әсәрләре белән файдаланып, китапларның мөәллифе[9] итеп аны, үземне тәрҗемәче итеп кенә күрсәткән идем. Бу хосусны бу вакытка кадәр һичкемгә белдергәнем булмаса да, Галимҗан иптәш Өченче китабым вә аны язуымның сәбә-

---

[1] Мөбтәля – дучар булучы.
[2] Инкыйраз – бетү, юкка чыгу.
[3] Мөтәрәккый – алга киткән.
[4] Бу ике әсәр: «Тәрбияле бала» белән «Сагълык»ның матбугатка чыгуына 1929 нчы ел[да] 40 ел тула.
[5] Мөндәриҗә – эчтәлек.
[6] Мөдафәга – үзен саклау, каршылык күрсәтү.
[7] Истишарә – киңәш сорау, киңәш итү.
[8] Җәвәлан – әйләнеп йөреш, хәрәкәт, эш итү.
[9] Мөәллиф – китап язучы.

бе: мин үзем крестьян таифәсе арасында туып үскәнгә күрә, һәм мәдәният җәһәтеннән бик артта калган таифәдә алар булганга күрә, көч җиткән кадәр ярдәмгә килергә иң тиешле таифә итеп аларны күрдем. Һәм дөнья тереклегендә аларның нинди әсәрләргә мохтаҗлыгын тикшердем. Бәгъзе хосусларында ярдәм итәрдәй Насыйринең бәгъзе әсәрләреннән башка һичбер әсәр күрмәдем. Әмма аларның дөнья ихтыяҗлары чиксез-кырсыз иде. Бар мохтаҗлыкларны бетерү бер кешегә, әлбәттә, мөмкин түгел. Әмма кайсыннан башларга? Менә шуннан башларга, минем тәфтишемнән күренүенә бинаән[1] аларга бик зур зарар китергән, бөлгенлеккә төшергән, хәтта зур сугышлар, үтерешләргә кадәр җиткергән нәрсә, аларның иң кадерле вә бөтен тереклекләренә иң кирәкле булган, вершогы да алар каршында кыйммәт булган җир вә аның чикләрен белдерә торган план вә җир үлчәве гыйлемнәрендә бөтенләй хәбәрсезлекләре икәне күренде. Шушы хәбәрсезлекләре аркасында кулларында планнары була торса да, әмма алар үзләре аннан бернәрсә дә аңлый алмаганлыклары сәбәбендә кирәк, крестьян авыллары үзараларында, кирәк помещиклар белән бик зур гаугалар, низаглар[2] кубарганнар. Бу белемсезлекне чишәр өчен алар царизм чиновникларына һәм дәгъва вәкилләренә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булганнар. Алар исә каю як күбрәк ришвәт[3] бирсә, яисә кайсы якта зур помещик булса, шуның файдасына хөкем чыгарып, крестьянның башын катырып, бөлгенлеккә төшереп бетергәннәр. (Безнең үз авылыбызда да шул ук хәл булган. Күрше помещик җирләрне талап алып, үзләрен төрмәгә утырткан.) Крестьяннар үзләре бернәрсә дә аңламагач, үз файдаларына хөкем иттерү өчен ришвәтче хакимнәргә җинаятьче дәгъва вәкилләрен ашата-ашата зур бөлгенлеккә төшеп, хәтта җир вә урманнарны сатканнар. Болай дәгъва ятышмагач, сугышлар, үтерешләргә кадәр җитешкәннәр. Дәгъвалар егермешәр, хәтта алтмышар елга тартылган, һаман да өзелмәгән. Бу хәл күп авылларда, хәтта бәгъзесе бу вакытка кадәр сузыла килә. Менә бу хәлне күргәч, мин аларга бу хосуста аз гына булса да ярдәм булмасмы өмиде белән план вә җир үлчәве хакында булган, өченче китабым булган: «Мәсахәтел әрз[4]» китабын яздым. Бу китап бик элементарный гына, яхшырак аңлансын өчен фән сүзләрен дә бик садә тел белән язып, зарур[5] күргәнлегемнән, беркадәр рәсемнәр дә керттем. Бастырыр өчен ул вакыт Казан китапчыларына гарыз кылсам да, ләкин алар рәсемнәреннән өркеп, клише табылмас, кыйммәт төшәр, сатып булмас,

---

[1] Бинаән – нигезләп, таянып.
[2] Низаг – ызгыш, талаш.
[3] Ришвәт – үз файдасына эшләсен өчен бирәүгә бирелгән акча, бүләк.
[4] Мәсахәтел арз – җирнең киңлеге.
[5] Зарур – тиеш, кирәк.

дип куркып, буш бирсәм дә алмадылар, бастырмадылар. Үземдә аны бастырыр кадәрле куәт юк иде. Гакыйбәт[1] Гаспринский белән бу хосусны сөйләшеп, бастыруны вәгъдә кылганлыктан, аның ун еллык дәвамына тәбрик итеп җибәргән идем. Уд һәм бастыра алмады. Әсәр шунда калды. Кулымда фәкать черновик кына калды. Анысы бу көндә сәламәт.

**4 нче тәэлифем[2] «Бәсыйрәт[3]»не[4]** язуга сәбәптән шулай ук халкыбызның дөнья тереклеге хосусында артка калулары гына түгел, бәлки бик тизлек белән кирегә китүләрен күрү иде. Гыйлем-мәгърифәт бабында дингә кирәкле беркадәр нәрсәләр булса да, әмма дөнья тереклегенә кирәкле гыйлем-мәгърифәт халкыбыз арасында (Насыйри вә Мәрҗанинең бәгъзе әсәрләренә истисна[5]) һич юк иде. Моны кирәксенгән кешеләр дә бик аз иде. Араларында дөнья гыйльме укыган Гали Мәхмүдиләр, Хәлфиннар, Бикчуриннар, Терегуловлар, Әхмәревлар һәм б. шикелле бик аз гына кешеләр булса да, элек алар бик сирәк иде. Икенче: алар масса арасыннан, түбән катлаудан чыккан кешеләр түгел иделәр. Шуңар бинаән масса әхвале белән якыннан таныш түгел, һөнәр вә сәнаигы гаммәи халык, хосусан түбән катлау халык өчен зарур иде, әлбәттә. Халкыбызның күбрәге, сатучылар булсалар да, ләкин белемсез-мәгарифсез булганнарына күрә, башка милләт сәүдәгәрләре белән ярышта һаман җиңелә, түбән төшәләр, толчок сәүдәгәрләренә, су сатучылар гына булып калып баралар иде. Бу безнең халкыбыз элеккеге заманнарда Яуропа белән Азия урталыгында утырып, бер яктан: Грек, Гарәп, Фарсы, Һинд, Кытай; икенче яктан: Фин, Славян, Тефтоннар белән Скандинавияга кадәр сәүдә кылган. «Кама болгарлары»ның «татар» исемен алган балалары була торып, бу хәлгә калуларны күрү, әлбәттә, бик аяныч иде. (Тарих белән әшнә булмаганнары сәбәбеннән, үзләренең бу хәлдән шөгурләре[6] булмаса да) шулай ук һөнәр вә сәнагать бабларында да көн-би-көн артка тәгәриләр иде. Казанның үзендә һәм әйләнә-тирәсендә никадәр нанки, катат шикелле материя эшли торган фабрикалары; шәм, сабын, күн һәм б. эшли торган заводлары булып, Мәскәү вә башка шәһәрләргә мал җибәрүче Казан халкының бу көндә адәм рәтле бер завод-фабрикалары калмаган, барысы диярлек харап булганнар иде. Казанда кәләпүш, читек, кәвеш; өязләрендә җита сугу, чабата ясаудан башка һөнәрләре калмаган иде. «Тәдбир[7]» – эшнең ахырын уйлау дигән нәрсә, һәр

---

[1] Гакыйбәт – эшнең соңы, нәтиҗәсе.

[2] Тәэлиф – җыйнау, төзү.

[3] Бәсыйрәт – аң, аңлылык.

[4] Ихтира: бу битне бер бала сызгалап пычраткан, бозылган түгел. Шуңар күрә гыйбарәләр куәтендә (автор искәрмәсе).

[5] Истисна – чыгарма, чыгарып алу, аерып алу.

[6] Шөгур – аңлау, төшенү сәләте.

[7] Тәдбир – эшнең ахырын уйлап эшләү, алдан күрү.

эшне тәкъдиргә тапшырылганлыктан, байтактан бирле булмавы аркасында, дөньяны шаулаткан болгар-татарларның балалары бик күпне югалтканнарны яза торырга да хаҗәт юк. Менә мин шул хәлләрне тарихлар васитасы һәм үз күзем белән күреп, гаять ачынганга күрә, шушы үз халкыбызның тәрәкъкый итүенә, һич булмаса тагы да тәдәнни[1] итмәүләренә лязим[2] вә, әлбәттә, минһү булган гыйлем, мәгърифәт, һөнәр, сәнагать. тәдбир хакында шул «Бәсыйрәт» китабымны язып, 1889 нчы елда бастырдым[3]. Бу китабымда ислам галәмендә гарәпләр, төрекләрнең гыйлем-мәгърифәт бабында биш шәһәрләрендә университетлары булыр кадәр мәдәнияттә алга китүләре, дөнья гыйлемләрендә Яуропага остаз булыр кадәр җитешлекләрен, Ибн Синаларның, Фарабиларның, Разиларның, һ.б. әсәрләре Яуропа университетларында йөзәр елга кадәр укылдыкларын Белларменев кебек урыс вә Лабуз кебек француз галимләреннән сүзләр күчердем. Бу әсәр заманында күп булмаган дөнья гыйлемләренең әһәмиятен вә аларның безнең өчен зарурлыкларын белгән гыйлем әһелләре арасында шөһрәт казанган, ислам галәмендә ялгыз матбугат булган «Тәрҗеман» гәзитәсендә 31 нче биттән беркадәр сүзләр күчереп гүзәл тәкъриз[4] язган, Риза казый, Фатих Кәрими вә башкалар тарафыннан тәбрикләр алынган иде. «Бәсыйрәт» хакында атаклы язучыларыбыздан Гали Рәхим иптәш утыз ф. бирә алыр.

**5 нче тәэлифем «Хөласател-бәян[5]»** китабы Казанда бастырылган иде. Бу китап нәзым[6] белә язылып, кырыена шәҗәрә дә ясалган иде. Ахырына гыйлем-мәгрифәткә дәгъвәт итеп гүзәл хатимә[7] дә тоташтырылган иде. Кулымда бер нөсхәсе дә калмаган. Кайсы елны басылганын да яхшы хәтерләмим.

**6 нчы тәэлифем «Нур әл-хакыйкать».** Бу китап Казан миссионерларыннан берсенең исеме язылмаган бер галим мулла белән моназарә[8] кылган имеш тә, аны мөлзәм[9] иткән имеш кебек күрсәтеп, чукынчык урыс Гәрәй белән язган бер китапка, тугрысы христианнаштыру васитасы белән руслаштыру сәясәте белән язылган әсәргә рәддия[10] итеп язылган иде. Казанда һәм өяздә күп галимләр кулдан кулга йөртеп, аларның, шул җөмләдән Мәрҗанинең дә, тәхсинен[11] казанган иде. Бастырылыр өчен

---

[1] Тәдәнни – түбән төшү, артта калу.

[2] Лязим – тиеш, кирәк.

[3] Бу «Бәсыйрәт» китабының да матбугат мәйданына чыгуына 1929 нчы ел[да] 40 ел тула (автор искәрмәсе).

[4] Тәкъриз – язылган әсәр һәм хезмәткә мактап бәя бирү.

[5] Хөласател-бәян – озын сүзнең кыскасы.

[6] Нәзым – рифмалаштырылган сүзләр, шигырь.

[7] Хатимә – азак, ахыр, эпилог.

[8] Моназарә – сүз көрәштерү, бәхәсләшү.

[9] Мөлзәм – бәхәсләшеп җиңгән.

[10] Рәддия – кире кагу, юкка чыгару, дөрес түгеллеген күрсәтү.

[11] Тәхсин – мактап яхшы дип әйтү.

рөхсәт алырга Петербургка җибәрелгән иде. Рөхсәт бирмәү генә түгел, бәлки цензор Смирнов асыл нөсхәсен дә кайтармый алып калды. Бу китапны язуга мәрхүм Габдерахман Ильясов та булышлык иткән иде[1].

**7 нче тәэлифем «Тәрҗемә әр-рисалә әл-махика[2] ли-әүвәл мохтәсар[3] әл-викая[4]».** Бу исеменнән үк мәгълүм булганга күрә, гәрчә русчадан тәрҗемә булса да, ләкин анда тәрҗемәдә миңа бик күп мәшәкать күрергә тугры килгәнлектән, эчендә минем тарафтан байтак кына шәрехләр[5] язылып, ахырына әһәмиятле тәгъликълар[6] илхак[7] ителдекеннән, мин аны тәэлифем дип атадым. Бу китап асылда мәшһүр Мөхәмммәтгали әд-Дирбәндинең Петербур университетында рус студентларына восточный факультетта укытыр өчен урысча тәэлиф иткәне фикъһе һәм ысулы фикъһе тарихы иде. Моны тәрҗемә вә тәэлифкә сәбәп шул булды. Бу фәннәр голүме исламияда зур урын тоталар. Мөселман галиме булу өчен болар белән таныш булу зарур иде. Шул сәбәптән аларны яхшы ихата кылу өчен мөселман шәкертләренә күп кенә китаплар, мәтеннәр[8], шәрехләр, хашияләр[9] укырга вә бик күп гомер уздырырга тиешле буладыр иде. Мәсәлән, ислам дөньясында иске заманнарда фикъһе вә ысулы фикъһе фәннәре ничек оеша башлаган, фәкыйһлар[10] вә мәзһәбләр[11] тәэсис[12] иткән, мөҗтәһидларның[13] тактикалары, тәрҗемәи хальләре, хокук вә шаннар[14] беленми кала иде. Менә дарелфөнүн[15] күргән эш башындагы бер адәм, баягы шәкертләр хаина[16] ачынып, үзенең никадәр теләсә дә, ләвазимы[17] ягыннан фикъһе һәм шул фикъһе фәннәре белә таныш булу лязим булса да, ләкин ул алар белән ашналашып[18] җитә алмаганга борчылып йөргәндә, Петроградта хөкүмәт көтепханәсендә, шул Казимбәкнең русча рисаләсе күзенә чагылган. Ул аның бик кирәксенгән нәрсәсе булганга күрә, ул аны йотардай

---

[1] Габдрахман Ильясовның тәрҗемәи хәле хакында беркадәр мәгълүмат белә кулъязмаларны Гали Рәхим иптәшкә бирәм (автор искәрмәсе).

[2] Махика – ватучы, җимерүче.

[3] Мохтәсар – кыска, кыскача.

[4] Викая – саклау, яклау.

[5] Шәрех – аңлатма, төшендерү.

[6] Тәгъликъ – аңлату.

[7] Илхак – кушу, тоташтыру.

[8] Мәтен – китапның, әсәрнең төп тексты.

[9] Хашия – бер китапның эчтәлеген ачыклаучы икенче бер китап, әсәр.

[10] Фәкыйһ – шәригать законнарын яхшы белүче.

[11] Мәзһәб – гыйлем, фәлсәфәдә, дөньяга караш тоткан юл.

[12] Тәэсис – төзү, оештыру.

[13] Мөҗтәһид – дин китаплары буенча яңа хөкемнәр чыгаручы.

[14] Шан – дәрәҗә, әһәмият.

[15] Дарелфөнүн – югары уку йорты, университет.

[16] Хаина – хыянәтче, сатлык җан.

[17] Ләвазим – тиешле булган нәрсәләр, кирәкле эшләр.

[18] Ашна – таныш, әшнә, дус.

булып укыган. Аннан фикъһе һәм ысулы фикъһенең нидән гыйбарәт икәнен тәмам аңлаган. Бу китап татар шәкертләренә, әллә ничә китап укып та ала алмаган тулы мәгълүматны бирә алачак дип бик нык ошаткан. Ләкин теле русча булганлыктан, татар шәкертләренә аңланачак булмаганга күрә, аны бер учреждения тәрҗеманына биреп, аны төрекчәгә тәрҗемә кылдырган. Ләкин тәрҗемә итүченең бу фәннәрдән җитәр кадәр хәбәрдарлыгы[1] булмаганга күрә, ул тәрҗемәдән бер кеше дә бернәрсә дә аңлый алмаслык булып чыккан. Әмма тәрҗемә кылдыручының ул китаптан мосыйббәте[2] суынмаган, өмете өзелмәгән. Бәлки аны тәрҗемә итәргә тел белү генә, яисә ярты-йорты гына хәбәрдарлык җитмәгәнне, тәрҗемә итүче үзе шул фәннәрдән тулы мәгълүматлы кеше булу кирәклегенә төшенгән. Шул китапны тәрҗемә итәргә яраклы кеше итеп аңар мине күрсәткәннәр. Мин аны, зур читенлек белән булса да, тәрҗемә итеп, 1890 нчы елда тәмам кылып бирдем. Өстенә «Гыйльме фикъһенең тарихына вә әгазим әсхабенә даир гыйбарәдә мөҗаз[3] мәзаминдә[4] муаффәкарь[5] улан рисаләи мөфиддер[6]» дип яздым. Ул аны Казан китапчылары Мөхәммәтҗан Кәремевләргә биреп бастырган иде. Ләкин Казанда бик зур пожар вакытында Кәримевләр складында бик күп нөсхәсе янды. Дөньяда бик аз гына нөсхәсе калды. Үз кулымда да фәкать бер нөсхәсе генә, черновиклары гына калды. Тагын кемнәр кулында бардыр, белмим. Хакыйкать тәәссеф[7]! Мең тәәссеф! Укып чыкканнар күрерләр: бик мөфид вә бик осталык белә төзелгән, галим вә мөдәкъкыйк[8] кеше тарафыннан эшләнгән әсәр, шәкертләр өчен бик уңайлы иде.

**Тарих белән шөгыльләнүем вә тарих китаплары язуым[9]:** хәзерге заманда тарих вә музыка вә шигырьнең милләтләр хәяте вә дәвамы өчен кирәклеге ике дә ике – дүрт булганы кебек мәгълүм булганга, аны һәркем үзе дә бик яхшы белгәнгә күрә, алар хакында язып утыру бикяр[10] гомер уздыру гына булыр иде. Әмма 30–40 ел элек эш алай түгел. Тарих булса, бер дә кирәкмәс бер гыйлем итеп карала, аның белән шөгыльләнү – гомер әрәм итү генә санала иде. Шуның өчен

---

[1] Хәбәрдар – белүче.
[2] Мосыйб – дөресен табучы, теләгенә ирешүче.
[3] Мөҗаз – яраклы, рөхсәт ителгән.
[4] Мәзамин – аңлашыла торган мәгънәләр, әйтергә теләгәннәр.
[5] Муаффәккарь – ирешә алган, эше барып чыккан.
[6] Мөфид – файда китерүче, әһәмиятле.
[7] Тәәссеф – кайгыру, ачыну.
[8] Мөдәкъкыйк – нечкәләп тикшерүче, җентекләүче.
[9] 1922 нче елгы 1 нче номер «Безнең юл» журналында 35 нче биттә Галимҗан Ибраһимов мәкаләсе һәм аның 1925 нче ел басылган «Имля, тел вә әдәбият мәсьәләләре» китабында 17 нче биттә. (Бу шәрех 10 нчы биткә «Галимҗан иптәш Ибраһимов әйткәнче» дигән сүзебезгә тиешле) (автор искәрмәсе).
[10] Бикяр – эшсез, шөгыльсез, файдасыз.

һичбер мөселман мәктәп вә мәдрәсәләрендә түгел, тарих гомуми яки милли тарих, бәлки ислам тарихы укылмый иде. Бер ислам дөньясында ике меңгә якын тарих китабы кирәкмәскә язылмаганыннан, ислам галәмендә бик зур урын тоткан «галлямә[1]» исемен алган «Җәрирәттәбари» (4 олугы җильд), Мәсгуди вә ибн Халдун (7 зур җильд) һ.б. зурзур тарих китапларын язу белән кирәкмәскә шөгыльләнмәдекләреннән, безнең ул заманның гавамлары[2] гына түгел, бәлки гыйлем белән шөһрәт чыгарган зур голяма исемендә йөргәнәрнең дә хәбәре юк иде. Музыка вә шигырьнең дә исламият башланганнан бирле уйнала вә җырлана килгәнлекләре бик күп китапларда, хәтта «Сахиха Бухари» шикелле Коръәннән соң иң дөрес саналган китапларда язылган булсалар да, ләкин бер тапкыр өстән караган соңгы заман голямасының ялгыш сүзләренә, хәдисләрне урынсыз китерүләренә карап, хәрам санала вә һәркемне алар белән шөгыльләнү дә каты тыю белән тыела иде. Хәтта контрольсез муллалар, туйларга кереп, урамнарга чыгып, уйнаучыларны, җырлаучыларны куып, музыка коралларын ватып йөриләр иде. Фәкать Мәрҗани кебек чын вә бик сирәк галимләрнең генә эшнең алай түгеллеген беләләр вә аңлыйлар һәм аңлатырга тырышалар иде. Шуның өчен Мәрҗани башлап «тарих» дип әйтерлек китап «Мөстафадел-әхбар» китабын үзе язып, музыка вә шигырьнең хәрам түгеллеген, бәлки файдалы бер эш икәнен «Мөкаддимә вафийәт әл-әсляф» китабында язды, моның өчен заманында аның башына кыямәтләр куптардылар. Әмма хөкамаэ исламия[3] бәянына вә минем озак тәҗрибәмә күрә (тәфсилен яза тормыйм), беленгән хакыйкать шул идекен, дөньяны дөрес тану, милләтләрнең кувәи гыйльмия[4] һәм фикрияләрен киңәйтү һәм бу васита белән алга бару – тәрәккыйләре өчен кирәк тә кирәк. Аның өстенә башкалар тарафыннан йотылмыйча, дөньяда калу вә яши белүләре өчен дә зарур вә лябеддә минһ[5] (боларсыз мөмкин түгел) иде. Шуның өчен дә Галимҗан иптәш Ибраһимов әйткәнчә (моның шәрхе 9 нчы биттә), Мәрҗани корган тарих нигезенә бина үстерергә, аны киңәйтергә һәм бөтенәйтергә тотындым. Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар»ы 1885 нче елда нәшер ителде. Мин дә күптәннән үк җыеп килгән материалларымны 1890 нчы елда ук китап тәртибенә җыя вә яза башлаган идем[6]. Ләкин кайбер урыннары өзек вә ялганмаганга вә аларны ялгарту, чын тагын байтак

---

[1] Галлямә – күп фәннән белеме булган кеше, зур укымышлы, бик галим.
[2] Гавам – масса, кара халык.
[3] Хөкамәэ исламия – ислам галимнәре, философлары.
[4] Кувәи гыйльмия – гыйлем көче.
[5] Лябеддә минһ – ансыз мөмкин түгел.
[6] Морад әфәнде Мәккинең «Тәлфикъ ли-әхбәр» исемле төрек кавемләреннән тагаликъли урыннарыннан мин тәрҗемә кылып (автор искәрмәсе).

материал җыярга вә гомер сарыф итәргә хаҗәт күренде. Әмма минем бу тарих җыю вә язу белә шөгыльләнгәнемнән хәбәрдар булган укытучылар вә укыту эше белән кызыксынучылар, китабымның матлубча[1] тәмам булуын көтмичә үк, ибтидаи[2] сыйныфка укытырга яраклы китап язуымны миннән сорадылар. Бу сорау минем түбән катлаудан башлауга да тема муафыйк килгәннән, үземчә ибтидаияләр өчен муафыйк булуны гөман[3] итеп, шушы:

**8 нче тәэлифем булган «Төрек ыруглары» исемендәге** китабымны яздым. Өстенә «Төрек вә татар кавемнәреннән барчасының нәсел вә ыругларын вә тереклек рәвешләрен кыскача бәян итәр» дип яздым. Ни өчен бу китапны язу кирәксенелде? Аның башына язылган «Мөәллиф[4] тарафыннан берничә сүз»е ачык күрсәтә (монда кабатлый тормыйм). Бу китап Казанда «Милләт» көтепханәсе тарафыннан 1897 нче елда бастырылды[5].

**9 нчы тәэлифем «Мотасар тарихе кауме төрки».** Өстенә болай язган идем: «Төрек ыругы кавемләреннән барчасының нәсел вә нәсебләрен, вә тереклек рәвешләрен, Яуропада әүвәл зоһурлары[6] тәртибе белән бәян ителде». Бу китапны язуга да сәбәп – ул вакытта рөшди мәктәп[7] вә мәдрәсәләрдә тарих укыту кирәксенелә башлаган, ләкин ул вакытта аңар яраклы китап мәйданда юк иде әле. Югарыда әйтелгәнчә, минем тарих белән шөгыльләнүемнән хәбәрдар булган укытучылар «Төрек ыругларыннан» озынрак янә бер китап язуымны (мөфассалны[8] көтмичә үк) сорадылар. Хосусан мәдрәсәләргә яңа фәннәр кертә башлаучы мәдрәсәи Мөхәммәдия мөдәррисе Галимҗан Баруди, миннән бу эшне таләп итте. Шулай ук бу китап та Казанда «Милләт» көтепханәсе тарафыннан 1907 нче елда бастырылды. Тарих укытуны кирәксенүчеләр арасында бу китап бик тиз таралды. Тәкрар[9] бастырылуны сорадылар. Ләкин ул вакыт тарих кирәксенүчеләр бик күп түгел иде. Шул сәбәпле тәкрар бастырылмый калды.

**10 нчы тәэлифем «Мөфассал тарихе кауме төрки»** 1909 нчы елда Уфада «Шәрекъ» матбәгасында[10] басылды. Бу китап Русиядә истиснасыз[11] бөтен вакытлы матбугат тарафыннан гүзәл мәкаләләр, тәкъризләр[12] белән каршы алынды. Халкыбыз вә гыйлем әһелләребез арасында

[1] Матлуб – теләнгән, эзләнгәе, таләп ителгән.
[2] Ибтидаи – башлангыч.
[3] Гөман – уй, фикер.
[4] Мөәллиф – китап язучы, китап төзүче.
[5] Музыка вә шигырь мәсьәләләренә мин түбәндә янә кайтачакмын.
[6] Зоһур – килеп чыгу, күренү, барлыкка килү.
[7] Рөшди мәктәп – башлангычтан югары (урта) мәктәп.
[8] Мөфассал – тулы, җентекле.
[9] Тәкрар – кабат, кабатлау.
[10] Матбәга – типография.
[11] Истисна – чыгарма, аерып алу.
[12] Тәкъриз – язылган әсәр һәм хезмәткә мактап бәя бирү.

бик тиз мәгълүм вә мәшһүр булды. Хәтта Төркия, Төркестан вә Төркмәнстанга кадәр җитешеп, гәзитәләргә язылды. Аларда да тәхсиннәр[1] вә афариннар казанып, зур-зур һәдияләргә[2] сәбәп булды. Вамбери вә Мисаруш кеби мөстәшрикъларның, Галимҗан Ибраһимов вә Габдрахман Сагди һ.б. кебек олуг мөхәррирләр тарафыннан тәкъдир ителде вә әсәрләренә дә яздылар[3]. Шул китапның «Мөкаддәмә[4]»сендә әйткәнчә, аңар материал җыяр өчен бик күп вә бик күп җилде китаплар күрелде вә бик озак гомер сарыф ителде. Ләкин, шөкерләр булсын, сагыйларым[5] габәскә[6] китмәде.

Моны да әйтеп китми булмый: бу китапның беркадәр җире мәшһүр Ишмөхәммәд мулла тарафыннан, «Яңа Тазлар» авылында бер солдаттан русчага тәрҗемә иттерелеп, туп-туры Сталинга җибәрелгән вә бу да гыйлавә[7] ителгән: «Әтнә мулласы (доноста исеме дә язылган иде, ләкин хәзер хәтеремдә калмаган): Әле аның икенче җилде бар. Ул җилдтә ул: «Төрекләр, татарлар, японнар берләшеп мөстәкыйль бер хөкүмәт төзергә тиешләр», – дигән имеш. «Әле минем аны күргәнем юк», – дигән. Ишмөхәммәд мулланың: «Күргәнем юк», – диюе дөрес. Чөнки ул җилд әле мәйданга чыкканы юк. Һәм анда андый сүзләр язылганы күптән юк. Әмма Әтнә мулласы Сирәф ялганны сөйләгән. Ишмөхәммәд мулланың «Мизан[8]» исемле китапларында «вәҗһе җиб кателүһем = аларны үтерү ваҗиб» дигән кешеләрнең берсе мин булганга күрә, доносында ул күренгәннәрне генә түгел, бәлки ишеткәннәрне дә, бер дә тәфтишсез-нисез язган. Шушы донос сәбәп белә минем бу эшемдә Бубыйлар эше тапшырылган «Судебный следователь по особо важным политическим делам»га тапшырылган. Ул да үзенә боерылган эшендә кимчелек итмәде. Китабым бик нечкә тәфтише астына алынган шикелле, үзем дә бик каты җавап астына алындым. Һәм жандармский полковник нәзарәтенә[9] тапшырылып, аның рөхсәтеннән башка бер җиргә чыкмаска мәҗбүр ителдем. Туган илемнән башлап, Казанда, Уфада минем хакта дикъкатьле тәфтишләр йөреп, бик күп кешеләр дә соралдылар. Шөкерләр булсын, соралганнар мине нахак һәлак итәргә разый булмадылар. Китапны язганда ук бу эшләрнең булачагын сизелеп, китап бик

---

[1] Тәхсин – яхшы күрү, мактап яхшы дип әйтү,

[2] Һәдия – бүләк.

[3] 1927 нче елда басылган «Татар әдәбияты тарихы», моны да тәшәккер белән язамын ки, иптәш Г. Сәгъди төрле мөнәсәбәт белән шул әсәрендә мине алты урында зикер иткән. Әле үзе белән күрешкәнебез-танышканыбыз юк (автор искәрмәсе).

[4] Мөкаддәмә – сүз башы, кереш сүз.

[5] Сагыйлар – тырышлыклар.

[6] Габәс – буш нәрсә, файдасыз эш.

[7] Гыйлавә – өстәмә, бернәрсәгә өстәлгән кушымта.

[8] Мизан – үлчәү, бизмән.

[9] Нәзарәт – күзәтү, контроль.

саклык белән язылган иде. Шул сәбәптән, китапта мине гаепләрлек эш табылмаганлыктан, китабым һәм үзем сәламәт калдык.

Тәэлифләрем хакында шушы кадәр белән туктыйм. Тәмамга якын булып та бәгъзе сәбәпләрдән басылмый калган «Тәдбир мәнзәл» (экономическая политика), «Вазаиф этфаль[1]», «Мизанелхак фи ихтиярелхак» материаллары беркадәр җыелып та, төрле сәбәпләрдән эшләнеп бетмәгән «Гомәр бабай», «Болгар шәһәрләре», «Мофассал тарих кауме төрки»нең 2 нче вә 3 нче җилдләре хакында сүз кузгатмыйм.

Әһәмияте булганга күрә мин инде бу урында тәэлифтән башка гыйльми вә иҗтимагый хезмәтләремнән бәгъзеләрен язам.

**«Диния нәзарәтенә исляхат[2]»:** Диния нәзарәте = Духовный собраниянең ислахка мохтаҗ икәнлеге күптәнннән үк мәгълүм иде. Мин үзем нәзарәт әгъзалыгына чакырылмас борын ук аны вә коерыкларын (мәхәллә, ахундлык, мохтасиблык һ.б.) ислах хакында бер ляихә[3] язып җибәргән идем. Бу ляихәмне күзеннән кичергән мәрхүм Баруди, ислахтан өметсез булуыннан булса кирәк: «Мөфти: “Хәерле булсын”, дияр дә калыр», – дип язып куйган иде. Ләкин мөфти алай дип кенә калмаган иде калуын, бәлки ислах кылыныр өмете белән, әүвәл Рәшит, Риза мине Уфага чакыргач, янә миннән, хәтта гайнияттән дә, үз-үзебезгә мөстәкыйль (бер-беребездән күчереп кенә түгел) ислах ляихәләре төзергә боерган вә без дә мәгалмәмнүнилять[4] өчебез дә (минеке инде бу өченчесе иде) төзегән идек. Бу ляихәләр ляихә хәлендә ятып, 1905 нче елда Уфага төрле тарафтан кешеләр чакырылып, янә ислах ляихәләре төзегәннәр иде. Бу съезд вакытында мин анда була алмадыгымнан, әхвәл үзгәрүенә күрә, вә элкеләренә бераз үзгәрешләр кертеп, өйдә торып ляихә төзеп җибәргән идем (монысы дүртенчесе иде)[5]. Шул съездда рәислек итүче мәрхүм Г.А. минем җибәргән ляихәмне бик җитди күрелгәнне шул съездда төзелгән ляихәгә вә бәгъзеләре гайнән күчерелгәнне, күп маддәсен әсас ителгәнне сөйләгән иде. Бу съезд төзегән ляихә эшкә ашкан тәкъдирдә дә Русия ислам галәмендә җилди үзгәрешләр булачагын мөляхәзә[6] белән, ляихә ике мәшһүр юристлар – карт Әхтәмев белән Албинскийлардан хөкүмәт теленә низам рәвешенә китерелеп, объяснительный запискалар язылып, хөкүмәткә төрле тарафтан җыелган вәкилләр илтеп биргәннәр иде. «Ярар, каралыр» җавабы

---

[1] Вазаиф этфаль – балаларның вазыйфалары, бурычлары.

[2] Исляхат – үзгәртүләр, реформалар.

[3] Ляихә – проект.

[4] Мәгалмәмнүнилять – шатлык белән, шатланып.

[5] Бу ляихәләрне Муса әфәнде Бигиев миннән сорап алып, ул хакта «Исляхат әсаслары» исемле китабында ..... байтак нәрсә язган. Бәлки Риза казый да кайда булса да бу хакта язгандыр, ләкин күргәнем юк. (Муса әфәнде ул ляихәләрне миңа кайтарганы юк әле) (автор искәрмәсе).

[6] Мөляхәзә – фикер йөртү.

бирелеп, тәкрар мөрәҗәгатькә дүрт елдан соң истиһза[1] рәвешле бер нәүгы[2] җавап белән каралуы тагын да алдагы көнгә калдырылган иде. Гакыйбәт[3] 1914 нче елда Русиянең <u>өч мөфтие вә бер шәйхульислам</u>[4] вә мөселманары, күп губерналарның губернаторлары чакырылып, Дахилия министерствосында каралса да, ниндидер бер карарга киленсә дә, ләкин шул арада Герман сугышы ачылып, соңра инкыйлаб булу сәбәбеннән, нигә карар бирелгәне дә мәгълүм булмый калды. Шул киңәш мәҗлесенә мөфти Солтанов урынына чакырылган Гайният казый[5] протокол копиясен дә алып кайта алмаганлыгы сәбәбеннән, мәҗлес карары бөтенләй күрелми калды.

**Уфада тел төзәтү. Мәктәп вә мәдрәсәләрне ислах. Халык арасына файдалы китаплар тарату эшләрен карар өчен җыелган зур җыелыш.**

Телебез, төрек-татар телен төзәтү, мәктәп вә мәдрәсәләребезне ислах итү халкыбыз арасына файдалы китаплар тарату кирәклеге бу эшләрдә ялгыз-ялгыз адәмләрнең генә түгел, бәлки зур җәмгыятьләр белән эшләнергә тиешле икәне күптәннән хис ителә иде. Менә шул мәсьәләне мөзакәрә[6] кылу вә эшләү өчен 1899 нчы елда Уфада бер җәмгыяи әдәбия җыелды. Фатих Кәрими 1907 нче елда басылган «Аннан-моннан» исемле китабында болай язган (чүпләбрәк, телен дә татарлаштырыбрак язам): «Дүрт-биш ел элек Уфада бер җәмгыяи әдәбиябез җыелды. Казан, Оренбург, Троицки, Петропавловски, Семипалат шәһәрләреннән вә башка мөселман мәркәзләреннән беркадәрле әдипләр, мөхәррирләр, яңа фикерле имамлар, мөдәррисләр, мөгаллимләр, педагоглар, чалмалы шәехләр; ачык башлы, озын чәчле гимназистлар, студентлар да бар иде. Шәригать гыйлемнәрен белгәннәребез булган кебек, дөнья гыйлеменә дә мәгариф җәдидәгә әшнә булганнарыбыз да бар иде. Татарча, төрекчә, фарсыча, русча, французча телләрне белүчеләр дә бар иде. Бер атнага кадәрле һәркөн мәҗлесләребез булды. Имля вә язуларыбызны ислах, әдәбиятыбызны тәрәккый иттереп, халкыбызны нурландыру хакында тәртип белән сөйләшенде. Сөйләнгән сүзләр төрле яктан мөхакәмә[7] кылынып, әксәрият[8] белән хөкем вә карар бирелде.

---

[1] Истиһза – көлү, мыскыл итү, хурлау.

[2] Нәүгъ – төр, сорт.

[3] Гакыйбәт – эшнең соңы, нәтиҗәсе.

[4] Ләкин Кырым мөфтисе Карашайскийдан башкасы бармадылар. Хәерле нәтиҗә көтелмәгәннән булса кирәк. (автор искәрмәсе).

[5] Бу министерство хозурындагы киңәшкә – мәҗлескә мөфти үзе мине билгеләп, төрле материаллар биреп, хәзерләндергән һәм Уфа мөселманнары да мине сайлаганнар иде. Ләкин хөкүмәт мине кабул итмәде. Бәлки үзе Гайниятне хаслап чакырып, аңар тәрҗеман рәвешендә Сафа Баязитовны билгеләде (автор искәрмәсе).

[6] Мөзакәрә – фикер алышу, сөйләшеп утыру.

[7] Мөхакәмә – хөкем чыгару.

[8] Әксәрият – күпчелек.

Мәктәп ибтидаиләребез өчен гомуми программалар тәртип ителде. Ибтидаиләрдә, рөшдиләрдә укытмак өчен бер беребез хисап, бер беребез тарих[1], кыскасы, ун төрле китап язылырга әгъзалардан кешеләр билгеләнде. Болар өстенә, халкыбызның холыкларын төзәтергә, мәгълүматларын киңәйтергә, тереклек вә дәүләтләрен яхшыландыруга вә алга җибәрүгә файда бирердәй гыйлем-мәгърифәт, һөнәр вә сәнаигыга даир китаплар халкыбыз арасына таратырга бу китаплар җиңел, саф, үз төрки телебездә, кечкенә ачык гавам халкы да, яшь шәкертләр дә укырлык, мәшәкатьсез аңларлык булырга карар бирелде. Бу максатка яраклы китапларның әүвәл дә барларын сайлап, аларга юкларны тәэлиф итеп мәйданга куярга, файдалы күрелгәннәрне халкыбыз арасына чәчелүне иҗтиһад итүне һәр мөэмин мөселманнан гомумән үтенелергә карар бирелде. Һәркем үз истигъдады[2] вә хәзерлеге вә көче җиткән кадәр кавемебез вә милләтебезгә хезмәт күрсәтсен!...». Фатих Кәрими китабында моны 30 нчы биттән 41 нче битенә кадәр тәфсилләп язган. Карарларны да, хазир[3] булганнарның беркадәресенең фиһристендә[4] язган. Фатих әфәнде бу җәмгыятьнең яңадан җыелмаганына хәсрәт итеп болай язган: «Көннәр буена сөйләштек, араларында мин дә бар идем. Мөшавәрә[5] вә мөзакәрәләр[6] иттек, һәр ел шушы билгеле вакытта җыелышырга, бер еллык хезмәтләребезне җәмгыятькә гарыз итәргә сүзләр, вәгъдәләр биреп аерылыштык. Ләкин шушы аерылышу соңгы аерылышу булды. Биш-алты ел булды, һаман да җыелыша алганыбыз юк. Җәмгыятьнең исемен дә телебезгә алганыбыз юк. Әмма ни өчен? сөаленә төпле бер җавап таба алмыйм. Бер такым тиречe, ябагачы Шәмсиләрнең, Галиләрнең кәефенә хуш килмәгәне өчен, бу кадәр гүзәл, төпле вә файдалы бер җәмгыятьнең дәвамыннан ваз кичтек дияргә уфтанамын». Фатыйх Кәриминең кирәксенгәнем кадәр сүзләре шунда тәмам.

Җәмгыятьнең дәвам итә алмаганына Фатыйх Кәриминең китергән сәбәпләре дә, әлбәттә, бар иде. Ләкин ул гына түгел, башка сәбәпләр дә бар иде. Ул вакыт мондый яңа эшләр ата-бабадан вә йә остазлар тарафыннан күрелмәгән эшләр хилафына аякланучы ялгыз тиречеләр, ябагачылар гына түгел, бәлки бик күп голяма исемен күтәргән, искелеккә каткан, шул ата-бабада, остазларда күрелмәгән һичбер эшне эшләргә ярамый фикерендәгеләр бар иде. Бу җәмгыятьне башлап кирәксенүче вә проектасын

[1]Хисап Фатих Кәримигә, тарих Хәсәнгата Гәбәшигә бирелгән иде (автор искәрмәсе).

[2] Истигъдад – сәләтлелек, булдыклылык.

[3] Хазир – күз алдында булган, шунда булучы.

[4] Фиһрист – эчтәлек.

[5] Мөшавәрә – киңәшләшү.

[6] Мөзакәрә – фикер алышу.

төзүче, чакырылачак адәмләрне тәгайен[1] итүче Риза казый белән без идек. Дәрхәкыйкать[2], тугрысын әйткәндә, Риза казыйны да кабинеттан чыгарып җәмәгать эшенә тартучы мин идем. Бу җәмгыятьнең инициаторы булганым кебек, ахырдан җәмгыятьнең карарлары да минем тәртибем буенча, хәтта минем каләмем белән язылган иде. Идарәнең өч әгъзасыннан икәвебез чирмешләр игътикадындагы[3] «йому» хезмәтен күргәндә, берәвебез «кирәмәт» хезмәтен күрә, ягъни икәвебез мең мәшәкать белән катлау-катлау рөхсәтләр алу, чакырылачак кешеләр билгеләү, мөзакәрәгә куелачак эшләр программасын төзү белән баш ваттыгыбызда, беребез бөтенләй бу эшләрне кирәксенми генә түгел, бәлки бу эшләрне булдырмаска теш-тырнагы белән тырыша иде. Җәмгыять ..... чакырылачак булгач, ул җәмгыятьнең составын үзе теләгәнчә мәсләктәшләреннән тәшкил итәргә тырышты. Ул да булмагач, шул сәгатьтә ул, Фатыйх әйткәнчә, тирече, ябагачыларны гына түгел, иске фикерле голяманы да, хәтта Уфа имамларыннан кайберләрен үз тарафына алып, югарыда әйтелгәнчә, баштан ук булдырмаска, рөхсәт бирдермәскә тырышуыннан өстен, җәмгыятьнең карарларыннан разый булмыйча, Уфаның печән базары хөкемендәге Гостинный дворына чыгып, җәмгыять әгъзаларын, карарларын әллә нинди кара буяуларга буяп, курканыч сурәттә күрсәтеп, әфкярдәшләре ярдәме белән кара агитацияләр ясадылар. Җәмгыятьнең авторитетын саклар өчен безгә бик каты көрәшергә туры килде. Шулай да без ул елны максудыбызча кышны тәмам иттек. Ләкин мин шул елның ахырында бәгъзән шушы көрәшләрнең сүэ[4] тәэсире белән[5] тәмам хасталанып, табиблар карарынча, күп эшләү сәбәбеннән каты рәвештә ми ялыкуы булганлыктан, шул табибларның киңәше буенча, баш эшләреннән тәмам тукталып, озак ял итәргә мәҗбүр булдым. Һәм вакыйган[6], бөтенләй эштән тукталып, вакытсыз, кыш уртасында җәмагатьләрем[7] белән авылга кайтып киттем. Киләчәк елда искелек вә искеләләр белән каты көрәшкә дә билгелән[гән] вакытта шул җәмгыятьне җыю эше белән шөгыльләнергә берәү дә кузгалмады. Риза казый да искедәге гадәтчә кабинетына кереп утырды. Менә! Фатыйх әйткәнчә, беркадәр гүзәл җыелышларның тукталып калуына тулы сәбәпләр шушылар булды.

---

[1] Тәгайен – билгеләү.

[2] Дәрхәкыйкать – чынлыкта.

[3] Игътикад – ышану, күңел беркетү.

[4] Сүэ – явыз, начар.

[5] Бу җәмгыятьнең инициаторы мин икәнен һәркем диярлек белә. Искелек тарафдарларының зәһәрле телләре дә минем тәнемә кадала иде. Риза казый хатип түгеллекне вә тавышы зәгыйфьлекне бәһанә (сылтау, сәбәп – ред.) итеп, һәрвакыттагы кебек, монда да каты чар итү, көрәшүдән саклана иде (автор искәрмәсе).

[6] Вакыйган – чыннан да, дөрестән дә.

[7] Җәмагать – берәүнең хатыны, өй кешеләре.

**Фәкыйрь студентларга ярдәм җәмгыяте.**

Тәфсиленә хаҗәт юк. Уфада урыс мәктәпләрендә укучылар Казанга күрә күбрәк иде. Ләкин аларның аталары күбрәге дә аз жалуния белән хөкүмәт учрежденияләрендә хезмәт итүче адәмнәр иде. Түбән вә урта мәктәпләр Уфаның үзендә булганлыктан, анда укытуга күп мәшәкать чикмәсәләр дә, әмма гали уку урыннары Уфада булмаганлыктан, читкә җибәреп укыту аларга бик авыр иде. Бер кузгалуга кузгалып, гали мәктәпләргә мең мәшәкать белән кергәннәре дә бик начар хәлдә яшиләр вә йә бөтенләй чыгарга мәҗбүр булалар иде. Менә бу хәл шул фәкыйрь студентларга ярдәм кирәклекне күрсәтте. Вә моның өчен ярдәм җәмгыяте төзелүне өстәде. Уфаның күп булмаган интелигентлары белән бергә учредительләр булып, 1899 нчы елның урталарында устав төзеп, тасдыйк[1] иттерелгән, правлениясенә рәис вә әгъзалар вә хәзинәдар[2] да, мин, Габәшине сайлаганнар вә байтак кына акча да җыелган иде. Ләкин, югарыда әйтелгәнчә, авыруым сәбәбеннән, мин Уфаны ташларга мәҗбүр булдым. Һәм җыелган акчаны, бу көндә сәламәт булган, шул җәмгыять правлениясе булган Баһаветдин Мәксудовка тапшырып киттем. Ахырда ул җәмгыятьтә дәвам итә алмаганнар. Мин икенче мәртәбә Уфага барганчы, җиде-сигез еллар үтеп киткән. Ул җәмгыять баш ала онытылган иде.

**Дарелмөгаллимин вә мөгаллимат:** мәдәниятккә аяк баскан халыкларда тәртипле тәрбия күргән мөгаллим вә мөгаллимәләр булу лязим икәнен сөйләргә хаҗәт юк. Ул вакытның хөкүмәт мәктәпләре без теләгән мөгаллимләрне житештермәгәне вә мөселманнарның үзләренә дә бу турыда юл бирмәячәге мәгълүм иде. Менә мөфти Солтановның хөкүмәткә хезмәтенә илле, мөфтилек хезмәтенә илле, мөфтилек хезмәтенә егерме биш ел тулу мөнәсәбәте белән аңар юбилей ясарга вә аңар ядкәр булу бәһанәсе[3] белән дарелмөгаллимин вә мөгаллимат ачарга рөхсәт бирелмәсме өмете белә Уфа мөселманнары юбилей ясарга карар бирделәр. Вә моның өчен халыкның һәртөрле таифәсеннән[4] 16 кешедән гыйбарәт комитет сайладылар. Рәис итеп Сәлимгәрәй Җантуринны, аңар могавин[5] итеп мине сайладылар. Ләкин Җантурин, хатыны авыру булу сәбәбеннән, тиз көннән Станбулга китәргә мәҗбүрият күрде. Шул сәбәптән, һәр хосусымда рәислек итү бөтенләе белән миңа калды[6]. Менә комитет әксарияте[7] тәрәккый

---

[1] Тасдыйк – раслау, дөреслеген тану.

[2] Хәзинәдар – хәзинә тотучы, казначей.

[3] Бәһанә – сылтау, сәбәп.

[4] Таифә – төркем, җәмәгать

[5] могавин – ярдәмче, булышчы.

[6] Бу комитетта бө көннәрдә Казанда булган Фәррәхетдин иптәш Әхмәдев секретарьлек иткән иде. (автор искәрмәсе).

[7] Әксәрият – күпчелек.

тарафдарлары (әмма гомум халыкка нисбәтән азчылык) шул дарелмөга.... ачарга, ә комитет азчылыгы (гаммәгә нисбәтән күпчелек) искелек тарафдарлары моңар бик нык каршы торып, аның урынына бер дини мәдрәсә ачарга теләделәр. Бу мәсьәлә юбилейга иштиракь[1] итәргә, Бөтенрусиядән съезд тарафыннан хәл кылыначак булды. Юбилейга ничә меңнәр белән халык җыелды. Ядкәр мәсьәләсе хәл кылыр өчен, Уфада иң олугы урын – Дворянский собрания залында җыелыш ачылды. Зал күтәрә алган кадәр халык кертелде. Ләкин бик күп кеше коридорларда, баскычларда, хәтта урамда калдылар. Җыелган халыкның бик күбесе иске фикерле һәм Уфада да, дарелмөгаллимин.... хилафына куәтле агитация йөрттекләреннән, җәмгыятьнең бик шау-шулы булачагы көтелә, дарелмөгаллимин фикерен үткәреп булуга бик аз өмет күренә иде. Бу сәбәптән, җәмгыятьтә рәислек итүдән һәркем, хәтта юристлар да тартылалар иде. Гакыйбәт[2] юбилей комитеты миңа ябышып, мине тәклиф[3] иттеләр. Ахырда мин кабул итеп, рәислек иттем. Җәмгыять низамнарыннан аз хәбәрле һәм үз фикеренә тәгассыблы[4] бу кадәрле күп халыкка рәислек итеп, хәтта губернатор да мактау рәвешен дә (мәҗлес гаять тәртипле баруы җәһәтеннән, документларда карагыз). Тәртип белән алып барып, максудча дарелмөгаллимин...гә карар чыгарту асат булмады. Һәрничек тә тәрәккъый тарафдарлары теләгәнчә чыгуына алар гаять мәмнүн булдылар. Зариф иптәш Бәшири кайдадыр бер мәкаләсендә, әсәрендәме, хәтерләмим: «Хәсәнгата хәзрәт Габәши бик осталык белән рәислек итә иде», – дип язган иде. Тәрәккъый тарафдарлары, күзләренә яшь китереп, кулымны кысып миңа рәхмәтләр укыдылар. Фатыйх Кәрими һ.б.: «Инде моннан ара һичбер җәмгать хезмәте эшләмәсәң дә, бу хезмәтең гомер буе эшләнәчәк хезмәтләргә торырлык булды, җәмгать хезмәтчесе исемен алырга тәмам җитәрлек булды», – диделәр. Икенче көн шул ук Дворянский собрания залында юбилей хөрмәтенә, 500 кешелек тантаналы зыяфәт[5] мәҗлесе, юбилей комитеты тәшәббесе[6] белән ясалды. Мәҗлеснең шәүкәтен[7] арттыру өчен гаскәри оркестр чакырылачак булды. Милли рух бирү өчен капельмейстер офицер Моттельдән: «Беркадәр татар көйләре уйный алмассызмы», – дип үтендек. Ул: «Без болай гына уйный алмабыз, чөнки бер дә татар көйләре уйнаганыбыз юк, әмма нота хәзерләп бирүче булса, гәрчә вакыт бик аз калган (бер-ике генә көн) булса да, уй-

---

[1] Иштиракь – катнашу, бергәләп эшләү.
[2] Гакыйбәт – эшнең соңы, нәтиҗәсе.
[3] Тәклиф – көчләп кушу.
[4] Тәгассыб – артык омтылу, фанатизм.
[5] Зыяфәт – кунак итү, хөрмәтләү.
[6] Тәшәббес – тапкырлык, инициатива күрсәтү.
[7] Шәүкәт – көч, куәт, бөеклек.

ный алыр идек», – диде. Түбәндә әйтәчәгем фәнни рәвештә музыка өйрәттергән угылым Солтанәхмәд Габәши тиз генә арада ике озын, ике кыска = Ашказар, Тәфтиләү, Пороховой Хатиҗә, Баламишкин көйләренә язып өлгертте. Моттель да аларны оркестрга таратып хәзерләде. Мәҗлескә билгеле юбилилыларны Уфаның үзеннән руслардан күбрәге әлеге эш башындагы кешеләрдән илле кеше чакырылды. Калганнары читтән җыелган кешеләр иде. Юбилей комитеты рәисе булуым сыйфаты белән, юбиләр мөфтине дә каршы алып, үзенә мөнасиб татарча хөтбә сөйләдем. Шулай ук рус кунакларын да каршы алып, русча речь сөйләдем. Оркестр татар көйләре уйнады, бик гүзәл чыкты. Рус кунаклары көйләрдән гаҗәпсенеп, бер-берсенә карашып: «Бу нинди көйләр?», – дип сораштылар. «Татар көйләре», – дигәч, «Кара син, татарларда да шундый военный оркестр белән уйнарлык көйләр бар икән», – диештеләр. Һәм бик яраттылар.

Озын-озын өстәлләр, бик гүзәл чәчәкләр белән гаять зиннәтле төзелгән нигъмәтләр. Иң өстә ресторанчылар тарафыннан яшерелгән шәраблар да, кешесенә – кунагына күрә лимонад, шипучий куастан шампанскийга кадәр хәзерләнгән иде. Әлхасыйл, бик сәеррәк була торган мәҗлесләрдән берсе булды. Музыканы да сорап-сорап, кайта-кайта уйнаттылар. Кунаклар гаять самими рәхмәтләр укып, бик шат булып таралдылар.

Иртәгесен бик зур рәвештә сабан туе ясалды. Һәр тарафтан, хәтта бик ерактан да халык бик күп иде. (Биш меңгә чамаладылар). Утызлап чабыш аты, йөгерешүчеләр, мәшһүр көрәшчеләр, хәтта велосипедчылар да, һәркайсы үз һөнәрләрен күрсәтteләр. Бөтен шәһәр халкы диярлек хәзер булдылар. Киез өйләр, шатерлар да корылган иде. Мөфти үзе дә хәзер булды. Анда һәм гаскәри музыка шул көйләрне уйнады. Җыелган халык бик гаҗәпсенеп кызыгып тыңладылар. Үзләренең таныш милли көйләре, башкорт-татар көйләренең гаскәри оркестрда ишетүләренә гаять тә шатландылар. Мин сәбәпче угылым Солтанәхмәд язып бирүче булганлыгыбыздан, халык безгә әйтеп бетергесез рәхмәтләр укыдылар. Музыка бабында тәшәббесемез[1] вә сагыйларыбызның[2] бу дәрәҗәдә сәмәрәсен[3] күрү белән, билгеле, без дә шатландык. (Музыка вә шигырьләр бабында хезмәтем үзенә башка бер эш булса да, ләкин юбилейдагы музыкага мөнәсәбәте булганлыктан, юбилей бабын бүлеп торып булса да, бераз язып китүне мәгъкуль күрдем).

Тарих бабында музыка вә шигырьгә ничек караганымны беркадәр язган идем. Инде монда янә беркадәр язам. Файдалы эшкә, тел вә каләм белән генә

---

[1] Тәшәббес – тапкырлык, инициатива күрсәтү.
[2] Сагый – тырышучы.
[3] Сәмәрә – җимеш, нәтиҗә.

өндәүгә күрә, гамәл = эш белән өндәү тәэсирлерәк булуы – күптән мәгълүм бер хакыйкать. Шушы максат белән мин музыкага үз балаларымнан башлап, самоучка белән генә түгел, бәлки фән юлы белән өйрәтү өчен мәшһүр композитор Рубенштейнның шәкерте Яна Васильевна Соколова дигән музыка мөгаллимәсеннән угылым Солтанәхмәд белән кызым Рокыяне дәвамлы рәвештә укыттым. Баштагы өч айны укыгач та, шул мөгаллимәләре: «Бу балаларда музыйкальный слух фәүкыльгадә[1] куәтле булганын, шул өч айда болар гади балаларның ел ярымда алганнары кадәрне алганнарын» – сөйләде. Без аңар мәгърур булдык. Уфадан киткәнчегә кадәрле дәвам итәрдек. Мәрхүм Сәлимгәрәй Җантурин белән без әдәбият вә музыка кичәләре ясар өчен Уфа мәдрәсәләреннән, хөкүмәт мәктәпләрендә укучылардан вә хезмәткәрләрдән катыш группа төзеп, күбрәге Җантурин йортында, кайсы вакыт минем йортымда репетицияләр ясадык. Ул вакытларда әле әфкяре гаммә[2] мондый эшләргә дин ничек карауны бик игътибарга ала, иске фикерлеләр моннан файдаланып, бу эшләрнең барын да хәрам күрсәтеп, бу эшкә катышу, булышудан вә әдәбият кичәләренә йөрүдән «дин» исеменнән тыярга тырышалар иде. Уфа җәмгыяте хәйрия мәҗлесләрендә, бу эшкә дин җәһәтеннән манигы юк икәнен «Сахихы Бохари», «Ихъяи голүм[3]», «Фәтваи Һиндия» дә, б[ашка] могътәбәр китаплардан дәлилләр китереп исбат итә идем. Һәм: «Кемдер моның хилафына сүз сөйли, пәрдә артына яшеренмәсен, менә шушы ачык мәйданга чыгып сөйләсен», – дия идем. Уфада каршы чыгучы булмады. Әмма «Дин-мәгыйшәт»челәр минем башыма да кыяматләр куптардылар. Ләкин халыкның күбесе аларга карамады. Безнең тырышлыклар, көрәшләр бушка китмәде. Әдәбият кичәләренә залга сыймаслык кадәр халык килә иде. Үзем дә калмый идем. Ул вакытта Уфада рояльдә уйный белүче бер ялгызы булып Солтанәхмәд уйный иде. Музыка кораллары, вагы-эресе күбәйде. Хәтта мәрхүм Хәкимев шикелле Ишмөхәммәт мулла нөфүзенә[4] төшкәннәр рәтенә керде. Без Уфадан киткәнчегә кадәрле шул хәл дәвам итте.

(Янә юбилей мәсьәләсенә кайтабыз). Бу дарелмөгаллимин вә мөгаллимат ляихәләрен[5] төзү, рөхсәт алу, фигылияткә чыгару эшләре барсы да шул олы җәмгыять тарафыннан тагын да шул ук юбилей комитетына тапшырылган иде. Бу комитетта минем рәислегем белә ике айдан артык вакыт сарыф итеп, мөтәхассыйс[6] мөгаллимләр дә чакырып,

---

[1] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.
[2] Әфкяре гаммә – күпчелек уе, масса карашы.
[3] Ихъяи голүм – гыйлемне яңарту, тергезү.
[4] Нөфүз – авторитет.
[5] Ляихә – проект.
[6] Мөтәхассыйс – белгеч, специалист.

этрафлы мөляхәзә[1] вә бик дикъкать, әхваль вә икътидарыбызга[2] татбикъ[3] белән тәмам булды. Мөфти үзе дә бергә булганы хәлдә, комитет вәкилләре аны Петроградка илтеп хөкүмәткә тапшырдылар[4]. Хөкүмәт билгеле: «Ярар, вакыты белән карарбыз», гыйбарәсе белән алып калды. Бер елга кадәр аннан нам-нишан[5] булмады.

Комитет янә белеште. Хөкүмәт: «Ул ляихәне, хосусан аның программаларын җитди рәвештә карарга кирәк була. Менә мөселман эшләрен карар өчен Дахилия министерствосында киңәш мәҗлесе җыелачак. Анда мөселманы күп губерналарның губернаторлары һәм Русиядәге өч мөфти, бер шәйхүльислам да чакырылачак. Бу ляихә шул киңәш мәҗлесендә карарга кичектерелде», – җавабы алынды. Гомер узу белән бер көн ул киңәш мәҗлесенең көне вә вакыты билгеләнде. 1914 нче ел мартта булачагы, алдан 1913 нче ел ахырында мөфти Солтановка хәбәр ителде. Дүрт дин башлыклары чакырылды. Ләкин берсе дә үзләре бармадылар. Оренбургы мөфтисе Солтанов үзенә хәбәр ителгәч тә, үзенең бара алмаячагын, үз урынына мине җибәрәчәген, моның өчен миңа күп кенә материаллар биреп, җитди рәвештә хәзерләнергә, хәтта кайбер мөһим күренгәннәрен күңелгә бикләргә боерды. Чакырылу көне җиткәч, үзеннән генә кеше җибәрергә хакы булса да, ләкин халык теләгән кеше булуны мөляхәзә белән соңыннан халыкның үпкәсе булу ихтималын йөртеп, Уфа халкыннан представительләр чакырып сайлатты. Представительләр дә билиттифак[6] диярлек әксәрият[7] белә мине сайлаганнар иде. Ләкин министерство мине кабул итмәде. Бәлки, минем урыныма хөкүмәт үзе Гыйният казый Капкаевны наз[на]чайть иткәне вә аңар переводчик итеп Сафа Баязитовны билгеләнде. Губернатор аркылы хәбәр итте. Капкаев барды. Әле эштән хәбәр бирмәс борын ук, уртага Минкин (департамент директоры), уң ягына Капкаев, сул ягына Баязитов утырган рәсемнәрен җибәрделәр. Әмма бу мәҗлестәниләрдән бәхәс ителде вә ни нәрсәгә карар бирелде, бу мәгълүм булмый калды. Мәҗлес ун көннән артык сузылса да, Капкаев үзе дә аңлап җитмәү һәм мәҗлес протоколыннан копия алып кайтмау сәбәбеннән, мәҗлес нигә карар биргәне белемсез калды. Моның өчен мөфти бик борчылды, хафаланды, Капкаевны да бик орышты. Капкаев кайтканнан соң, өч-дүрт

---

[1] Мөляхәзә – фикер йөртү.

[2] Икътидар – көч җитү, булдыра алу.

[3] Татбикъ – килештерү, яраклаштыру.

[4] Мөфти үзе дә барып күренгәч, әллә тизрәк рөхсәт бирмәсләрме өмете белә, ул вакытта мөфтинең сәламәтлеге җирендә булмаса да, үтенеп җибәргән иде. Хосусан, мин аерым сурәттә тырышкан идем. (автор искәрмәсе).

[5] Нам-нәшан – рәсми җавап.

[6] Билиттифак – берләшеп, оешып.

[7] Әксәрият – күпчелек.

кенә көн соң, менә Петроградтан Уфага шул Минкинның килүеннән телеграмма килә. Вакыйган, котелгән көндә департамент чиновнигы Тарановский белән Минкин килеп төште. Истикъбаль[1] вакытында килүнең сәбәбен булай бәян кылды: «Менә бу казый (Капкаевның үзенә ишарәт итеп) безгә Духовный собрания хакында зарур булган мәгълүматны биреп җиткерә алмады. Сез (миңа хитап итеп) Бөтенрусия мөселманнары съездына Петербургыга чакырылгансыз. Списокаларында сез дә бар[2]. Анда киткәнче сездән тулы мәгълүмат алып калу өчен ашыгып килдек», – диде. Мин: «Соң башта ук мөфти үзе күрсәткәнчә мине кабул иткән булсагыз, бәлки бу килеп йөрү мәшәкатен чикмәгән булыр идегез», – дидем. Минкин көлемсерәде: «Сине министерствода кызыллардан санийлар шул», – диде. Уфада бер атнадан артыграк торып, үзләре әйткәнчә, тулы мәгълүматны миннән, ялгыз миннән алдылар да, беркөнне миңа Минкин әйтте: «Съезд вакыты җитте инде, сине бушатабыз, гәрчә безгә тагы беркадәр мәгълүмат кирәк булса да әле, ләкин инде сине мөселман съездыннан соңга калдырасыбыз килми, әгәр барырга теләсәң, бара алырсың, ләкин мин синең урынында булсам, ул съездга бармас идем», – диде. Мин: «Алай һәркемгә дә барырга ярамаган съезд булса, ник соң рөхсәт бирдегез? Әгәр махсус минем баруым матлуб[3] булмаса, ник соң минем исемемне чакырылганнар спискасыннан сызмадыгыз», – дидем.

Минкин моңар да рәтләп җавап бирми, сүзне икенче нәрсәгә юнәлдерде. Мин дә аның куркынуына карамыйча съездга бардым. Минкинның бу сүзләрен ишетеп торган Капкаев минем башыма әллә нинди афәтләр килү ихтималын якын күреп йөргән иде. Ул-бу булмады тагын.

**Зур булмаса да, моны да гыйльми хезмәтләрдән санарга ярый дип беләм.**

Мәдрәсәи Хөсәения: Оренбургта мәдрәсәи Хөсәения ачылганнан күп тә узмый, шул ук Хөсәеневләр чакыруы белән мин Оренбургка мәдрәсәи Хөсәениягә барып йөри башладым. Уфадан Риза казый белән чакырылып баруыбызда, әле мәдрәсә иске бинасында чагында ук, аны җентекләп карадык. Тәрәккъкыйсы юлында фикерләребезне бәян иттек. Шулай ук Оренбургның башка мәдрәсәләрен дә, Каргалының бөтен мәдрәсәләрен дә карап йөрдек. Аларны ислах вә тәрвиҗ[4] юлында фикерләребезне сөйләдек. Шул баруда ук Каргалыда

---

[1] Истикъбаль – киләчәк, булачак.

[2] Бу съезд Г. Думадагы мөселман фракциясе тәшәббесе белә шул ук 1914 нче ел 10 нчы июненә чакырылган иде. Хөкүмәт чакырылачак кешеләрнең исемлеген сораган. Шуннан соң чакырылачак кешеләргә яңадан хәбәр җибәреп: «Хөкүмәткә тапшырылачак спискага исемегезне язарга рөхсәт итәсезме?», дип фракция сорады. Бәгъзеләре шуннан куркып исемнәрен яздырмадылар. (автор искәрмәсе).

[3] Матлуб – теләнгән, таләп ителгән.

[4] Тәрвиҗ – тарату, алга җибәрү.

Сәгыйд бабадан калган хәрабә[1] хәленә түнә язган йортын да карап, бумың асаре кадимә[2], безнең өчен тарихи кыйммәте булындыгыны Хөсәеневкә сөйләдек. Без икенче барганчы мәрхүм ул йортны төзәттергән иде. Шул ук Фарштатта Адамовага ачып биргән кызлар мәктәбен дә барып карап, нәмунә[3] өчен кыз балалар эшләгән кул эшләреннән байтак нәрсәләр алып кайттык. Алар күп елларга кадәр бездә выставка хезмәтен күрделәр. «Әхмәд бай» рисаләсендә 22 нче битендә Риза казыйның «иптәшебез илә» дигәне, иптәше мин идем. Ни мөляхәзә[4] беләндер иптәше кем икәнен, ягъни минем исемемне әйтәсе килмәгәндер. Ул елларда Оренбург вә Каргалының берәр, икешәр муллаларыннан башкалары искелек тарафында иделәр. Араларында сүзгә үтештә «татар хатибы» аталганнары да бар иде[5]. Алар Хөсәеневләр ачкан зур мәдрәсә вә алар тарафыннан ачылган күп кенә ысулы җәдидә мәктәпләре хилафына куәтле агитация ясыйлар иде. Хөсәеневләр үзләре хакында бик авыр сүзләр вә бик зур ифтиралар[6] ишетсәләр дә, аңар илтифат итмиләр. Әмма алар ачкан мәдрәсә, мәктәпләрдән халыкның күңеле сүнмәсен, балаларны файдалы гыйлемлекләрдән мәхрүм итмәсеннәр өчен гаммәи халык – масса алдында хакыйкатьне ачып бирүне, тегеләрнең вәсвәсәләреннән[7] коткаруны телиләр иде. Бу хезмәтне күрү өчен, ул заманның нөфүзле[8] адәмләреннән булуны хисап итеп, безне чакырганнар иде. Без дә шуның өчен һәр барган урында мәктәп вә мәдрәсәләрдә вә хосусый мәҗлесләрдә җыелган халыкка хакыйкать вә мәслихәтләрне төшендерергә, вәсвәсәләрне бетерергә тырыша идек. Муллаларның беркадәресе, безнең риясәтебездән[9] куркып, безгә каршы чыкмасалар да, әмма batыррак муллалар вә сәүдәгәрләр безгә дә күп игътиразлар[10] кылалар, без дә аларга тиешле җавапны бирә идек.

Мәсьәләне тиешле юлына салыр өчен байтак сөйләргә, кайбер вакыт тиргә батарга мәҗбүр була идек. Иптәшем дә тавышы зәгыйфь һәм үзе дә хатиб[11] булмаганны бәһанә[12] итеп, бу хезмәтләрне күбрәк миңа йөкләтә иде. (Гани бай рисаләсе 182 нче битенәрәк). Төрле вакытта мәдрәсә имтиханнарына да чакырылып, аның алга

[1] Хәрабә – җимерелгән төзелеш, йорт калдыклары.
[2] Асаре кадимә – археологик истәлекләр.
[3] Нәмунә – үрнәк, өлге.
[4] Мөляхәзә – фикер йөртү.
[5] Мәсәлән, Шакир ахунд кебиләре (автор искәрмәсе).
[6] Ифтира – яла ягу.
[7] Вәсвәсә – котырык, шик, хәвеф.
[8] Нөфүз – сүз үтемлелек, авторитет.
[9] Риясәт – рәислек итү, башлык булу.
[10] Игътираз – каршы сөйләү, кире кагу.
[11] Хатиб – яхшы оратор.
[12] Бәһанә – ялган сәбәп.

баруларына, шәкертләрнең артык игътимад[1] галәлнәфес итмәй, заман вә әхваль ирек биргәне кадәр истикмальләрен[2] иң алдагы планда тотуларын ихтар[3] идем. Бәгъзән мөгаллимләр, мәсәлән, Муса Бигиев вә башкалар тарафыннан бик җитди игътиразларга, Фатыйх Кәрими тарафыннан шәкерткә истикмаль белән тәүсыям[4]: «Чәчәкләргә гүзәл булыгыз, хуш исле булыгыз!», димәк кебек имеш мәзмумны[5] да кыяс[6] мәгальфарикъ[7], җанлыны җансызга чагыштыру кебек игътиразлар да ишетә идем. Шул ук мәдрәсәи Хөсәения турысында кай вакыт үз тәэлифләрем[8] хакында да Хөсәения мөгаллимләре белән фикер алыша идем. (Ул вакыт Хөсәениядә мөгаллим булган Җамал иптәш Вәлиди бу хосусларны яхшы хәтерли торгандыр.) Әхмәд мәрхүм вафатыннан соң, энесе Мәхмүд үзе имтихан вакытларында Казанда калып, үз урынына имтихан мәҗлесләрендә хәзер булуым өчен мине махсус Оренбургка җибәргән иде. Мәхмүд Хөсәенев тарафыннан шул ук мәдрәсәгә мөдирлеккә дә чакырылган идем. Ләкин төрле сәбәпләрдән[9] мин бара алмадым.

**Уфада газета чыгару эше:** Уфада бер татар газетасы да булмавы, Уфа шәһәре дә, тирә-юне өчен дә зур кимчелек иде. Бу сәбәп белән анда бер татар газетасы тәэсисе өчен учредительләр табу, пай акчалары җыюга, шул эшнең инициаторы Җантуринга күп булышлык иткән идем. Мәсәлән, зуррак дәүләт ияләренә зуррак ярдәм итәргә дәляләт итеп күндергән идем. Үзем дә пай акчасы илле сум биргән идем. Рөхсәт тә алынды, мөхәррир дә билгеләнде (Вагыйз Нәүрүзев). «Тормыш» исемендә газета да барлыкка чыкты. Мәкаләләр дә язгаладык. Ләкин зур ярдәм итүче Садрый Нәзирев белән мөхәрриренең ялгыш хәрәкәтләре сәбәбеннән, пай акчаларыбыз кайтарылмаганы хәлдә үк, тиз көннән газета коллегия кулыннан хосусый бер сәүдәгәр Гыйбадулла Госманов кулына күчеп, мөхәррире дә башка кеше Закир әл-Кадыйри булды. Бу соңгы кеше хосусый бер аңлашылмау өчен миңа хәтере калып, җәмгыятьләрдә һәм мәкаләләре белән газеталарда минем хилафыма хәрәкәт иткәләде.

**Туберкулез белән көрәшү өчен төзелгән Бөтенрусия җәмгыяте (Лига)ның Уфа шөгъбәсе.**

Туберкулез = чахотка нәрсә? Аны сөйләп торасы юк, һәркем аны белә. Җәмгыять ни өчен төзелгән, исеменнән үк мәгълүм. Ни өчен Русиянең бик

---

[1] Игътимад – таяну, ышану.
[2] Истикмаль – төгәлләү, кимчелекләрне бетерү.
[3] Ихтар – искәртү, кисәтү, дикъкатен тарту.
[4] Тәүсыя – киңәш бирү.
[5] Мәзмум – өстәлгән, арттырылган.
[6] Кыяс – ошату, чагыштыру.
[7] Мәгальфарикъ – аерма белән.
[8] Тәэлиф – китап (әсәр) язу.
[9] Бу хосуста Фатыйх Кәрим «Вакыт» газетасында язган иде. (автор искәрмәсе).

күп шәһәрләрендә, шулар җөмләсеннән Уфада да Лига шөгъбәсе төзелде. Бу турыда бер-ике генә сүз әйтү, аның белән бик якын таныш түгел кешеләр өчен зарар итмәс. Моны укучылар, шаять, гафу итәрләр. Чахотка адәм нәселендә газаплый торган озын авыруларның иң йогышлысы, иң куркынычлысы, иң күп таралганы (100 гә 90 кешедә чахотка микробы була), иң күп үтерүчесе (адәмләрнең 7 дән берсе чахотка белән үлә) булганга күрә, һәр шәһәр халкы диярлек аның белән көрәш Лигасының шөгъбәсен төзегәннәр һәм төзиләр. Хосусан, кымызлы якларга, шулар җөмләсеннән Уфага вә әйләнә-тирәсенә Русиянең һәр тарафыннан бик күп чахотка белән авырый торган кешеләр киләләр. Алар әүвәл Уфаның үзендә беркадәр торып микробларны чәчәләр, аннан соң әйләнә-тирәдәге авылларга таралып, анда да хифзыссыйхәтнең[1] ни икәнен белмәгән, бинаән галәйһи[2] аннан саклана белмәгән халыкка авыруларын йоктырып калдыралар. Алар арасында бу авыру котычкыч рәвештә таралган һәм һаман тарала бара. Моны күргәч, Уфа докторлары вә интеллигентлары вә аңлы адәмләре дә әйтелгән Лиганың шөгъбәсен төзеделәр. Русларга караганда, татар-башкортлар арасында бу авыру бигрәк тә таралганга күрә, Уфа мөселманнарының бу эшкә җитди рәвештә катнашуларын сорадылар. Правлениясенә дә эш эшләрлек кешеләрне сайлауны тиешле күрделәр. Шөгъбә правлениясенә күбрәк докторлар, земство әгъзалары, мөселман интеллигентларыннан Җантурин белән юрист Ибраһим Әхтәмевне вә аларның дәләләте буенча мине дә сайладылар. Алар сөбатлы[3] дәвам итә алмасалар да, правлениядә минем дәвам итүемне үтенделәр. Правления дә шуның белән тәмам канәгатьләнә иде. Правления эш башлап җибәрер өчен Уфаның, Бөтенрусиядән чахоткалылар җыела торган урын булуны күрсәтеп, мәркәздән дә күп кенә акча алды һәм һәр елыны ала килә иде. Махсус чахоткалы авыруларны карар өчен Капкаев Гыйният казый пулатына амбулатория ачтык. Исеменнән кешеләр нәфрәтләнмәсен өчен без дә исемне французча «диспансер» дип атадык. Спецдоктор вә төрле лязим[4] булган әсбаплар китерттек. 3 нче стадиясенә ирешкәннәрне, башкаларга йоктырмас өчен, Казан урамында зур йорт иҗарәгә[5] алып «убежище» ачтык. Амбулаториядә һәркөн правления әгъзалары дежуровайт итеп, авыруның хәле белән яхшы таныш булу өчен сораша вә тереклек итә торган урынны да регистровайт итә идек. Дәүләт ияләреннән нык кына итеп басып сорап, зур-зур иганәләр ала идек. Иптәшләр – правления

---

[1] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[2] Бинаән галәйһи – шуның өчен, шуңа күрә.
[3] Сөбатлы – биредә: даими, тотрыклы мәгънәсендә.
[4] Лязим – тиеш, кирәк.
[5] Иҗарә – вакытлы файдалану, аренда.

әгъзалары – урыс дәүләтлеләренә күбрәк тә мине җибәрәләр иде. Доктор Куржанский шикелле шаярып сөйләшергә яратучы муллалары: «Без синең шикелле әрсезлекне, оятсызлыкны булдыра алмыйбыз», – дияләр иде. Турысын әйтергә кирәк, татар халкы урысларга караганда күбрәк һәм ансатрак ярдәм итәләр иде. Урыс байларыннан шул әрсезләнмичә, оятсызланмыйча ярдәм иттерү читен иде. Һәр елны: «Ак чәчәк бәйрәме» ясап, ул көнне 60 лап кружка белән руслардан, мөселманнардан күбрәге яшь-җилкенчәкләрдән чәчәк саттыра идек. Өяз шәһәрләренә, зуррак заводларга, хәтта Борай шикелле зуррак авылларга да җибәрә идек. Киноларда «Ак чәчәк» файдасына сеанслар бирдерә идек. Ул көнне зур бәйрәм ясап, атлы арбалыларны да «Ак чәчәк» белән зиннәтләп, урамнарда йөртә идек. Правления әгъзаларыннан табиблар, руслар аудиторияларда, училищеларда мин һәм ул вакыт Уфага ялгыз мөселман табибиясе булган Рауза Губиевадан үтенеп, мөселман мәдрәсәләрендә чахотка вә аннан саклану хакында дәресе гомумиләр укый идек. Правления әгъзалары без барыбыз да буш, өҗрәсез[1] хезмәт иттек. Ялгыз спецдокторга гына өҗрә бирелә иде. Бу авыру шәһәр читләрендә начар шараит эчендә тереклек итүчеләр арасында бик таралган булганга күрә, аларга җәмгыять әгъзаларының күбрәге мөселман хатын-кызларын йөртеп тәфтиш[2] иттерә идек. Квартиры бик начар булганнарны яхшырак квартирга чыгарып, караваты юкларга карават, утыны юкларга утын, өст-баш вә аяк киемләре юкларга шуларны алып бирә идек. Моның өстенә бик фәкыйрь, ашау-эчүләре бик начарларны аерым регистровайт итеп, аларга һәркөн бер бутилкә сөт, бер булки калач өләштерә идек. Мәркәздән дә, шәһәрнең үзеннән дә, өязләр, заводлар, хәтта зуррак авыллардан да мул-мул ярдәм килү белән безнең кулыбыз бик иркен иде. Эш шулай була торса да, әмма безнең ярдәмебез күбрәк шәһәрдә (Уфада) торучыларга була иде. Чит шәһәрләрдә, завод һәм авылларда торучыларга амбулаториябездә буш карау зарур[3] булганнарына буш дәва бирүдән узып булмый иде. Фәкать шәһәрнең кайсы гына амбулатория, больницаларына чахоткалы кешеләр күренсә, безнең амбулаторияга җибәрәләр иде. Без Уфа шәһәреннән башкаларга да мөмкин булган юл белән ярдәм итүне касд[4] итеп, һичбулмаса гыйльми юл белән булса да, чахотка бабында ул вакытта иң мәгъкуль[5] күренгән А.А. Якир рисаләсен[6] русларга шул хәленчә

[1] Өҗрә – эш хакы, хезмәт хакы.
[2] Тәфтиш – тикшерү.
[3] Зарур – тиешле, кирәкле, котылгысыз.
[4] Касд – ният, теләк.
[5] Мәгъкуль – урынлы.
[6] Биредә сүз А.А. Якирның «Туберкулез как народное бедствие и борьба с ним» (М., 1912) исемле китапның тәрҗемәсе хакында бара.

русча, мөселманнар өчен минем карамакта Фәррәхетдин Әхмәдевтән бик җиңел татарчага тәрҗемә иттереп, 1914 нче елда 15 мең нөсхә бастырып, бөтен Уфа виляяте фәкыйрьләренә волостьлар аркылы җибәреп, бушлай тараттык. Китапның тышына болай язылган иде: «Чахотка белән көрәшү өчен төзелгән Бөтенрусиянең Уфа шөгъбәсе тарафыннан нәшер ителде. А.А. Якирәдән тәрҗемә. Туберкулез вә аның гомуми халыкка бәла булуы һәм аның белән көрәшү. Фәррәхетдин Әхмәдев тарафыннан тәрҗемә ителде. Хәсәнгата Габәши нәзарәте[1] белән табгы ителде». Китапның ичке як башына минем тарафтан болай язылган иде: «Назыйрдан[2]: мөселман карындашлар! Чахотка нинди куркынычлы авыру икәнен барыгыз да беләсез! Хәсрәтләнерлек хәл шулдыр ки, ошбу соңгы елларда бу куркынычлы авыруның без, мөселманнар арасында бик күбәеп баруы тәфтиш вә тәҗрибә белән мәгълүм булды. Хосусан кызлар, яшь хатыннар, укучы шәкертләр, дөнья көтүче яшьләр арасында күбрәк күренүе бигрәк хәсрәтләнерлек хәлләрдән икәнен уйласагыз, әлбәттә, үзегез дә беләсез. Элекке заманда чахотканы нәселдән килә торган, дәвалап булмый торган авыру дип хисаплыйлар иде. Әмма тыйб[3] фәне голямасының[4] хакыйкынча алай булмаганы, бәлки кешеләрнең тиешенчә тереклек итмәгәнлекләреннән чахотка була башлаганы, яисә тиешенчә сакланмаганлыкларыннан башкалардан булмаганы ачык беленде. Шулай ук бу авыру эләккән кешеләр форсатны үткәрмичә дәвалану чарасына керешсәләр, сәламәтләнеп була икәне дә ачык беленде. Чахотка авыруы адәм угылларына бик зур дошман хөкемендә, дошманнан саклану, аны дөрес тану вә лязим[5] тәдбирләрне[6] кылу белән генә мөмкин. Сакланганны ходай саклаган дигән бабайлар сүзен хәтерегездән чыгармагыз. Сезгә бу җөмләдә бер ярдәм күрсәтү ният хәйриясе белән, чахотка белән көрәш өчен төзелгән Бөтенрусия җәмгыятенең Уфа шөгъбәсе мөселман әгъзаларының үтенүе буенча мәзкүр[7] җәмгыятьнең иң яхшы күреп нәшер иткән китабыннан, мөселманнар да мәшәкатьсез файдалансыннар өчен, төрки телгә тәрҗемә кылдырып нәшер итәдер, файдаланыгыз! Сәламәт булыгыз карындашлар!» Хәсәнгата.

Без, тугрысы мин, моның белән генә дә канәгатьләнмәдем, бәлки авыл хуҗалыгы җәмгыятендәге шикелле монда да бер китаплар гына тарату җитмәгәнен вә бәлки төрле лозунглар вә мәүзугъларда[8] плакатлар,

---

[1] Нәзарәт – күзәтү, контроль.
[2] Назыйр – идарә башында торучы, мөдир.
[3] Тыйб – медицина.
[4] Голяма – галимнәр.
[5] Лязим – тиеш, мәҗбүри.
[6] Тәдбир – тиешле чара.
[7] Мәзкүр – югарыда әйтелгән.
[8] Мәүзугъ – тема, проблема.

кагыйдәләр, афишалар, хәтта беркөнлек газеталар да бастырып таратуны, Лига исеменнән өязләргә кымыз районнарына сәйяр[1] мөселман медиклары чыгарып йөртеп, алардан дәрсе гомумилар укыту, выставкалар ясатуны кирәклекне дәгъва һәм исбат иттем. Правлениядa минем дәлилләремә канәгать итеп, гаризамны кабул итте. (Плакатлар, кагыйдәләр, афишаларның беркадәресен монда куям). Ләкин мөселман медиклары табуны һәм аларны чакырып китерү эшен правления миңа йөкләде. Миндә ул вакытта миңа мәгъкуль ике медик студент: Казан[нан] Әхмәтҗан Мостафа угылы мәрхүм Габдрахман Мостафа белән Уфа[дан] Хәйрулла Госманов угылы Габделбарыйны күрсәттем. Боларның берсе Казанда, берсе Мәскәүдә иделәр. Биззат[2] һәрикәвесенә үзем язып чакырдым. Һәрикәвесе килделәр. Габдрахман Мостафаны Бәләбәй өязенә кымыз районнарына, Габделбарый Госмановны Златоуст өязенә чыгарып, ничә авылда дәрсе гомумилар укытып, выставкалар төзеттек. Чахоткадан кем курыкмый? Болар үзләре йөреп кайтканчы ук халыктан бу эштән мәмнүн булганлыкларын белдереп, Лигага, хосусан миңа бик зур рәхмәтләр яудыра башладылар. Хосусан, боларның мөселманча яхшы укыган шәкертләр булганлыкларыннан һәм ачык чырайлы, гүзәл холыклы, адәм сөюче булганлыкларыннан, мөселманнар үзсенеп, мәхәллә имамлары да ис сенеп, әйләнәтирәләрендә ераклардан да дәрес тыңларга, выставка карарга киләләр. Гаять һәвәс белән тыңлыйлар. Выставканы да гаять дикъкать белән карыйлар. Күңелләренә килгәннәрне барын да сорап, боларны җөдәтеп бетерәләр иде. Болар да, тел вә тавыш кызганмаенча, аларны тәмам канәгатьләндерә иде. Һәр җирдә дәрес ике көнгә билгеләнеп, бер көне ирләргә, икенче көне хатыннарга махсус иде. Хатыннар да, үзләре генә булганлыктан, бик иркенләп, тартынмыйча, рәхәтләнеп тыңлыйлар иде. Шул сәбәпләрдән халыкның мәмнүниятенең чиге юк диярлек иде. Шушы сәбәпләрдән чахотка вә аннан саклану хакындагы белемнәр (гыйлемләр) без уйлаганнан ун өлеш, хәтта йөз өлеш артык тарала иде. Бу студент-медиклар шулай нәүбәт белән губернаның һәр өязенә йөреп чыгачаклар иде. Фәкать җәйге эш вакытларында тыңлаучы аз булыр мөляхәзәсе[3] белән, эш вакытларында тукталып торып, киләсе октябрь башыннан йөри башлаячаклар иде. Ләкин шул бәдбәхет сугыш бу эшләрне дә тәмам чуалтты. (Бу хакта булган әдәбиятка, хосусан Габдрахман Мостафа хатына күз салыгыз).

Бу тәрҗемәи хальне укучылар бу хезмәткә ни күз белән карарлар. Анысын белмим, әмма үзем бик мәмнүнмен. Татлы ядкәрләремнең зурларыннан са-

---

[1] Сәйяр – хәрәкәт итүче, күчмә.
[2] Биззат – турыдан-туры үзе, башкаларга тапшырып түгел.
[3] Мөляхәзә – фикер йөртү.

ныйм. Яшерен калдырмаска тиешле янә беркадәр гыйльми вә иҗтимагый хезмәтләрем бар. Ләкин хәзергә шушы язылганнар белән туктыйм.

1928 нче ел, 17 нче гыйнвар.
Кече Солабаш авылы.
Хәсәнгата Габәши.

Бу тәрҗемәи хальнең әүвәлге нөсхәсенә Габидулла иптәш Шонаси тарафыннан язылган сүзләрне гайнан[1] күчерәм: «Татар тарихчыларыннан Хәсәнгата Габәшинең тәрҗемәи хальне укып чыктым. 1908 нче елдан башлап, 1925 нче елга чаклы Уфада яшәгәнлегемнән шуны әйтә алам, Х. Габәшинең 1908 нче елдан башлап Уфада эшләгән гыйльми, иҗтимагый, тәрбияви эшләре шушы тәрҗемәи халендә язылганча дөрес, хакыйкатькә муафыйк. Шуны тасдыйк[2] итәм».

1928 нче ел, 19 нчы гыйнвар.
Казан.
Имза: Габидулла Шонаси.

**Чыганак**

Казан федераль университеты Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. 1542 т. Х. Габәши. Тәрҗемәи халем. Солабаш, 1928. 33 б. Нәсех.

*Гарәп графикасыннан кириллицага күчереп, кулъязманы басмага әзерләүче:*
***Рәйсә Гамир кызы Шәрәфиева,***
*Казан федераль университеты Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге баш библиографы*

[1] Гайнан – бөтенләй, тулысынча.
[2] Тасдыйк – дөреслеген тану.

УДК 811.512.145´351

*Нигъмәт Хәким*

# ИМЛЯ ХАКЫНДАГЫ КОРЫЛТАЙ КАРАРЛАРЫ ТУРЫНДА

Предлагаемая вашему вниманию статья Нигмата Хакима посвящена вопросам татарской орфографии на основе арабской письменности. В ней, в частности, рассматриваются постановления II Всероссийского собрания мусульманских учителей, указываются их недостатки. Публикуется по изданию: Укытучы. 1918. № 3. С. 82–84.

**Ключевые слова:** Нигмат Хаким, орфография татарского языка, арабская письменность.

Мин «Бөтен Руссия мөселман укытучы вәкилләренең икенче съездында имля хакында биргән карарлары» турында берничә сүз язарга үземне мәҗбүр белдем.

Имля мәсьәләсе, миллият нигезе ноктасыннан караганда, әһәмиятле мәсьәләләрнең дә иң әһәмиятлесе. Чөнки миллият тел нигезенә, тел үзе имля нигезенә каралган була. Имля ничаклы нык, таза булса, тел дә шул чаклы нык һәм таза була. Юкса, юк. Менә шул сәбәпле бу мәсьәләгә җиңел, өстән генә карап үтәргә мөмкин түгел. Мәсьәләнең астын өскә актарырга, аның белән генә дә туктамыйча аст белән өст арасындагы иң кечкенә ноктaларынача, инәдән җебенәчә, нечкәләп тикшерергә тиеш. Мин үземчә нечкәләп тикшергәннең соңыннан түбәндә күрсәтеләчәк кимчелекләрне таптым. Казандагы карарларның имля төзәлүгә зур бер адым икәнен сөйләп торуы да артык саналганга, мин карарларның яхшы якларын санап та тормыйм, бәлки туптуры җитешмәгән якларын гына күрсәтәм.

1. Җыелышның «тел вә әдәбиятыбызны һәм хәрефләребезне тәгъйин» кылуына кушылырга ярый. Мәгәр хәрефләребезне бүлгәндә «тавышлы һәм тавышсыз хәрефләр» дип йөртелгән истилахларга кушылып булмый. Чөнки хәрефләрне болай атау төбе-тамыры белән методикага хилаф. Ысул саутиядә хәрефләрне өйрәткәндә хәрефләрнең аваз (тавыш)ларын нигез итеп алына, хәреф тавышның галәмәте дип йөртелә. Бер ысул саутиядә генә түгел, гомумәдә, хәреф тавышның галәмәте итеп йөртелә. Ә монда, ысул саутиянең нигезе булган авазлар юкка чыгарыла – 25 хәреф «тавышсыз хәрефләр» диелә. Әгәрдә хәреф тавышсыз булса, (монда үзеңне бала итеп хисапларга кирәк) тавышы булмаган хәрефне ничек ишеттерербез? Мәсәлән: «б, л» галәмәтләрен аваз аркылы өйрәтмичә, ничек өйрәтербез? Ымлапмы, авыз кыйшайтыпмы? Тавышлары булмаган галәмәтләрне бер-

берсеннән ничек аертырбыз? Ул галәмәтләр аркылы сүзләрне ничек ишеттерербез. Без балаларны язуга өйрәткәндә бит: «Бу сүздә ничә аваз бар, шул авазларның галәмәтләре булган ничә хәреф языла?» дип сорыйбыз. Менә мондый сораулар белән теге «тавышсыз хәрефләр» капма-каршы килә. Хәрефләрне тавышлы һәм тавышсызга бүлгәндә: «Бу сүздә ничә тавыш юк. Юк тавышларның галәмәтләре ничәү языла? – дип сорарга туры килә түгелме? Юкса, чеп-чи тнакс була түгелме? Әлбәттә, моңа каршы: «Бу бит вак мәсьәлә, фәлән»...? –дип әйткәннәр дә булыр. Бу билгеле, мәгәр моның мәсьәләсе төймәдәй кечкенә күренсә дә, бәласе дөядәй бик зур шул. Зарарлы микроблар үзләре, өстән караганда, күренмәсәләр дә, аларның күрсәткән зарарлары караңгы төндә күренерлек дәрәҗәдә зур була. Менә бу мәсьәлә дә шуның нәкъ үзе инде. Дөрес, кайберәүләр тагы гарәпләрнең («вә җә тәсмиядә ийрад вә итрад вә эннакс шарт түгел») дигән сүзләрен әйтерләр, сукыр тәкълид белән русларның «гласный, согласный хәрефләр» йөртүләрен дә китереп бастырырлар, әйтсеннәр, бастырсыннар, бик яхшы. Мәгәр мин гарәпләрнең ул мәшһүр сүзләренә, мөмкин булганда, «вә җә тәсмиядә итрад вә имһакс шарт» дип, истисналы бер җөмлә кушасым килә, килә генә түгел, кушарга тиеш. Русларны мисалга китерүгә каршы: «безгә торып русларның ясаган хаталарын тәкрарлау лязыйммени»? – димен. Бу бер. Икенче, «согласный хәрефләрне» тавышсыз хәрефләр дип аңламыйлар да, аңлатмыйлар да. «Согласный дигәннән тавышсыз мәгънәсе аңланмый, согласный хәрефләргә «тавышсыз хәреф» дип мәгънә бирү фәкать аңламаудан гына килгән бер нәрсә, сукыр тәкълидлек кенә. 12 бит 11 нче карарларында «тавышсыз хәрефләр» дигән истилахларын үзләре дә боза. «Вау, йа» галәмәтләренең мәд хәрефе булмыйча, аваз хәрефләреннән булып килгән чакларында да «тавыш хәрефләре» диелгән.

2. «Имляда төп имлямыз» дигән башлангыч астында 1–2 нче саннарда «һәр авазга бер генә хәреф булдырырга» карар кыйлынганы кебек, «һәр хәрефкә бер генә аваз табарга» да карар кыйлынырга тиеш иде. Юкса, төп әмәл бөтен булып җитә алмый.

3. Мәд хәрефләре хакында: «ишетелгәнчә язу хәзерге көндә түбәндәге алты мәд хәрефләре белән гамәлгә куелыр: а – ә, у, о, ы, э «бара – бәрә, өчен, тозак, ике, алты, бирде, барды, бирделәр, бардылар, су, тун, сүз, түз дигән сүзләрдәге кебек» диелгән. Монда «суз, сүз» сүзләрендәге ике авазга йөретелгән «вау» галәмәте белән «бәйли, сайлый» сүзләрендәге ике авазга йөретелгән «йа» галәмәтен ни өчендер мәд хәрефләреннән итеп саналмаган, хәлбүки болар «у, о, ы, э» галәмәтләреннән дә озын һәм ачыграк булып әйтелә. Әгәрдә «у, ы» галәмәтләре «тау, тәү, ай, бәй» сүзләрендәге кебек аваз хәрефләренә дә йөртелгәне өчен мәд хәрефләреннән саналмаган булса, монысы тагы гаҗәеп бер матзаксызлык булачак. Ул чакта бары «вау, йа» хәрефләре аваз

хәрефләре дә, мәд хәрефләре дә булып йөртелә дияргә генә кирәк иде. Мәд хәрефләре хакында бөтен имлячыларның хата аңлауларын, хата тәгрифләрен (руслар вә гарәпләр дә шунда керә) язарга теләсәм дә, сүз озынаюдан куркып, аны язуны икенче бер вакытка калдырып торам.

4. «ы – э» хәрефләре сүзнең уртасында ябык хаҗәләрдә һәм мәгънә бозылмаслык урыннарда язылмаслар. Әмма зарур урыннарда мәркәзгә куелып «,ٔ» рәвешендә язылырлар» диелгән. «Хатын, уен» кебек «н» га беткән сүзләрдә «,ٔ» галәмәтләрен язу тиеш булса кирәк. Әгәр дә «төп сүзнең уртадагы хәрефләре бөтен көенчә саклана» дигән... кагыйдәдән истисна ясамыйбыз дисәк, мәсәлән «Хатны, уйны» рәвешендә язылган сүзләрне (Хатны, Хатыны, Уйны, Уйыны) рәвешләрендә укылып саташтырышачак. Кеме, нәрсәсе? сүзләренә җавап булган теркәгечләр белән кемне, нәрсәне сорауларына җавап булган төшем тәмамлыгы буталачак.

Аннан соң өченче карарны... язылмастан элек асыл саутиядә хәрефләрнең ялгыз хәлләрендәге авазлары сәкен белән укылмый, әллә нечкә өтер белән укыламы? икәнен тикшереп бер карарга киләсе бар, чөнки «ы – э» авазларының сүз уртасында язылуы-язылмавы шул нигезгә корыла. Мин хәзергә бу хакта сүз озайтмыйм, вакыт сыйдырса, киләчәктә бу турыда озаграк туктарга ниятем бар.

5. Һәмзә галәмәтенең «йа» астына куелып язылуы муафыйк булмаса кирәк.

6. «Язып, килеп, килсен (йазп, килп, килсн) алр, белр, хатн, алтн, утр, салкн, сарн, кызк, сызк... дигән сүзләрдә булган кебек ябык хаҗәләрдә мәд хәрефләре язылмас» дигән карар хата. Монда нинди мәд хәрефләре язылмавы күрсәтелмәгәч, (сигез) мәд хәрефе барсы да керә. Бу кагыйдә буенча «тук, кил, кул, бал, йаз» кебек ябык хаҗәле сүзләрдә мәд хәрефләре язылмаска тиеш. Ул вакыт югаргы сүзләрне «тл, кл, гл, кл, бл, эз» рәвешендә язарга кирәк була. Мин, имля мөтахассислары исеменнән төзелгән мондый хата карарларны күргәч, бер юлы шашып калдым. Әллә үзем ялгыш аңлыйммы икән? дип үз-үземә дә сораулар биреп, каткат тикшереп карадым. Мәгәр, караган саен ялгыш аңламауыма ышаныч арта гына барды. Мотахасисларның мондый зур хаталарына меңнәрчә тасыф кылдым. Моның белән бергә имляны нык саглам һәм үзгәрми торган бер нигезгә салу өчен тиздән тагын бик зур җыелыш ясау лязем икән дигән уйга килдем.

Аннан соң өченче карар булгач, бу карар артык. Әгәр дә кагыйдә итеп ясалса, кагыйдәдәге «мәд хәрефләре язылмас» дигән урынга “,ٔ” хәрефләре язылмас дияргә кирәк булыр. Моның өстенә «зарур һәм мәгънә» бозылырлык урыннарда гына язылыр дигән истисна арттырылыр.

7. Беренче имкян булгач та һай рәсмия урынына фәтхәле әлифтән ясалган шул «мәдле әлиф галәмәте кулланыла башланыр» диелгән җыелышның бу карары югарыдагы: «һәр авазның үзенә каршы хәреф булындыру»

дигән төп теләктәге үз карарына хилаф[1].

8. 12 нче кагыйдә бик томанлы рәвештә язылган: Кагыйдә болай: «Сүз башындагы һәмзәләр – «мәдле әлиф», «һәмзә вә һай рәсмия бүтән урыннарда әлиф сурәтендә язылырлар». Ялгышмасам, карарны ачыгырак гыйбәрә белән әйткәндә, болай булырга тиеш: «Сүз башындагы һәмзәләр калын сүзләрдә «мәле әлиф», нечкә сүзләрдә «һай рәсмия» рәвешендә, бүтән урыннарда «әлиф» сурәтендә язылыр». Мин шулай аңладым, шулай аңлавым хата булмаса, бу кагыйдә буенча «тарта, тәртә, бара, бәрә, була, бүлә» сүзләрен бары өч шәкелдә «тарта, бара, була» рәвешләрендә генә язарга тиеш булып кала. Менә бу, минемчә, бик зур хата, гафу ителмәслек рәвештә булган зур бер хата. Бердән, ишетелгәнчә язуга төбе тамыры белән хилаф. Икенчедән, бу кагыйдә буенча язганда сүз уртасында ике авазга бер хәреф куллану була. Ә менә бу, ягъни ике авазга бер хәреф куллану съездның: «Бер авазга ике хәреф кулланылмас» дигән үзенең төп теләгенә дә каршы бер адым. Өченчедән, съезд үзе: «Калынлык-нечкәлектә аваз хәрефләре мәд хәрефләренә иярер», – дип карар ясаган. Ә монда шуңарга каршы барыла. Чөнки нечкә һәмзә үзе белән калын һәмзә авазының икәвесенә бер генә галәмәт куелганда бер сүзнең калынлык, нечкәлеген кайдан белербез? Хәлбуки, калынлык, нечкәлектә аваз хәрефләре мәд хәрефләренә иярә дибез. Мәсәлән: бара рәвешендә язылган сүзнең «бара»мы, «бәрә»ме икәнен ничек белербез? Димәк, җыелышның 8–12 нче карарлары үзләреннән-үзләре төшеп кала.

*«Укытучы». 1918. № 3. Б.82–84*

*Басмага әзерләде:*

***Асылгәрәев Шәрифҗан Нурлыгәрәй улы,** филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомум лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

---

[1] Һәй рәсмия галамәте урынана кулланулы мадлуб улган галәмәт «мәдле әлиф» түгел, бәлки башка галәмәттер. Әлегә укытучы ясалган матбагада ул галәмәт булмаганлыктан күрсәтелә, ди (идарә).

УДК 398=512.145

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ЮЛЫ УҢНЫҢ ЭШЕ УҢ, ЯКИ САМАРАГА СӘЯХӘТ

Статья представляет собой краткий отчет по фольклорным материалам экспедиции в Самарскую область, предпринятой Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ в 2014 г.

**Ключевые слова:** татары Самарской области, комплексная экспедиция, произведения татарского народного творчества.

Милләттәшләребез аяк басмаган урын җир йөзендә юктыр ул. Тарихчы галим Дамир әфәнде Исхаков әйткәнчә, татарлар кебек сибелеп яшәгән башка халыкны Рәсәйдә табып та булмый. Халкыбызның бай тарихын, мәдәниятен төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез күп гасырлар буена барысы бергә бар иткән. Шуңа да рухи байлыгыбыз татарны татар итеп саклый торган бергәлектә, бөтенлектә генә бар тулылыгы белән ачыла.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үзенең 75 еллык эшчәнлеге дәвамында татар халкының рухи һәм милли-мәдәни мирасын барлау, туплау һәм өйрәнүгә зур игътибар бирә килә. Халкыбыз вәкилләре белән очрашып тору, ә моның өчен фәнни экспедицияләр уздыруның әһәмияте тел, әдәбият, фольклор, сәнгать фәннәре үсеше өчен әйтеп бетергесез. Зур мирасның үз вакытында тарихка теркәлеп калуы халкыбыз бөеклеген фәнни яктан раслый. Милләт җәүһәрләрен барлау максаты белән соңгы елларда гына да Институт тарафыннан Актаныш (2009), Түбән Новгород, Курган, Апас (2010 ел), Кукмара, Стәрлебаш (Башкортстан), Бәрәңге (Мари Эл), Оренбург (2011), Чүпрәле, Удмуртия Республикасы (2012), Әстерхан, Пермь, Мамадыш (2013) төбәкләренә комплекслы экспедицияләр оештырылды, тупланган материаллар исә соңгы берничә елда «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» исемле сериядә аерым китап булып басыла килә.

Бөек Тукаебыз әйткәнчә, «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул». Элекке дәверләрдән туплана килгән тормыш тәҗрибәсе, зирәк акыл, тапкыр фикерләр, тәрбия алымнары, әхлак нормалары, күңел дөньясының, матурлыкның үзенчәлекле чагылышы, хәерле гамәлләрне аңлау-тоемлау рәвеше, дин, фәлсәфә, хәтер – болар бар да халыкта яши торган тиңсез хәзинәләр. Халык бар икән, димәк, аның күңел байлыгы да исән-сау, ул байлык, тарихның үзе кебек, һаман үсеш-үзгәрештә. Галимнең бурычы – әнә шул хәрәкәтнең кабатланмас чаткыларын, әһәмиятле мизгелләрен билгеләп калу, бөртекләп җый-

нау, теркәү, өйрәнү аша мөһим ачышлар ясау, халыкныкын халыкка кире кайтару.

Шушы максатларны тормышка ашыру уе 2014 елның җәендә Институтыбыздагы бер төркем галимне Самара өлкәсенә китерде. Бу өлкә – Рәсәйнең «Кая барсаң, шунда – татар» дигән гыйбарәне чын-чынлап аклый торган урыннарыннан берсе. Биредә Татарстанның татар авылларындагы кебек үк рәхәтләнеп татарча аралашып була торган, татарча сөйли, татарча уйлый, татарча эш-гамәл кыла, тормыш алып бара торган милләттәшләребез яшәве мәгълүм. Рәсәй куенындагы Самара өлкәсендә милләттәшләребез берничә гасырлардан бирле компактлы рәвештә гомер кичерәләр, зурзур авыллар корып, менә дигән итеп яшәп яталар.

Берничә гасыр элек үк үз милләттәшләребез тамыр җибәргән төбәк буларак, Самара татарлары галимнәрне күптәннән кызыксындыра. Әле алтмышынчы елларда ук бу якларга И. Надиров, Х. Мәхмүтов, Ф. Урманчеев, Ф. Әхмәтова, Х. Гатина кебек фольклорчы галимнәр экспедицияләргә чыгып, фактик материаллар туплап алып кайтканнар, аларны академик басмалар төзегәндә кулланганнар, Самара татарларыннан җыелган рухи энҗеләрне милли мирасыбыз буларак бәяләгәннәр. Ярты гасырга якын вакыт аралыгыннан соң бу төбәкнең фольклорында, телендә-сөйләмендә, халык музыка сәнгатенең яшәешендә, археографик, ташъязма һәм этнографик мирас сакланышында һ.б. нинди яңалыклар, үсеш-үзгәрешләр, табышлар һәм югалтулар бар соң? Экпедиция әгъзаларының һәркайсы шушы сорауларның үз эшчәнлегенә бәйлесенә җавап эзләде.

Самараның Похвистнево, Келәүле һәм Камышлы районы татар авылларына Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплекслы экспедициядә барлыгы 8 кеше идек. Экспедиция составында – телче галимә, диалектолог Ф. Баязитова, геология буенча фән докторы, профессиональ фотограф Р. Мөхәммәтшин, Татарстан дәүләт музее хезмәткәре, сәнгать белгече Л. Шкляева, археографлар, филология фәннәре кандидатлары А. Гайнетдинов һәм С. Галимов, фольклорчылар, филология фәннәре кандидаты, экспедиция җитәкчесе И. Ямалтдинов һәм мин, шулай ук автобус йөртүчебез А. Маслов. Һәр белгеч үз фәнни өлкәсенә муафыйк максатларны тормышка ашыру юнәлешендә эшләде. «Юлы уңның эше уң», – ди халкыбыз. Безнең дә юлыбыз уң булып, эшебез гаять җайлы барды. Экспедиция барышында Самара татарларының рухи һәм матди мәдәнияте төрле яклап өйрәнелде.

Фольклорчы буларак, төп игътибарымны, әлбәттә, халык авыз иҗаты үрнәкләрен барлауга юнәлттем. Халык белән әңгәмә корулар нәтиҗәсендә авыз иҗатына хас кайбер үрнәкләр язып алынды, шушы төбәккә генә хас булган тарихи һәм мифологик риваятьләр, авыл тарихлары, уеннар, җырлар, йола фольклоры,

төрле ышануларга бәйле барлыкка килгән яисә халык китаптан укып сөйләгән хикәятләр, бәетләр, мөнәҗәтләр, мәзәкләр, мәзәк хәлләр архивыбызны баетты. Ачык йөзле, сүзгә оста информантлары, кулլары шифалау үзлегенә ия халык табиблары (әйтик, Яңа Мәчәләйдән Асия апа Әмирова), оста гармунчылары, гармун ясаучылары, тәмле сулары, татлы бавырсаклары, исламны хөрмәт итеп яши белә торган халкы белән күңелгә кереп калды.

Ни дисәң дә, Самара татарларында ата-бабаларыбыз каны ага, тамырларыбыз бер, гореф-гадәтләребез уртак. Һәр мәсьәләгә үз карашы булган тырыш, гаярь, җор телле, ушлы Самара татарлары – асылда, милләтебезнең тулылыгын, бөтенлеген тәэмин итеп торучы шактый эре катлам. Биредә очраган һәм язып алынган фольклор әсәрләре исә – татар халык иҗатының хәзерге торышы, халкыбыз яшәешенә, аның бүгенге сулышына тере мисал.

Үзеңнеке һәрвакыт үз була. «Без – татарлар!», – дип горурланып әйтерлек милләтеңнең булуы шул милләттән булган һәр кешедә канәгатьлек хисләре тудыра. Бу хис татарларның бай тарихка, үзенчәлекле мәдәниятклә ия халык булуыннан килә, әлбәттә. Самара татарлары белән аралашу, авыллары тарихы, күренекле шәхесләренең эш-гамәлләре, гореф-гадәт, йолалары турында үз авызларыннан ишетү, күңел сандыкларын ачтырып, анда сакланган хәзинәләр белән танышу шушы хиснең кабат яңаруына һәм тагын да ныгуына сәбәп булды. Самарада Похвистнево районы Гали, Нугай, Красный мост, Яңа Мансур, Иске Мәчәләй, Яңа Мәчәләй, Келәүле районында Назаровка, Камышлы районында Камышлының үзендә, Иске Ярмәктә, Яңа Ярмәктә, Иске Балыклыда һәм Дәүләткол авылларында булып, татарлардан туплап алып кайтылган кайбер фольклор материаллары белән укучыларны да таныштырасыбыз килә.

**Гали авылына**
**кем нигез салган?**
(тарихи риваять)

Котлыгыш монда өч улы белән килгән. Уллары Галигә – 27, Солтанга – 19, Якупка 16 яшь була биргә килгәндә. Солтанны патша хезмәтенә армиягә алалар. Якуп Оренбург далаларына чыгып китә. Ә Гали монда кала. Котлыгыш үзе Похвистневоның бер өлешендә ике тау арасында бер авыл төзеп урнаша.

Котлыгышның олы улы Гали шушы Галигә нигез сала. Авыл аның исеме белән атала. Ул монда кабат җиде гаиләне – туганнарын, якыннарын алып килә. Менә шулар хәзерге зират тирәсендә подвал казып, җир астында яши башлаганнар. Ул тирәләр күл, сазлык булган. Су җәнлекләре күп булган. Килеп урнашып, галилеләр башта шуларны тотып сатып көн иткәннәр. Соңрак сарык үрчетә, йонын сата башлаганнар, бодай игеп, икмәк белән сәүдә иткәннәр. Кемдер тимерче булып киткән. Җәнлек тиресе дә сатканнар. Шулай ныгыганнар, баеганнар.

*Гали авылыннан*
*Әхмәдиева Асия Хәлимулла*
*кызыннан (1958 елгы).*

**Тибрә Хәлилулласы**

(кушаматларга бәйле риваять)

Инәкәемнең иркәсе (*диал.* энекәш яисә сеңел. – *Л.М.*) Тибрә кушаматлы, Тибрә Хәлилулласы дип йөртәләр. Үскәндә Галидә атаклы тимерче Йосыповларга килеп йөри икән бу, шулай тимер эшенә өйрәнә дә үзе дә бидрә (чиләк), кәчтрүлләр ямый, лобогрейкалар (ургыч машина) ясый башлый. Бөтен кешегә шулай тимер эше эшләп бирә икән. Чувашлар да килә икән моңа күрше-тирә авыллардан.

– Кая барасың? – дигән сорауга каршы чуваш хатыны:

– Тибре паять иттерергә, – дип җавап бирә икән. «Бидрә» урынына «тибрә» дигән. Шуннан Тибрә Хәлилулласы булып калган инәкәемнең иркәсе. Нәселләрен дә «тибрәләр» диләр.

*Гали авылыннан*
*Әхмәдиева Асия Хәлимулла*
*кызыннан (1958 елгы).*

**Кемнең җен күргәне бар?**

(мифологик хикәят)

Ахшам укыдым. Караңгы. Дисбе тартып утырам. Карасам, дисбем төймәләре арасыннан ике ялтыр күзле кап-кара нәрсә килеп чыкты. Бәләкәй генә үзе. Кит, дим, «Лә һәүлә вә лә куватә»не укып, күзенә төкерәм. Китми дә, күзен дә йоммый. Карап тора туп-туры. Шуннан кызымны чакырдым. «Инәкәй, әйдә сызыйк», – ди кызым. «Аятелкөрси»не укып, икәүләп пычак белән стенаны сызып чыктык өй эче буйлап. Икенче көнне двухстволка мылтыктан аттырдык куркытыр өчен. Шуннан бетте теге җен.

*Гали авылыннан*
*Моратханова Наилә Закир*
*кызыннан (1936 елгы).*

**Хат**

(фольклорда эпистоляр жанр үрнәге)

Бер ирне солдатка алалар. Башкаларга карамасын, дип, хатынына болай дип хат язып җибәрә бу:

Алтын балдак кадакта.
Барысына да кояш булма,
Калырсың бит азакка.

*Гали авылыннан*
*Зарипова Фәимә Әхмәтшәриф*
*кызыннан (1957 елгы).*

**Йорт анасы кем?**

(мифологик хикәят)

Йорт анасы бар ул. Иртән торуга лапаска чыксаң, мал-туарлар тирләп-пешеп беткән. Йорт анасының эше бу. Ачуы килгән булса, шулай итә. Йорт анасы, яратмаганга, төне буе малларны куып йөрткән, диләр ие. Мунчасына да, йортына да, лапасына да хуҗа ул. Шуны йорт анасы диләр инде. Күченсәң, «Әйдә, калма бездән, ияр», – дип әйтергә кирәк. Йорт анасы үзеңнән калмый күченсә әйбәт. Саклаучы ул. Аллаһ шулай яралткан бит аны. Өйдә орчык эрләгән тавышлар чыгара ул, әле генә кул астындагы әйбереңне яшереп куеп шаяра, аннары кире урынына китереп куя, лапастагы атның ялларын үрә төнлә белән. Нишләп хатын-кыз затыннан? Соң, хатын-кыз бит бөтен нәрсәне күреп, нечкәлекләрен

белеп тора йортта. Йорт анасы да шулай.

*Нугай авылыннан*
*Кәлимуллина Мөхлисә Кәлимулла*
*кызыннан (1939 елгы).*

**Кодагый, хәзер таң ата**
(мәзәк)

Базарга барган да бер хатын, кайтышлый кодагыена кагылган. Кунарга калган. Кунакны ашарга бик кыстыйсы килми икән хуҗабикәнең.

– Хәзер таң ата, кодагый, хәзер таң ата, – дип, кунагын көттерә икән.

– Атыр, кодагый, атыр, атканчы бер ипине тартыр, – ди икән карыны ачкан кодагые моңа каршы.

*Красный Мост авылыннан*
*Вакказова Хатимә Шәяхмәт*
*кызыннан (1941 елгы).*

**Кемне сөйсә дә барыбер**
(мәзәк)

Бер килен кияве (ире) белән яхшы тормаган. Муллага килгән киңәш сорарга.

– Татулык юк. Ирем сөйми башлады. Гел талаша. Балаларны ятим итәсем килми. Нишләргә? – ди икән.

– Мин сиңа бер дога язып бирермен. Ачма, укыма. Ирең талаша башласа, шул дога язылган кәгазеңне ал да тышка чык. – дигән моңа мулла һәм язу язып кулына тоттырган.

Ярар. Кайтып киткән хатын муллага рәхмәт укып, сәдакасын биреп. Өенә кайткач, мулла әйткәнчә эшләгән инде. Яхшы тора башлаган болар. Өйдә татулык икән. «Ничек шулай?», дип, боларның тату яши башлауларының серен беләсе килгән башка хатыннарның. Теге хатын үзенең муллага баруы, аның дога язып бирүе турында сөйләп биргән. Укыйк әле, ни язган икән соң, дип, теге язуны ачып укыганнар.

Аны сөйсәни миңа,
Моны сөйсәни миңа,
Биш тиен акчасын биргәч,
Кемне сөйсәни миңа. –

дип язылган булган ди мулла биргән кәгазьдә.

*Красный Мост авылыннан*
*Вакказова Хатимә Шәяхмәт*
*кызыннан (1941 елгы).*

**«Кач-кач»**
(уен, балалар фольклоры)

Йөз чыбык чәчтереп җибәрәсең. Көтүче чәчелгән чыбыкларны җыеп бетергәнче качып бетәргә кирәк. Көтүче йөз чыбыкны да җыеп бетерә. Чәчтерсә, кабат җыя башлый. Җыеп бетергәч, качкан кешеләрне эзләү башлана. Көтүчене болай саный идек:

Әткәмә-сүткәмә, эбел-фәбел
думина,
Ике-пике раматака, зәйнеспис.

Кемгә «Зәйнеспис» сүзе чыга, шул көтүче була.

*Красный Мост авылыннан*
*Йосыпова Рәйсә Гариф*
*кызыннан (1932 елгы) .*

**Кош белми телләремне**
(җырлар)

Алларым кебек күрәм
Гөлләрем кебек күрәм,
Әллә нигә бик яратам,
Яннарым кебек күрәм.

Киртәләргә элеп куйдым
Пуховый шәлләремне.

Кошларга да сөйләр идем,
Кош белми телләремне.

Олы юлның тузанын
Мин күрмәдем тузганын.
Бер ходаем гына белә
Гомерем ничек узганын.

*Яңа Мансур авылыннан*
*Ягудина Әминә Гайфетдин*
*кызыннан (1928 елгы).*

**Күз тисә әгәр...**
(имләү йоласы)

Күз тисә, берәр җирең сырхауласа, имлиләр. Иртәнге якта таң суы алып кайтып, суга Әлхәм, Нәс сурәләрен, Аятелкөрсине укып, өрәләр. Шуның белән юындыралар кешене.

– Череген бетер, тазасына тимә, тфү-тфү! – дип өшкерәләр.

*Гали авылыннан*
*Баһаветдинова Әнисә Шәрип*
*кызыннан (1926 елгы).*

**Атын жәлләгән**
(хикәят)

Берәү базардан кайтып бара икән. Ат өстенә бер капцык бәрәңге салган. Мулланың «Хайваннарга мәрхәмәтле булыгыз» дип сүләгән вәгазе исенә төшкән моның. Туктале, дигән бу, атыма мәрхәмәтле булыйм әле, ди икән. Шыннан бу бәрәңгене аттан төшереп, капцыкны үз аркасына бәйләп куйган да, атка менеп атланган. Юл буе үзенең хайванга рәхимле-шәфкатьле булуына исе китеп кайткан ат өстендә. Иске китаптан укыган идем мин боларны, выты шыларны сүләдем.

*Иске Мәчәләй авылыннан*
*Булатова Шәмсегаят Миргаз*
*кызыннан (1930 елгы).*

**Бавырсагың таралмасын!**
(Яңа Мәчәләй мишәрләрендә
туй йоласы)

Кыз ягында никах укытыла. Никахтан соң туйгача кияү кеше кыз йортында ята, аңа кияү мунчасы ягыла, кияү коймагы пешерелә. Туй көнне килен төшерү була. Туйга кыз бавырсагы пешерәбез. Килен төп йортка төшкәнче, башта бавырсагын алып китәләр, аннары – үзен. Бавырсакны кыз ягындагы туганнары пешерә. Оста чакырып та пешерәләр бавырсакны. Аны пешерүнең үз тәртибе, кагыйдәләре бар. Пешереп, ширбәттә болгатып өеп куйганнан соң ике сәгать үткәч бавырсак оешмаса, таралып төшсә, гаилә дә нык булмый. Бавырсак тулысынча таралып бетсә, бу – гаиләнең дә таркалачагына ишарә. «Бавырсагы таралган», – диләр аннары.

*Яңа Мәчәләй авылыннан*
*Әмирова Асия Әхмәтгали*
*кызыннан (1956 елгы).*

**Дәүләтколда изге чишмә**

Иске Симәннән агып чыккан Камышлы елгасына тыкрык буйлап төшкәч тә Изге чишмә ага. Кыйблага таба ага, шуңа изге дигәннәр. Суы шифалы. Ул чишмә янында начар сүз әйтү түгел, начар уй уйларга да ярамый.

*Дәүләткол авылында*
*Галәлетдинова Тәлига Мәсәллим*
*кызыннан (1932 елгы).*

**Каз өмәсендә бәлеш урлау**
(фольклорда йола элементы)

Каз өмәсеннән соң кызлар йыелыштык. Бәлеш салынган.

Егетләр килде. Такмак әйтеп йырлыйлар. Икесе яңа такмак өйрәнгән:

– Пешә төшә, – ди берсе. Аңа каршы икенчесе әйтә:

– Пешә төшсә, бөгелә төш.

– Бөгелә төшсәң, суы чыга.

– Суы чыкса, шу да чык.

Карасак, бәлешне чәлгәннәр. Бәлеш турында әйтешәләр икән болар үзара. Без такмак әйтәләр дип, авыз ачып тыңлап торабыз. Ырланган бәлешне кире бирәләр иде. Бәясе – я «Түләгез акчагызны», – диләр инде, я йырлаталар.

*Яңа Мәчәләй авылында*
*Әмирова Асия Әхмәтгали*
*кызыннан (1956 елгы).*

## Иске Ярмәк авылы
(топонимик риваять)

Монда элек Ярмөхәммәд исемле кешенең биләмәләре булган. Авылның исемен шуңа Ярмәк атаганнар. 1737 елда авылга рәсми нигез салынган дип барыла. Әмма чынлыкта авыл борынгырак, 500 еллап тирәсе бар аның оешуына.

*Иске Ярмәк авылында*
*Галимуллин Наил Нәбиулла*
*улыннан (1957 елгы).*

## Сабырлык догасы
(мөнәҗәт)

Сабырлык – эшләрнең башы,
Сабырлык – бер хода эше.
Сабырлык ул – иман нуры,
Сабырлык бирсәнә, аллаһ!

Илаһым, хәсрәтем авыр,
Ничек итим икән сабыр?
Сабырлык ул – иман нуры,
Сабырлык бирсәнә, аллаһ!

Ходаем, хәсрәтем бетсен,
Йөрәктин кайгылар китсен,
Яна бәгърем уты, сүнсен,
Сабырлык бирсәнә, аллаһ!

*Гали авылында*
*Моратханова Наилә Закир*
*кызыннан (1936 елгы).*

## Кыз урлау йоласы

Галидә кыз урлау бар. Әле дә урлыйлар. Минем үземне дә урладылар. Мине күргән дә: «Бу минеке!» – дигән. Алдан план корганнар. Вечерда идем Саимәләрдә, әле 17 ем тулмаган чак. Күтәреп алып чыгып киттеләр дә егет өенә апкайттылар. Анда мулла чакыртылган булган. Мине ризалаттылар инде. Никах укылды. Ник китмәдем? Позор бит. Аннан ул бик чибәр кеше иде, зараза. Дүрт бала үстердек.

*Гали авылында*
*Моратханова Наилә Закир*
*кызыннан (1936 елгы).*

## Ишек – кискән, тәрәзә – тишкән
(афористик жанр үрнәге, әзер җавап)

Халкыбыз бик кунакчыл. Экспедициядә йөргәндә кайсы гына өйгә керсәң дә чәйгә кыстау гадәте бар. Самара өлкәсе татар авылларының берсендә хуҗабикә кыстый-кыстый табынга утыртты, хәзинәдә барын өстәленә тезде. Үзе туктаусыз сөйли:

– И-и, әйтеп килмәдегез бит менә, әйтеп килмәдегез! Бәлешләр пешереп торган булыр иек. Бәлешкә дигән итләрем дә әзерләп куелган. Тәмле итеп бәлешләр салган булыр ыем!

Безне информантларга озата йөрүче җор телле апа әйтә куйды:

– Хәбибә апа, болар әле бездә атна-ун көн буласылар. Иртәгә килик мәллә алай булгач?

Хуҗабикә югалып кала торганнардан түгел:

– Ишек – кискән, тәрәзә – тишкән, килсәгез, – дип, бу темага әңгәмәне ябып куйды. Бу ападан шактый гына җырлар, мәзәкләр, бәетләр язып алып, ачык йөзе, тәмле чәе өчен рәхмәтләребезне әйтеп, юлыбызны дәвам иттек.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*email: lilmuhat@mail.ru*

УДК 76

*М.Р. Газизова*

## САТИРИК РӘССАМ ИЛДАР НӘФИЕВ ИҖАТЫ

Статья посвящена творчеству И. Нафиева – одного из наиболее ярких и популярных на сегодняшний день художников-сатириков Татарстана. Круг художественных интересов И. Нафиева не ограничивается лишь сатирой, он также работает в области книжной иллюстрации и занимается живописью. Статья освещает стилевые предпочтения и тематику работ художника.

**Ключевые слова:** Ильдар Нафиев, художник-сатирик, журнал «Чаян», художник-иллюстратор.

«Чаян» журналының иң талантлы, популяр һәм актив мастерларының берсе Илдар Нәфиевнең әлеге басма белән хезмәттәшлек итә башлавына 25 ел.

«Оргсинтез» заводының сәнгать бүлегендә эшли торган яшь рәссамны «Юморина» фестивалендә катнашырга җибәрәләр. 1980 еллар азагында ул Казан шәһәренең Бауман урамында уза. 1 апрель көнне урам рәссамнар белән тула һәм алар узып баручыларның күз алдында кариктура һәм сатирик рәсемнәр ясыйлар. Иң яхшы иҗат эшләрен шәһәр комиссиясе әгъзалары сайлап ала; комиссия эшендә «Чаян» журналы вәкилләре дә катнаша. Шунда «чаян»лыларының яшь һәм өметле рәссамга күзләре төшә дә инде. Журналның баш мөхәррире аны үзләре белән хезмәттәшлек итәргә чакыра. Бу вакытта Илдар Н. Фешин исемендәге Сәнгать училищасында әле яңа гына укый башлаган була. Үз стилен һәм сәнгать телен булдыру өчен эзләнгәндә, И. Нәфиев Татарстанның Э. Гельмс, И. Хантимеров, А. Космылин кебек сатирик графика өлкәсендәге корифейларына мөрәҗәгать итә. Яшь сатирик журналга эшкә килгәндә, алар әле исән була һәм редколлегия эшендә даими катнашып киләләр. Бу утырышларда карикатураларны сайлап алу мәсьәләсендә көчле бәхәсләр куера. Ә бу исә яшь рәссамнарга үз стилен һәм фикерен формалаштыру өчен чын мәктәп була.

Сүз дә юк, бүген инде И. Нәфиев – сатира өлкәсендә эшли торган чын мастер. Аның комизмнары чама хисен югатмаган, карикатураларында ул рәсем темасының мәгънәсен һәм эчтәлеген гади һәм аңлаешлы итеп җиткерә, кирәкмәгән, артык катлаулыклардан качарга тырыша. Нәфиевнең асыл сыйфаты – сизгер күзәтүчәнлек, аңарда шатлык карнаваль яңгырашка ия түгел, каты күңеллеккә урын юк, ул тамашачыга аңлаешлы һәм ачык төсләр белән эш итә. Аның яраткан темалары – социаль һәм тормыш-көнкүреш сатирасы. Рәссамның бөтен композицияләре дә киң күңеллелек һәм гадилеге белән аерылып торалар – бу исерекләр образлары, гаилә кү-

ренешләре, безнең көндәлек тормышыбыз. Ул теге яки бу персонажның характерына хас үзенчәлекләрне төгәл ача белә, аларның сатирик якларына игътибарны юнәлтү өчен төрле детальләр эзли. Автор үзе, аеруча кыйммәтле карикатуралар дип, «сүзсез»ләрен саный. Аныңча, «визуаль юмор төрле телләрдә дә аңлаешлы булырга тиеш» һәм сатирикның максаты – сәнгать чаралары аша сюжетны бар халыкларга да танырлык итеп ачып бирү.

Карикатураларны иҗат итүнең техникасы вакытлар узу белән үзгәрә барган. 1980–1990 елларда рәссам гадәти график материаллар – карандаш, перо, акварель белән эш иткән һәм рәсем тулысы белән «кулдан ясалган». Хәзер мастер компьютер графикасыннан актив файдалана. Башта ул ручка, перо, тушь белән рәсемне кәгазьгә төшерә, аннан цифрга күчерә һәм фотошоп ярдәмендә әсәрне ахырына җиткерә.

Илдар Нәфиев иллюстратор буларак та билгеле. Училищены тәмамлау белән ул Татарстан китап нәшрияты, «Мәгариф» нәшрияты, «Идел-пресс» белән хезмәттәшлек итә башлый. Бу вакыт эчендә ул дистәләгән китапларга иллюстрацияләр ясый. Аның рәсемнәре «Салават күпере», «Ялкын», «Сөембикә», «Сабантуй» журналларында һ.б. матбугат чараларында даими рәвештә дөнья күрә. Рәссамның таланты, балалар китаплары һәм журналларын бизәгәндә, аеруча ачык чагыла.

Профессиональлек, техник яктан виртуозларча эш итә белү – И. Нәфиев әсәрләренең бәхәссез сыйфаты. Һәр иллюстрация циклында да ул, язучының идеясын укучыга җиткерү өчен, кирәкле интонацияне, стильне таба белә. В. Сосновская билгеләп үткәнчә: «Китап эшләүче рәссамнар өчен ике капма-каршы позиция бар: беренчесе – әдәби материалга төгәл нигезләнү, икенчесе – аның нигезендә үз версияңне булдыру. Беренчесендә – туры мәгънәсендә иллюстрацияләү, текстта язылган сюжет мативларын ачу, икенчесендә – текст белән сурәтләү арасындагы тышкы элементләр сүлпәнләнә һәм иллюстрацияләр ассоциатив төсмер ала. Илдар Нәфиев ике иҗади позициядән уңышлы файдалана. Ул әдәби әсәрнең идеясен гәүдәләндерергә дә, шулай ук китапны эчтәлекле һәм кызыклы итәргә дә сәләтле».

Балалар өчен иллюстрацияләр ясаганда, рәссам әсәрнең идея һәм эчтәлеген рәсемгә күчерергә тиешлеген дә исәпкә алырга кирәк. Нәфиевнең иллюстрацияләре җитди дә, юморлы да, заманча да, әмма алар аңлаешлы, нәниләрне үзенә җәлеп итәрлек. Рәссам иллюстрация аша баланы үз дөньясына алып керә, үзенең тәҗрибәсе белән уртаклаша. Балалар иллюстрациясе сәнгатьнең иң популяр һәм аңлаешлы формасы. Нәфиевнең рәсемнәре, фантазиядән бигрәк, реализмга якын. Балалар китаплары һәм журналларын эшләгәндә, ул ачык төсләр куллана һәм контрастлардан (сатирик графикадан аермалы буларак) файдалана, фотомантаж техникасын эшкә җигә.

И. Нәфиев, теге яки бу әсәр өстендә эшләгәндә, һәрвакыт иллюстрация ясала торган китапның эчке дөньясын ачып бирерлек төрле стилистик алымнар сайлый. Мәсәлән, дөнья халыклары әкиятләрен сурәткә төшергәндә, милли орнамент һәм кием элементларын рәсемгә кертергә тырыша. 2006 елда ул үзен, иллюстратор буларак кына түгел, автор буларак та сынап карый. Илдар «Приключения глупого мышонка и другие сказки» дигән шәхси китабын нәшер итә һәм «Ел китабы» Республика конкурсының «Балалар китабы» номинациясендә бүләккә лаек була.

2012 елда рәссамга ТР сәнгать фондында эш бүлмәсе бирәләр һәм И. Нәфиев сынлы сәнгать белән тыгызрак шөгыльләнә башлый. Аңа заманча сәнгатьнең авангард формалары ошый: абстракция, фовизм, этнофутуризм... Абстракт композицияләр тудырганда, рәссам уй-кичерешләренә, хисләренә, тәэсирләренә өстенлек бирә һәм безне дә үзенең эчке дөньясына алып керә. Аның әсәрләренә символика, полихромия, геометрикалык, гомумиләштерү, кыскалык хас.

Илдар Нәфиев, Татарстан мәдәнияте өлкәсендә үз урынын алган күренекле рәссам. Аның иҗаты киңкырлы, эчке дөньясы бай. Ул зур тәҗрибәгә ия һәм үз эшенең чын остасы. Рәсем сәнгатенең карикатура, иллюстрация, сынлы сәнгать өлкәләрнең һәркайсында да ул колач җәеп иҗат итә.

***Газизова Марина Ринат кызы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты,*
*«Хәзинә» милли сәнгать галереясының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 78:398.8=512.145

***Э.М. Галимова***

# МОРДОВИЯДӘ ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАРНЫҢ ҖЫР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
## (Абдулла Кротов башкаруындагы җырлар мисалында)

Данная работа посвящена исследованию и анализу песен разных жанров татар-мишарей Мордовского региона в исполнении Абдуллы Кротова. На сегодняшний период есть значительное количество работ, посвященных проблеме изучения музыкального фольклора татар-мишарей. Интерес к изучению песен татар-мишарей Мордовского региона в исполнении Абдуллы Кротова вызывает неординарное музыкально-поэтическое изложение и необходимость расшифровки данного материала, которая в будущем будет представлять определенную ценность в представлении фольклора татар-мишарей в целом.

**Ключевые слова:** музыкальный фольклор, татары-мишары, этногенез, звуковысотная организация, ритмическая организация, поэтические особенности.

Бүгенге көндә, татар-мишәрләрнең музыкаль фольклорын тикшерүгә багышлаган күп кенә фәнни хезмәтләр бар, чөнки бу этник төркемнең фольклоры бик үзенчәлекле. Идел-Урал татарлары арасында, мишәрләр, этник төркем буларак, икенче урында торалар. Әлбәттә, бөтен этник төркемнәрнең фольклор үзенчәлеген өйрәнмичә һәм аларны бер-берсе белән чагыштырмыйча торып, без ниндидер төгәл нәтиҗә ясый алмыйбыз. Мордовия республикасының мишәр җырларын башкаручы, аларны мирас итеп киләсе буынга җиткерү өчен зур тырышлык куйган кеше – Абдулла Кротов.

Абдулла Ибраһим улы Кротов 1919 елның 4 апрелендә Мордовия республикасының Кадошкин районы, Иса авылында дөньяга килә. Ул тумыштан сукыр булып туа һәм нечкә күңелле бала кечкенәдән үк музыка сәнгатенә тартыла, халык җырларын өйрәнә. Кызыклы тарихи хәлләр, борынгы җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, аның хәтерендә күп саклана. Абдулла башлангыч урта белемне, Лямбир районының Черемишево авылында урнашкан сукырлар мәктәбендә ала. 1940–1950 елларга А. Кротов инде җитди музыкант, аккордеонист, халык җырларын туплап саклаучы һәм башкаручы буларак таныла. Аннан шул җырларны язып алуга татар фольклорчысы Х. Ярми үзенең зур өлешен керткән. 1957–1960 елларда А. Кротов башкаруында 50 дән артык җыр һәм бәетләр яздырып алынган. Аның нәтиҗәсе итеп, 1979 елда дөнья күргән З. Сәйдәшева һәм Х. Ярминең «Мишәр-татарларының җырлары» җыентыгын атарга була. Бу җыентыкка А. Кротов

башкаруында ундүрт җыр кергән. Шулай ук берничә җырны М. Нигъмәтҗановның 1970 елда чыккан «Татар халык җырлары», Казанда 1988 елда чыккан «Татар халык иҗаты» китабы һәм К. Долотказин һәм Р. Исхакова-Вамба җыентыкларында да күрергә була. А. Кротов башкаруындагы җырларның язмаларын мирас итеп саклар өчен Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчеләре зур эш башкарды. Алар тарафыннан 2009 елда әлеге җырлардан тупланган диск чыгарылды.

Мишәр җырларының үзенчәлеген билгеләү һәм анализлау өчен 53 җырдан торган әлеге дисктан 24 җыр нотага салынды. Кызганычка каршы, барлык җырларның да язма сыйфаты расшифровка ясар өчен кулай түгел: шактый җырларның сүзләре аңлашылмый, аккомпонемент белән барган көйләрне, уйнау дәрәҗәсе аксау нәтиҗәсендә, гомумән нотага салуы авыр. Алда әйтеп үтелгән җыентыклардагы унике җырга З. Сәйдәшева һәм Х. Ярми, шулай ук М. Нигъмәтҗановның да ясаган расшифровкалары бар. Ләкин язмаларны тыңлаганнан соң, интонация һәм ритм ягыннан хаталарның шактый булуы ачыкланды. Гомумән, җыентык авторлары көй үлчәвен җиңеләйтеп, алышына торган ритм калыбын кулланмыйлар. М. Нигъмәтҗанов расшифровкаларда мелизмнарны төшереп калдырып, көйнең калыбын, схемасын гына нотага сала, бөтен интонацион һәм ритмик нечкәлекләрен билгеләми. Шулай ук Мордовиядә еш башкарыла торган: *«Кузырлыкай чана»*, *«Ике егет печән чаба»*, *«Малы юк егет җыры»*, *«Биек тау башында»* җырларын Р. Исхакова-Вамба үзенең «Татар халык җырлары» дип исемләнгән җыентыгына керткән. Ләкин әлеге җырлар үзенчәлекле булган икенче көй янгырашында бирелгәннәр. Татар-мишәрләрнең фольклорына гына хас бер шигырьгә берничә көй булуы гадәти күренеш. Бу расшифровкаларны анализлаганнан соң, бөтен нечкәлекләрне күздә тотып, яңабаштан төзәтмәләр кертеп, әлеге җырлар нотага салынды. Алардагы үзенчәлекле үрнәкләр башка җырларга да кызыксыну уятты. Нигездә, әле бер кем дә расшифровка ясамаган унике җыр (*«Дәрьялар»*, *«Төнге төшем»*, *«Ризыксыз егет»*, *«Салихан»*, *«Җил милчә»*, *«Җамали кыз бәете»*, *«Карт муллага чыккан кыз бәете»*, *«Мәнүк бәете»*, *«Кыз елату җырлары»*, *«Борынгы туй җыры»*, *«Туй җырлары»*, *«Ак та кияр безнең яр»*) нотага салыр өчен сайлап алынды һәм аларның музыкаль-шигъри үзенчәлекләре билгеләнде. Анализлау һәм чагыштыру өчен сайлап алынган җырлар төрле җанрда булулары белән дә әһәмиятле. Мишәр җырлары җанрларга бүленү җәһәтеннән, казан татарларының фольклорына якын. Ләкин мишәр җырлары стилистик һәм тематик яктан аерылып торалар. Мәгълүм булганча, болар бәет, озын көйләр (лирик җырлар дип тә атыйлар), кыска көйләр, һәм мишәр фольклорының үзенчәлеге булган йола җырлары.

Жанрларга бүленүенә карап, мишәр-этник төркеменә генә хас булган җырларның музыкаль-шигъри үзенчәлеген билгелик: татар-мишәрләрнең фольклорында зур әһәмияткә ия булган жанр – ул озын көйләр дип, әйтә алабыз. А. Кротов башкаруындагы җырлар шуның бер дәлиле булып тора. Әлбәттә, җырларның эчке халәтен искә алсак, аларны лирик җырлар дип тә әйтеп була. Мишәр фольклорының этник үзенчәлеге, әлеге җырларның көй һәм шигырь төзелешендә чагыла. Мәсәлән: *«Дәрьялар», «Төнге төшем», «Ризыксыз егет»* җырларында композицион беренче төзелеше өске тоника тирәсендә көй әйләнеше чагыла, ә икенче төзелешендә инде төп тоникага таба юнәлеш үзгәрә. Әлбәттә, бу мелизм чаралары белән эшләнә. Мишәр җырларында терция, кварта һәм квинта баскычларына нигезләнгән каданс зур әһәмияткә ия. Шулай ук, казан татарларының лирик җырларыннан аермалы буларак, мишәр җырларында киң тарафта интонацион сикерү еш күзәтелә: бу дорийская секста, децима интерваллары. Үзенчәлекле яңгыраган трихорд каденцияләр кулланган җырлар да шактый: *«Дәрьялар», «Ризыксыз егет», «Кыз елату җырлары»,* һәм бәет жанрында *«Җамали кыз бәете».* Диатоник авазлар рәтендә ярым тон интонацияләре кулланылу пентатоникага яңа төсмер бирә. Шигъри үзенчәлекләрен билгеләсәк, лирик җырларны берничә формула белән аера алабыз. Мәсәлән: *авсв, аааа, авав, аавв,* ә көй юнәлеше катлаулы метр белән аерылып тора (5/4, 7/4, 8/4, 11/4). Күп очракта цезуралар шигырь төзелешенә карап ясала. Төзелеше ягыннан шулай ук кызыклы алты юллык җырлар да шактый. Шигырьнең соңгы ике юлы кабатлана, нәтиҗәдә җырның кушымтасы барлыкка килә. Мисал итеп, *«Җил милчә»* җырын искә алырга була.Тагын бер үзенчәлек шунда: кушымтаның көе, җырның икенче һәм дүртенче юллары белән бәйле, шулай ук соңгы ике юл кабатлануы төп фикергә басым ясау билгесе булып тора.

Бәетләр тематика ягыннан тарихи вакыйгаларга нигезләнеп языла. Шулай ук кешенең шәхси тормышын чагылдырган бәетләр дә күп. Нигездә, бәетнең көе тар диапазонда, гадәттә – шигырь беренче, ә көй икенче урында була. Аермалы буларак: Мордовия өлкәсендә популяр булган *«Абдельман купич»* бәетен, көй төзелеше ягыннан, күп кенә музыка белгечләре (М. Нигъмәтҗанов, З. Сәйдәшева һ.б.) лирик җырларга якын дип, билгелиләр. Бу җыентыктагы *«Карт муллага чыккан кыз»* бәетенең үзенчәлеге шунда: так ритм калыбы белән җөп ритм калыбы чиратлаша. Әлбәттә, мондый очрак шигырь юллары белән бәйле. Көй септима пентатоникасына нигезләнгән һәм аның юнәлеше тоникадан-квинтага, квинтадан-тоникага таба хәрәкәт итүдән гыйбарәт. *«Җамали кыз бәете»* – алты юллык шигырь белән үзенчәлекле. Соңгы ике юл ике тапкыр кабатлана һәм лирик җырлардагы кебек кушымта ролен уйный. Мәсәлән:

*Хәзрәтебез Избез кош атты*
*Мәчетебез, аем, дип.*
*Бегылыйлар шәм коялар,*
*Җамали кыз маен, дип.*
*Бегылыйлар шәм коялар,*
*Җамали кыз маен, дип.*

Татар-мишәрләрнең фольклорында бәйрәмнәр һәм йолалар белән бәйле җырлар сакланган. Мәсәлән: *«Нардуган»* җыры. Төзелеше ягыннан бәет жанры белән якынлаша: **АВВ.** Мисал итеп, З. Сәйдәшева язып алган *«Нардуган»* җырының бер варианты:

*Нардуганың нар булсын,*
*Эче тулы нар булсын,*
*Нардуган көен көйләгән*
*Шул бәхетле яр булсын.*

*«Нардуган»* көенә төрле-төрле шигырь юллары кулланыла һәм бертөрле генә сүзләр кулланган мисаллар да бар.

Яз җитү белән, көн белән төн тигезләшү вакытын билгеләп үтү өчен, *«Җимчәчәк»* йоласы бик үзенчәлекле. Бу йола түгәрәк уен җырларын башкару белән бәйле. Р. Мөхәммәтова үзенең язмаларында әлеге йола турында бик күп мәгълүмат бирә. Гомумән, бәйрәмнәр, йолалар белән бәйле мишәр-татарларның җырлары кешенең тормыш юлын чагылдыра. Беренчедән, сабыйның дөньяга килүе, икенчедән, туй мәҗлесе һәм әлбәттә, кешене соңгы юлга озату тәртипләре белән бәйле. Л. Сәрвәрова үзенең язмаларында туй җырларын 3 төркемгә бүлә: 1. Кыз елату җырлары; 2. Мактау җырлары; 3. Каргау җырлары. «Таң кучат» йоласы – Мордовия өлкәсенең Темников һәм Лямбир татар-мишәрләрнең этник үзенчәлеге. Иртә таңда кияүгә чыгасы кыз бала бу җырны башкарырга тиеш була. Бу музыкаль җыентыктагы *«Кыз елату җырлары»* дип исемләнгән җырны мисал итеп китерә алабыз. Шулай ук, Сергач мишәрләре фольклорында бер авазда гына речитация кулланып башкарган *«Кыз елату җырлары»* күп. Туй йолалары белән бәйле мишәр җырлары арасында кияүне мактаган: *«Ак та кияр безнең яр»,* кодаларга багышланган *«Шаян җыр»,* бию көйләре аерылып тора. Шулай ук Мордовиядә туй җырларын кияү белән кәләшнең туганнары үзара диалог формасында башкара. Әлеге башкару ысулы керәшен, чуваш һәм мари этник төркемнәре арасында да күзәтелә. Җырның төзелеше ягыннан карасак: **АВ,** яки **АВВ,** шигыре 7–8 иҗектән, 4 юлдан тора. Мәсәлән: *«Ак та кияр безнең яр»* җыры. Шулай ук күп кенә мисалларда 4/4 һәм 5/4 ритм калыбының чиратлашуы гадәти күренеш.

Кыска көйләр жанрына мисал итеп: *«Шаян җыр»*ны китерә алабыз. Җырның көй төзелеше – **аавсс** – секстовая пентатоникага нигезләнгән. Рәттән төзелгән баскычлардан барган көй юнәлеше һәм киң булмаган диапазон – гадәти күренеш. Шигырьнең ахыргы ике юлы кабатлануы бу жанрда да төп фикерне ныгыта.

Абдулла Кротов башкаруындагы җырларны Мордовиядә яшәүче татар-мишәрләрнең фольклорына гына хас булган, этник үзенчәлекләрен саклаган милли мирас дип әйтергә була. Нигездә, көй язылышы һәм аның юнәлеше, лад, ритм калыбының

алмашынуы, мишәр диалектында булган сүз тезмәсе, *«Абау, гөлкәем», «Абау, бәгърем», «Ах, җанушым», «Алтын алмам»* җырларындагы цезураның дүртенче һәм алтынчы юлдан соң урнашуы – гадәти күренеш. Шулай ук башка этник төркемнәреннән аерылып тору билгесе итеп, мисалга китергән музыкаль-шигъри чараларны да әйтә алабыз. Җырның композицион төзелеше ягыннан карасак, А. Кротов, беренче куплетны тәкъдим итү йөзеннән, вариатив чараларны кулланмый, чөнки алдагы куплетларда кабатлау җирләрен вариацияләргә тырыша. Әлбәттә, моның өчен ул тавыш мөмкинчелекләрен дә төрлеләндерә: бер-берсенә охшамаган мелизмнар, музыкаль оборотлар куллана. Мәсәлән, аның җырларында өчлек белән сигезле ритмында, пентатоника кысаларыннан чыкмаган мелизм еш очрый, шулай ук җырның ахыргы ритмик өлешләрен дә, ул мелизм белән тулыландыра. Бөтен җанрларны да берләштерә торган шигъри үзенчәлекне әйтеп үтәргә кирәк: җырларның соңгы ике юлы кабатлану төп фикергә басым ясау, нәтиҗә чыгару өчен мөһим.

Нигездә, башка этник төркемнәрдән аермалы буларак, татар-мишәрләрнең җыр сәнгате зур кызыксыну уята һәм Абдулла Кротов башкаруындагы җырларны музыкаль фольклор хәзинәсенең энҗе бөртекләре дип, әйтергә була.

**Әдәбият**

*Гиршман Я.М.* Пентатоника и ее развитие в татарской музыке / Я.М. Гиршман. М.: Сов. Композитор, 1960. –179 с.

*Долотказин К.И.* Иса авылы җырлары. Казань, 2006. 22 с.

*Исхаков Д.М.* Этнография татарского народа. Казань, 2004. 287 с.

*Исхакова-Вамба Р.А.* Татарские народные песни / Р.А. Исхакова-Вамба. М.: Сов. композитор, 1981. 190 с.

*Исхакова-Вамба Р.А.* Татарское народное музыкальное творчество: Традиционный фольклор / Р.А. Исхакова-Вамба. Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. 262 с.

*Капкаев А.А.* Абдулла Кротов – легенда татарской фольклористики // Татарский мир. Москва, 2005. № 9–10;

*Каюмова Э.Р.* Татарская народно-песенная культура Нового времени: Проблемы традиционного мышления и жанровой атрибуции / Э.Р. Каюмова. Казань, 2005. 256 с.

Народный певец Абдулла Кротов // Сборник ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Казань, 2010. 186 с.

*Нигмедзянов М.Н.* Татарские народные песни / М.Н. Нигмедзянов. М.: Сов. Композитор, 1970. 184 с.

*Нигмедзянов М.Н.* Народные песни волжских татар: исследование / ред. М. Нигмедзянов. М.: Сов. композитор, 1982. 135 с.

*Нигмедзянов М.Н.* К характеристике жанров татарских народных песен // Музыка и современность: Актуальные вопросы народной музыки / ред. М. Нигмедзянов. Казань, 1986. С. 98–125.

*Сайдашева З.Н., Ярми Х.Х.* Татарско-мишарские песни. М., 1979. 80 с.

*Сайдашева З.Н.* Татарская музыкальная этнография / З.Н. Сайдашева. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. 224 с.

*Сарварова Л.И.* Этнический компонент песенной культуры татар-мишарей: Вопросы звуковысотной и фактурной организации: автореф. дис. ... канд. искусствовед: 17.00.02 / Л.И. Сарварова. Казань, 2006. 23 с.

*Урманчеев Ф.И.* Собирание и изучение татарского фольклора // Советская этнография. М, 1966. № 5. С. 142–148.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*

## ӘХМӘТЬЯНОВ Р.Г. ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЭТИМОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ

Бу сүзлек – татар тел белемендә күптән көтелгән иң катлаулы да, иң кирәкле дә булган хезмәтләрнең берсе. Ниһаять, татар халкының югары мәгърифәтлелеген, татар тел белеме фәненең зур казанышын чагылдырган, барыбыз өчен дә гаять әһәмиятле булган әлеге хезмәт «Мәгариф – Вакыт» нәшриятында дөнья күрде.

Авторның бу хезмәте тирән белем таләп итә торган, эшләү өчен гуманитар фәннәрдә иң катлаулы булган зур эш.

Анда этимологик сүзлек төзүнең бай тәҗрибәсе чагылган. Әмма иң әһәмиятлесе – туган телебезнең меңләгән еллар буе туплана килгән искиткеч бай, киң тармаклы, халкыбызга хас күпкырлы эшчәнлекне шактый тулы чагылдыра. Моңа бары дистәләгән еллар буе башкарылып килгән фидакарь хезмәт белән генә ирешергә мөмкин. Монда, әлбәттә, Р.Г. Әхмәтьяновның үз халкын яхшы белүе һәм аңлавы, үз туган телен һәм шулай ук ут күршебез башкорт телен чын күңелдән яратуы да ярдәм иткән.

Сүзлекнең әһәмиятле үзенчәлекләреннән берсе – анда диалектлардан да бай материал кертелгән булу. Бу – һичшиксез, уңай күренеш. Чөнки безнең әдәби телебезнең чисталыгын сакларга тырышу өстендә алып барган эшчәнлегебез аның матур бизәкләрен киметүгә китерде. Автор, телебезнең төп хәзинәсенә хәзерге вакытта күтәрелеп киткән энҗе җәүһәрләрен дә өстәп, сүзлекне баетуга ирешкән.

Хезмәт бай чыганакларга нигезләнгән:

– гасыр тузаннарына күмелеп юкка чыга язган галәм белән бәйле сүзләр;

– онытыла башлаган һәм хәзер диалектологлар (Ф.С. Баязитова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б.), этнографлар, авыз иҗатын өйрәнеп, халыкка кайтару өстендә эшләүче галимнәрнең хезмәтләрендәге материаллар;

– халкыбызның матди һәм рухи мәдәнияте элементларын торгызуда актив эшли торган әдипләребез, шагыйрьләребезнең матур иҗат үрнәкләре;

– үзгәртеп кору елларында баш калкытып, хәзергә хәтле бөтен көчләрен туплап татар теленең сүзлек һәм терминологик байлыгын мәңгеләштергән төрле юнәлешле сүзлекләр һ.б.

Менә шундый киң колачлы чыганакларга тарих шаһиты итеп урнаштырылган тел байлыгы Р. Әхмәтьяновның «Татар теленең 2 томлык этимологик сүзлеген»дә урын алган.

Тагын бер гаять әһәмиятле факт: сүзлектәге һәр сүз искитәрлек бай әдәбиятка нигезләнеп аңлатыла. Ул – татар теле мәдәниятенең барлык тармакларында эшләүчеләр өчен дә күптән көтеп алынган, кадерле, кызыклы, бай мәгълүматлы кулланма.

Этимология – ул бик катлаулы өлкә. Аны укыган һәркемнең үз фикере булырга мөмкин. Әмма без – гади укучыларның фикер йөртү чыганагы төрле югарылыкта, төрле киңлектә

була, ә бөтен гомерен шушы гаять авыр эшкә багышлаган галим кеше колачлырак карый, күбрәк белә. Әлеге сүзлек бу яктан да бик откан, чөнки автор, үзенең тирән белемен эшкә җигү белән бергә, укучыга да шушы изге эштә катнашырга урын калдыра, сораулар куя, төрле карашларны китерә.

Кереш сүз бик күп теоретик фикерләрне туплаган үзенә бер зур хезмәт булып тора. Автор татар тел белеменең, гомуми тел белеменең бүгенге югары казанышларын чагылдыра. Анда этимология фәненең принциплары, сүзләрнең этимонын, нигезен ачу критерийлары җентекле бәян ителә, авторның ачышлары бай материал белән дәлилләнә. Р.Г. Әхмәтьянов үзен эзләнүчән, фәнни-нәзари яктан туктаусыз үсә бара торган, өлгергән галим итеп таныткан. Аның кереш сүзендә бүгенге көндә һаман да актуаль булып кала килгән мәсьәләләр күтәрелгән һәм чишелеш тапкан.

Сүзлекнең белешмәлек өлеше – телләр һәм сөйләшләр исемлеге, чыганакларны чагылдырган библиография һ.б. – барысы да югары дәрәҗәдә оештырылган. Алай гына түгел, автор сүзләрне аңлатканда таянган башка галимнәрнең исемлеген дә аерым күрсәтүне кирәк тапкан.

Сүзлекнең кереш өлеше укучының белемен, карашларын бермә-бер арттыра, киңәйтә.

Шушында ук хезмәтнең фәнни редакторының, бу авыр эштә булышкан техник хезмәткәрләрнең изге өлешен аерып күрсәтмичә булмый.

**_Рамазанова Дөррия Бәйрәм кызы,_**
*филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

## ДОКУМЕНТЛАРДА – ТАРИХ САБАКЛАРЫ

Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәрләре, XIX–XX йөзләрдәге татар авылы җәмгыяте халәтен өйрәнүгә багышланган тарихи хезмәтләрне өйрәнеп, аларны бастырып чыгару өлкәсендә актив эш алып баралар. Бу өлкәдә аеруча тарих фәннәре докторы Илдус Заһидуллин җитәкчелек иткән бүлек хезмәткәрләре активлык күрсәтеп килә. Шул ук вакытта И. Заһидулин да – XIX йөздәге татар мәгарифе һәм ислам дине белән бәйле проблемаларга багышланган калын-калын хезмәтләр язып һәм аларны бастырып чыгарып, тарихи мирасыбызны барлауга зур өлеш кертүче. Менә бер төркем тарихчылар 1880–1905 елларда татар-мөселман җәмгыятьләрендә барган яңарыш хәрәкәте барышын чагылдырган чыганаклар җыентыгын иҗади төзеп, тәфсилле искәрмәләрне аларга юлдаш итеп, документларда искә алынган шәхесләрнең зур гына исемлеген төзеп бастырып чыгарды[1]. Әлеге исемлек үзенә күрә бер энциклопедия моделе кебек танылa. 532 битлек китапның фәнни һәм техник эшләнеш ягы – тарихыбызны барлау юлында эшләүче актив яшьләр үскәнне исбатлаучы факт.

XIX гасыр – Русия тарихында күп яңалыклар, тарихның алга барышын күрсәтүче көчле фактларга байый барганлыгын раслаучы дәвер. Бу дәвер Русиядә инде крепостнойлык-коллык дәверенең соңгы чиккә килеп җиткәнлеген күрсәткән термометрны хәтерләтә.

Русиядәге крепостнойлык хуҗалыгы – илнең, җәмгыятьнең тупикка терәлгәнлеге күрсәткече. Ул кайсыдыр яклары белән бүгенге Русиядәге кризиска китергән, көчкә таянып кына эш итәргә яратучыларның һ.б. эшләре дөрес юлдан бармаганлыгына да ишарә булып тора.

Мәсәлән, алпавыт-крепостнойлар хакимияте илнең экономик үсешенә тормоз булганлыгын әле XIX йөзнең алтмышынчы елларында да аңлап эш итмиләр иде. Илдә бу көннәрдә дә шушы психологик халәт хөкем сөрә.

Крепостнойлык Русиянең экономик үсешенә ат аякларына кидерелгән тышау ролен үти. Шулай ук башка милләтләргә карата төрле кысу, чикләүләр аларның мәдәниятенә һөҗүм, мәгарифенә һөҗүм илнең бердәмлегенә тискәре тәэсирен арттырып тора.

Русиядә 1878 елларда урысларның Төркияне җиңүләре илнең халыклары арасында хуплау тапмады. Җиңү белән шашкан чиновниклар урыс булмаган халыкларны чукындырабыз, дип, мөселман татарларга каршы кораллы хәрби көчләр, Казан янындагы Чыпчык авылы урысларына тал чыбыклар тоттырып, Әтнә, Олы Мәңгәр, Мәмсә һ.б. авыл

---

[1] Модернизационные процессы в татарско-мусульманском сообществе в 1880-е – 1905 гг.: документы и материалы / сост. И.К. Загидуллин, Н.С. Хамитбаева, Л.Ф. Байбулатова и др.; под ред. И.К. Загидуллина. Казань: ЯЗ. 2014. 512 с.

татарларын кышның салкын көнендә кырга чыгарып, башларыннан бүрекләрен салдырып, аларны бер кат алача штаннар белән кар өстенә утыртып, урындыкларга бәйләп салып, тал чыбык белән суктырулары әллә урыс-татар дуслыгын ныгытыр дип уйладылармы?

Җир азлыктан интеккән татар халкының бер өлеше, монда яшәү мөмкинлеге чикләнгәнен күргәч, илен ташлап, Троицк, Чиләбе, Каргалы, Кызылҗар, Аягуз, Сими, Питрауга, Җаек якларына күчеп китеп, анда тиз арада тормыш хәлләрен яхшырттылар, чөнки ул якларда крепостнойлык, татарларга каршы юнәлдерелгән глобаль изү сәясәте йомшаграк була.

Моннан нәтиҗә: татар халкын хакимият никадәр кысып, эзәрлекләп интектерсәләр дә милләтебез үзенең гакыл хәзинәсе белән бу казадан чыгу юлын тапкан.

Әлеге яңа чыккан җыентыкта да һәм икътисади, һәм мәдәни өлкәдә татарның тапкырлык эзләре ялтырап ята. Аны тик таный белергә һәм тарихтан тиешле сабак алырга гына кирәк.

***Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

**2015 елның 29 июненнән 10 июленә кадәр** Россиянең Оренбург өлкәсендә Г. Ибрагимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган экспедиция эшләде. Өлкәнең 15 авылы – Шарлык районының Яңа Муса, Иске Сарманай, Зирекле, Мостафа; Александровка районының Султакай, Тукай, Яфар; Сакмар районының Каргалы, Чебенле, Кабан, Биктимер; Саракташ районының Колчым, Шишмә, Рәдүт (Никитино) һәм Әбләздә – институтның фәнни хезмәткәрләре – тел, фольклор, сәнгать белгечләре – тарафыннан шактый бай материал җыелды. Җирле халыкның тел үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, йолалары өйрәнелде; музыкаль фольклор үрнәкләре җыелды, кулъязма мирас һәм эпиграфик ядкәрләр тупланды. Институтның Кулъязма һәм музыкаль мирас үзәге кулъязма һәм басма китаплар белән баетылды. Оренбург өлкәсе татарларына хас һөнәр төрләре, декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләре турында бай материал җыелды.

Элек-электән татарның аңбелем учагы булган; Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Мирхәйдәр Фәйзи, Муса Җәлил һәм башка бик күпләрне үз бишегендә тибрәтеп үстергән Оренбург өлкәсе бүген дә туган телебезне, мәдәниятыбызны, рухи байлыгыбызны саклап килә. Экспедиция материаллары шул хакта сөйли.

Сәфәр нәтиҗәләре киләчәктә яңа хезмәтләргә ныклы нигез булыр, дип ышанып калабыз.

Агымдагы елның **30 июнь – 13 июль көннәрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Томск өлкәсенең татар авылларына ясалган фәнни экспедиция эшендә катнаштылар. Экспедициянең максаты – бу төбәктә яшәгән татарларның рухи-мәдәни мирасын, тарихын, көнкүрешен өйрәнү, өлкәнең иҗтимагый-сәяси тормышында аларның тоткан урынын, ролен өйрәнү иде. Ул Татарстан Республикасының «Сохранение национальной идентичности татарского народа (2014–2016 годы)» программасы кысаларында оештырылды һәм Томск өлкәсенең Әүштә, Абытай (Черная Речка), Кызылкаш (Тахтамышево), Барабинка, Казанка, Калтай авылларында уздырылды. Эш барышында фольклор галиме И.Г. Закирова, диалектологлар О.Р. Хисамов (экспедициянең җитәкчесе), М.Г. Булатова, галим-археограф И.Г. Гомәров, булачак галимәләр – аспирантлар Г.М. Яхшисарова, А.Р. Борһанова тарафыннан җирле татарларның халык авыз иҗатына, тел-сөйләш үзенчәлекләренә, топонимия, археография һәм сәнгатенә кагылышлы материаллар тупланды. Алар Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплекслы экспедицияләре нәтиҗәсе буларак дөнья күрә килгән «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә урын алачак.

**Университет ул – үзе зур дәүләт.** Казан федераль универ-

ситетының А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты яңа лаборатория корпусында яңа уку елын башлап җибәрде. Яңа мәгариф учагын ачу тантанасында Татарстан Президенты, КФУның Попечительләр советы рәисе Рөстәм Миңнеханов, ТР Премьер-министры урынбасары – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов һәм башкалар катнашты.

«Казан федераль университетына килгән саен, ниндидер яңа лабораторияләр, төзекләндерелгән биналар ачуыбыз сөендерә. Химия институтының хәле шактый мөшкел иде. Без менә шундый төп институтлардан башка, университетыбызның белем бирү-тикшеренүләр үткәрүдә лидер була алмаячагын аңлый идек. Безгә бөтен дөньядан белемне бөртекләп җыярга кирәк. Әгәр институтларыбыз лаеклы булса, моңа ирешеп була. Казан университеты – ул лидер. Университет ул – үзе зур дәүләт», – диде Татарстан Президенты.

Химия институты директоры Владимир Галкин бу яңа корпус университетның химиклары гына түгел, геологлары, медиклары өчен дә көтеп алынган вакыйга икәнлегенә басым ясап, болай диде: «Бу корпус дисциплинаара характерда булачак, 37 лабораториядә наноматериаллар, полимер материаллар һәм композитлар җитештерү һәм башка төрле юнәлешләрдә эш алып барылачак. Болар бөтен дөнья дәрәҗәсендәге заманча җиһазларда башкарыла. Кайбер төр җайланмалар Россия һәм хәтта дөньяда да бердәнбер нөсхәдә. Болар барысы да химиядә җитди алгарышка ирештерәчәк». Владимир Галкин билгеләп узганча, биредә ветеринария, медицина өчен импортны алмаштыручы яңа, чит илләрнекеннән арзанрак медицина препаратлары эшләнәчәк.

**Татарлар тарихындагы билгесез битләр.** Магнитогорскилы милләттәшебез, фәлсәфә фәннәре кандидаты Салават Әхмәтҗанов шәһәр һәм металлургия комбинаты төзелү тарихы һәм аны төзүдә татарларның өлеше, роле турында китап язган. «Спецпереселенцы – первостроители Магнитогорска» дип аталган әлеге басма сентябрь аенда Магнитогорскиның Үзәк шәһәр китапханәсендә әлеге кала җәмәгатьчелегенә тәкъдим ителде.

Яшәү уңайлыклары булмаганга, үз ирекләре белән эшкә килүчеләр мондый кырыс шартларга түзә алмыйча кире китәләр. Шуңа күрә кешеләрне буш урында шәһәр төзергә мәҗбүри китерү турында 1931 елда карар кабул ителә. Комбинат һәм шәһәр төзергә махсус күчерелгәннәрнең күпчелеге – Татарстан, Ярославль, Кострома, Иваново, Рязань өлкәләреннән кулак дип сөрелгән крестьяннар, зур хуҗалык тоткан тәҗрибәле хезмәт кешеләре.

Магнитогорск шәһәрен, нигездә, руслар һәм татарлар төзегән, ә беренче бистәдә яшәүчеләр, барысы да диярлек, татарча сөйләшкән. Аерым алганда, Магнитогорскига Татарстаннан гына да 42 мең кеше (аларның яртысы диярлек – татарлар) күчерелгән. 1933 елда инде торак пунктта 50 меңнән артык кеше исәплән-

гән, әмма иртә үлемнәр, качып китүләр 1936 елга халык санын 26 меңгә калдырган.

Казан, Магнитогорск архивларында, Чиләбенең НКВД архивында эзләнүләр алып барган, күчерелгәннәр һәм аларның якыннары белән аралашкан Салават Әхмәтҗанов татарлар тарихындагы билгесез битләрне киң җәмәгатьчелеккә ача. Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты Магнитогорск филиалында фәнни эшчәнлек башында торган милләттәшебез 2 еллап бөртекләп материал туплаган. Китап 321 данә тираж белән дөнья күргән.

**КФУ галимнәре яңа препарат ясаган.** Казан федераль университеты галимнәре яңа буын пробиотик препараты ясаган. Университет тикшеренүчеләре ышандырганча, яңа препарат үзенең нәтиҗәлелеге белән дисбактериозны дәвалау буенча киң таралган даруларны берничә тапкырга узып китә икән.

Пробиотик булдыру эше Россия Фәннәр академиясенең А.Н. Несмеянов исемендәге Элемент-органик кушылмалар институты вәкилләре белән бергәлектә алып барылган. Тикшерү нәтиҗәләре буенча «Молекулярная генетика, микробиология и вирусология», «Микробиология», «Прикладная биохимия и микробиология» журналларында фәнни мәкаләләр бастырылган. Уйлап табылган ачыш өчен патент алынган, проектны коммерцияле нигездә тормышка ашыру өчен заказчылар эзләү эше алып барыла.

Эшләнелгән препаратның өстенлеге, барыннан да элек, аның составына кергән бифидобактерияләр һәм лактобациллаларның төрләр күплеге югары булуында. Әлеге препарат составына Lactobacillus plantarum, Lactobacillus fermentum, Lactobacillus acidophilus, Lactobacillus casei, Bifidobacterium bifidum, Bifidobacterium longum кебек микроорганизмнар керә, аларның йогышлы авыруларга каршы тору үзлеге расланган, шулай ук кеше организмында иммунитетны яхшыртуга сәләтле.

**«Болгар» музей-тыюлыгында II Халыкара кыр археология мәктәбе уздырылды.** Август аенда «Болгар» музей-тыюлыгы базасында II Халыкара кыр археология мәктәбе уздырылды. Ул дөнья фән казанышларын Евразия халыклары тарихи-мәдәни мирасын саклау һәм өйрәнү тәҗрибәсендә файдалану өчен Россия һәм чит ил фәнни-белем бирү ресурсларын бергә туплау максаты белән үткәрелде. Мәктәп эшчәнлеге кысаларында палеоантропология, борынгы металлургия һәм металл эшкәртү, археологиядә археобиологик ысуллар, шулай ук геомәгълүмати системалар, борынгы керамика тарихы, археологик пыяла һ.б. фәнни юнәлешләр буенча секцияләр оештырылды. Моннан тыш, программада тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм өйрәнү ысуллары, шулай ук кыр тикшеренүләренең хәзерге заман технологияләре мәсьәләләренә багышланган гомуми лекцияләр курсы уздырылды.

Мәктәп үз эшен Евразия халыклары мәдәни мирасын саклау һәм өйрәнүнең яңа технологияләренә багышланган конференция белән тәгәлләнде.

Чара ТР Фәннәр академиясенең А. Халиков исемендәге Археология институты, Казан федераль университеты һәм «Болгар» музей-тыюлыгы белән берлектә оештырылды.

**Япон егете татар грамматикасы турында китап язарга тели.** Соңгы вакытта татар телен өйрәнүче чит ил кешеләренең саны арту күзәтелә. Бу бигрәк тә Япониядә артты. Аның башкаласы Токиода татар теле курслары 2014 елның ахырыннан бирле уздырыла. Әлеге дәресләрне Төркиянең Япониядәге илчелеге, Юныс Әмрә институты белән берлектә, оештыра. Татар телен Гөлнара Курасава укыта. Курсларга йөрүчеләр татар теленең кыскача грамматикасын өйрәнә, тәрҗемә белән шөгыльләнә, татар җырларын өйрәнеп җырлый. Курсларга йөрүчеләр арасында Япониянең Хиросима шәһәрендә туган Казуки Аояма да бар. Хәзерге вакытта ул Токио университетында тел белеме белгечлеге буенча укый. Югары уку йортында ул төрек телен тирәнтен өйрәнә. Шуңа бәйле рәвештә, егеттә башка төрки телләрне, шул исәптән татар телен, өйрәнү теләге туган.

«Мин төрек телен яхшы беләм. Ә төрек һәм татар телендә сүзләр һәм грамматика бик охшаш булганга, татарчага өйрәнү минем өчен бик авыр түгел. Минем өчен татар теле – бик матур тел. Шулай ук татар милли киемнәре һәм биюләре дә бик ошый», – дип фикерләре белән уртаклашкан Казуки. Ул киләчәктә дә татар телен өйрәнүне дәвам итеп, татар теле грамматикасы буенча китап язарга тели.

**Кырымда профессор Җәвид Котдусов белән хушлаштылар.** 24 сентябрьдә Кырымның Акмәчет (Симферополь) каласында Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, музыкант, хор дирижеры, педагог, профессор Җәвид Котдусов вафат булды.

1929 елда Акмәчеттә Җәвид Котдусов танылган татар җырчысы, Татарстанның атказанган артисткасы Шәфыйка Котдусова (1910–1956) һәм адвокат Абдураим Котдусов гаиләсендә туган. Балалыгы Керчь, Карасубазар, Акмәчет калаларында уза. Акмәчеттә урта мәктәптә, 1 нче музыка мәктәбендә укый. 1941 елда энисе белән Казанга килә. Әтисе фронтта һәлак була. Яшь чакта Казанда оборона заводларында эшли (1942–1944). Әтисенең фронтта һәлак булуы аңа зур тәэсир ясый һәм ул, әтисе өчен фашистлардан үч алырга дип, 14 яшендә Төньяк флотка юнга булып китә. Хәрби хезмәттән соң, ул Казанга әйләнеп кайта, консерваториягә укырга керә. Консерваториянең өченче курсында укыганда, татар сәнгате тарихында беренче җыр бәйрәмен башта Татарстанның нефть районнарында, соңрак, Казанда үткәрә. Шунда үзен талантлы дирижер-башкаручы итеп таныта.

Консерваторияне тәмамлагач, аны Татар җыр һәм бию ансамбленә хормейстер итеп чакыралар. Ул берничә ел (1961–1970) ансамбльнең сәнгать җитәкчесе була. Шул чорда ансамбль Советлар берлегендә татарлар яшәгән төбәкләрдә чыгыш ясый. Аның җитәкчелегендә ансамбль «Сакмар», «Гөлҗамал», «Зиләйлүк», «Зөлхиҗҗә» һәм башка татар халык көйләрен радиога яздыра. Котдусов композиторлар А. Ключарев, З. Хәбибуллин, Ф. Гаскәровлар һ.б. белән иҗади дуслыкта эшли. 1970 елдан Казан мәдәният һәм сәнгать университетында укыта, 1987 елга кадәр кафедра мөдире, аннары профессор һәм декан була. 1998 елда Җ. Котдусов Кырымга кайта. Монда ул кырымтатарлар күпләп укыткан һәм укыган Кырым дәүләт инженер-педагогия университетына музыка кафедрасының мөдире итеп тәгаенләнә. Бу вазифада эшләгәндә (1998–2012), ул кафедрага кырымтатар укытучыларын җәлеп итә, аларны профессиональ яктан үстерүгә зур көч куя, студентларны кырымтатар музыка сәнгате өчен әзерли. Ул һәрвакыт кырымтатарларның фаҗигале такъдирен уйлап, туган халкына кулыннан килгәнчә эшләргә тырышып, янып-көеп яши.

Җәвид Абдураим улы Котдусов Акмәчетнең мөселман зиратында җирләнде.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2015. № 3

Бизәлеш авторы
*Э. Бәшәрова*

Компьютерда биткә салучы
*Н.Абдуллина*

Басарга кул куелды: 30.11.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20